

# Харрас Әюп



# ЙӨЗ ЯКТЫСЫ

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84(2Рос=Тат)—5
Ә 94

**Әюп Харрас**

Ә 94 Йөз яктысы: Шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 415 бит.

Шагыйрьнең бу китабына халык һәм ил язмышы, яшәү мәгънәсе турындагы лирик-фәлсәфи уйлануларын эченә алган шигырьләре һәм поэмалары тупланды.

ISBN 5-298-04115-9

© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Харрас Әюп, 2005

## КҮҢЕЛЕНДӘ ШИГЫРЬ УТЫ

Беребезгә дә сер түгел: татарны татар итә торган, ягъни аның телен, моңын, йолаларын һәм гореф-гадәтләрен бозмыйча диярлек саклый торган төбәкләр бик аз калып бара. Әмма, шөкер, урыны-урыны белән булса да, алар бар әле. Гүзәл табигать кочагына һәм ямьле Ык буена сыенып урнашкан Мөслим районының соңгылар исәбендә булуы, минемчә, бәхәссез. Моңа ышану өчен бу төбәктән Зөлфәт, Факил Сафин, Наис Гамбәр, Шәмсия Җиһангирова кебек танылган әдипләрнең чыгуын, Фоат Садриевның шунда яшәп иҗат итүен телгә алу да җитә торгандыр. Әлеге мәкаләдә сүз барачак якташым шагыйрь Харрас Әюп тә шушы якның бәрәкәтле туфрагыннан үсеп чыккан талант иясе.

Белүебезчә, Юлиан Семенов сценариесы буенча эшләнгән «Язның унҗиде мизгеле» дигән кинофильмда «Ватан кайдан башлана?» дигән тирән мәгънәле җыр бар. Харрас өчен олы дөньяга чыгу, Ватанын танып белү туган авылы Түрештән һәм әлеге авылның басу капкасыннан башланган.

Без түш белән шуып чыгып киттек
Балачактан... капка аслатып.

Әмма Казан университетында студент булган елларында да, шулай ук төрле газета редакцияләрендә журналист булып эшләгән дәверләрендә дә Харрасның «малай чагы һәрчак хәтеренең ал офыгында» була, «бер тотам да калмый артыннан йөгерә». Шигырьләрендә гомеренең шул чорына кабат-кабат кайтырга яратуының, әлбәттә, хикмәте бар. Гамьсез һәм кайгысыз үткән еллар түгел, ә сугыштан соңгы авыр дәвергә туры килгән «чабаталы һәм чүпрәк букчалы», «ач-ялангач һәм ачы кукылы» була аның бала чагы. Сугыштан яраланып кайткан әтисе дөнья

куйганнан соң, аңа бик иртә балалык чоры белән хушлашырга, дөнья нужасын тол калган әнисе белән чын ирләр кебек күтәрешергә туры килә.

Шагыйрьнең «Игенче турында баллада»сы шушындый ачы язмышына шактый дәрәҗәдә тап килеп тора. Аерым алганда, әлеге әсәрдә басуда көлтә бәйләүче хатын-кызларга хат ташучының көтмәгәндә сугыш башлану турында хәбәр китерүе һәм «ил өстенә төшкән кайгыны күтәрә алмыйча, бишек асылган куш имәннең шартлап сынуы», бишек бавының да өзелеп чыгуы тасвирлана. Һәм менә шул мәлдә янә таң калырлык могҗиза була: егылган сабый торып баса да, ир-егеткә әверелеп, яшь иңнәре белән ил кайгысын күтәрешә һәм кулына урак ала.

Туган як табигате сабый яшендә үк балигъ булган Харраска бөтен барлыгы белән теләктәшлек итә: «җил яшьләрен сөртә», «җәйләр елаган җанын җылыта», «урман киемен салып бирә», «тугайлар җиләкле паласын җәя», «күкеләр сөю-сагыну телләренә өйрәтә». Х.Әюпнең шагыйрь булгач та табигать баласы булып калуына һәм кешене табигать белән , табигатьне исә кеше белән «үлчәп» язуына гаҗәпләнергә кирәкми. Үзенең кылган һәм кылачак эшләрен дә ул табигать бизмәне белән үлчи:

Хыянәткә барсам, тау ишелер,
Нәкъ урталай ярылыр бу болын,
Имәннәрне давыл йолкып ташлар,
Барысы бергә дәшәр:
– И-и-их улым!

Кеше белән табигать берлегенең иң көчле гәүдәләнгән формасы, әлбәттә, ике арадагы кардәшлекнең һәм гармониянең сурәтләү объекты булып әверелүендә. Харрасның бик күп шигырьләрендә гармония мотивы кызыл җеп булып үзәктән бара. Һәм шагыйрь образы безнең алга табигатьнең, туган як туфрагының телен һәм ирләрен белүче тылсым иясе булып килеп баса. Әдипнең үз сүзләрен катнаштырып әйткәндә, ул «кояш нурларында пәрәвез тирбәлүен ишетә», «гөлләрдәге күбәләкне укый», «җилләр җырын тыңлый», «камыш белән серләшә», «сандугач кайгысыннан җылый».

Ләкин әлеге шигырьләрдән бөтенләй көтелмәгән саллы нәтиҗә дә чыга: табигатьнең серен кешенең үзеннән эзләргә кирәк! Әйе, дөньяда иң зур сер булган, табигатьнең серләрен дә үзенә җыйган Кеше галиҗәнапларыннан эзләргә. Грек философы Сократ «иң кыены – үз-үзеңне танып белү» дип юкка гына әйтмәгән. Минемчә, кешенең, шул исәптән үзенең табигатен аңлау һәм ачу өчен Х.Әюпнең нәкъ менә табигать белән кеше мөнәсәбәтенә игътибар итүе һәм маңгай күзе белән генә түгел, ә күңел күзе белән дә ике арада ассоциатив уртаклыклар күрүе бик урынлы. Мәсәлән, ул шигъри моңының беренче башлап үз авыллары очындагы «Куш чишмә төпләреннән агып чыгуы» һәм «җирдә яшәсә дә, күкрәгендә барыбер кош булуы» турында яза, йә булмаса халкы «бәгыренә еллар тигәндә, агач булып агачларның да ыңгырашып авуын» тасвирлап, «адәм башларыннан йөргән кайгы йөрер икән агач башлап та!» дигән көтелмәгән нәтиҗә чыгара.

Янә шунысы характерлы: күп кенә әсәрләрендә Х.Әюп, тагын да югарырак күтәрелеп, әйләнә-тирәлеген «заманнарның биек ярыннан торып» та тасвирлый һәм табигатькә бәйләнешле зур масштаблы образлар тудыра. Мин, мәсәлән, каурый болытны – каләмгә, зәңгәр күкне дәфтәргә тиңләгән башка шагыйрьне белмим.

Каурый болыт! Буйсын кулларыма,
Язганымны сеңдер, зәңгәр күк! –
Бу дөньяда җирнең шагыйрьләре
Әйтәлмичә киткән сүзләр күп.

Соңгы ике юлдан аңлашылганча, шагыйрь үзе, җөрьәт итеп, башкалар әйтә алмый киткән сүзләрне әйтергә алына. «Йөрәк атым» дигән поэмасы – шуның менә дигән бер мисалы. Белүебезчә, шагыйрьләр табигатьнең аерылгысыз өлеше булган ат турында заманында күп яздылар. Андый әсәрләрнең иң саллыларын мин Зөлфәт иҗатында очраттым. Әмма Харрас бу еш кабатланган темага үзенчә якын килә һәм аны үзенчә чишә. Башта ул гомерендә бер казык та какмаган ялкау батракларга, «ат күрмәгән адәм актыкларына» хакимият тезгене тоттырылуы һәм атлы крестьяннарның «кулак» дип гаепләнеп юк ителүләре

яки Себергә озатылулары турында ачынып яза. Моның нәтиҗәсе бик-бик фаҗигале һәм хәтәр булып чыга: «Исемебез генә ир-ат безнең, күптән инде атсыз калганга» ди шагыйрь, уфтанып. Ник дигәндә, атны акрынлап «Волга» машиналары, кәнәфи, хәмер һәм акча чире алмаштырган. Җигү атыңнан яздыргач, «революцион» идарәчеләр һәм куштаннар хәтта «суырып алыр өчен йөрәктәге соңгы атыңа» үрелгәннәр, денеңнән һәм иманыңнан яздырырга тырышканнар. Әмма имансыз һәм хыялсыз яшәп буламыни?! Ары таба шагыйрь «Ир йөрәгендә йөгәнле ат ятыр» дигән мәкальдән этәрелеп китеп, «ир-ат йөрәге атсыз торалмас» дип ярып сала һәм «тышауланмаган, камыт кидерелмәгән Мәхәббәт атлары кирәк», «атыгызны алып кайтыгыз!» дигән кинаяле чакыру ташлый. Шул рәвешле шагыйрь җанлы табигать образларыннан зур социаль гомумиләштерүгә барып чыга.

Х.Әюп иҗатының тагын бер үзенчәлеге шунда: ул табигатьне гаҗәеп дәрәҗәдә авыл темасы белән бергә үреп сурәтли. Чөнки ул мөкиббән китеп туган авылына, туып үскән җиренә гашыйк кеше. Дөрес, заманында әлеге авыл әнисе ягыннан указлы мулла булган бабасының (дәү әтисенең) нахакка кимсетелүенә, «кулак» дип үз өеннән куып чыгарылуына шаһит булган. Шулай ук өйләренең янгыннан исән калган имән капка баганалары да Харрас әнисенең (һәм, әлбәттә, булачак шагыйрьнең) «кулак нәселе» дип кыерсытылуларын күреп торганнар («Капка баганасы турында баллада»). Әмма соңыннан барысы да үз урынына утырган. Укымышлы бабасы һәм соңыннан, төпләнеп, әти-әнисе яшәгән нигез Харрас өчен иң изге урын булып калган. «Ата йорты – бала өчен кыйбла», «кыйбламны мин – туган туфрагымны бүтән кыйблаларга алмашмам» – менә шагыйрьнең горурланып белдергән хикмәтле фикер йомарламы. Һәм бу аңлашыла да. Авыл Харрас кебек малайларны кирпеч сукканда калыплаган, печән чапканда чарлаган, ат өйрәткәндә тезгенләгән, кичке уеннар вакытында җырга-биюгә, күңел ачарга өйрәткән. Күктәге Ай да шагыйрьнең «яшьлек сердәше», «Кояш исә – һич тә гаҗәп түгел – аның «авылдашы». Түбәндәге нечкә юмор белән өретелгән юллар шул авылдашы турында.

Озын көннәр буе Кояш – бездән,

Без – Кояштан тотам калмадык,
Озаграк чыкмый торса әгәр,
Майлы ботка биреп алдадык.

Әмма Харрас өчен авыл образы белән үрелгән иң җылы һәм иң якты Кояш, әлбәттә, Ана образы. Гел яхшылыкка, намуслы һәм шәфкатьле булырга өндәгән һәм дә өйрәткән газиз аналар – безнең барыбыз өчен дә иң изге җан. Менә шул бөек затны шагыйрь тере һәйкәл итеп пьедесталга менгерә һәм күңелендәге иң җылы хисләргә төреп, аңа Дан һәм Мәдхия җырлый. Үзенең бер рецензиясендә Фоат Садриев бик дөрес билгеләгәнчә, кешелек вөҗданын гәүдәләндерүче Ана образы Х.Әюп иҗатында туган йорт, Ватан, халык, милләт төшенчәләре белән кушылып китә һәм зур символик мәгънәләр ала. Һәм, гомумән, Ана образы шагыйрьгә иң җете, иң тәэсирле чагыштырулар һәм гомумиләштерелгән хикмәтле-эмоциональ гыйбарәләр тудырырга мөмкинлек бирә. Конкрет мисаллар китерик:

Әнкәйләрнең нигез сыңарыдыр,
Ахрысы, син, туган авылым!

яки:

Әнкәй урынына кала
Икән лә туган илләр. –

Болар гына да аз әле. Ары таба Ана кеше хәтта бөтен кешелек өчен кирәкле һәм бөтен дөньяны тотып торучы киң сыйдырышлы символ дәрәҗәсенә күтәрелә:

Төшендем мин: безгә генә түгел,
Бар дөньяга Ана икәнеңә. –

Бу, мөгаен, бала кешенең үз анасына бирә ала торган иң зур бәяседер. Кешелек дөньясының гасырлар дәвамында туплана килгән рухи кыйммәтләрен, тел һәм моң байлыгын, милли йола һәм милли гореф-гадәтләрне түкми-чәчми балаларына тапшырып һәм сеңдереп, Кеше итүче зат – безнең газиз Аналарыбыз бит! Моны Харрас бөтен барлыгы белән аңлый:

Туган җирләремнән җыеп,

Әнкәм биргән сулыштыр бу,
Изге дога, очар канат,
Кирәк чакта кылычтыр бу.

Шигърияткә сизгер күңелле укучылар аңлый торгандыр: әлеге строфадагы соңгы юллар шагыйрь иҗатының башка юнәлешенә дә юл ачып җибәрә. Табигате ягыннан Харрас никадәр генә тыйнак, әдәпле һәм эчкерсез булмасын, ул һич тә күргән-белгәннәре белән даими ризалашып, «ярхәмбикә» дип, кул кушырып торучылардан түгел. Кирәк чакта ул, үзе әйтмешли, очар канатын яки каләмен кылычка әйләндерә дә белә. «Авыл җаны» дигән поэмасы моның классик мисалы була ала. Автор анда үзе яраткан туган як темасына авыл җирендә барган соңгы үзгәрешләр яссылыгында якын килә, интонациясе дә, шуңа ярашып, берчә җитди борчылу һәм берчә кискен гаепләү рухында яңгырый. Шагыйрьнең болай борчылу һәм усаллану сәбәбе ачык: әле кайчан гына татарлык кайнап торган авылларга да, баксаң, таралу, акрынлап карт-коры төбәге булып калу куркынычы яный икән. Барысы да булмаса да, инде күп авыллар таланган, «кунак-төшем, килем-китем беткән», бала-чагаларның шатлыклы чырчуы тынган, хәтта «яшьләр белән гармун китеп барган». Ә инде кайчандыр ата-бабалары ут күршеләр булып яшәгән аерым гаиләләр, шәһәр җирендәге кебек, бер-берсен белешми башлаганнар. Алай гынамы әле!

Элек болыннарга сыймаган җан
Кысан ихатадан артмый хәзер;
Күршесендә энә артык икән –
Көнләшүдән көеп, шартлый хәзер.

Мондый аяныч хәлнең тамыр җәюе, байтак татар җанлы авылларның да мөшкел хәлгә төшеп баруы, бушап калуы өчен Х.Әюп, кайберәүләр кебек, һич тә заманны гына гаепләми. Киресенчә, моның өчен ул бәхет эзләп читкә китүчеләрне, тәне-җисеме белән шәһәрдә торса да, җаны белән туган авылында яшәүчеләрне ныграк гаепли. Соңгылар исәбенә ул, «шәһәрләшә алмаган» авыл баласы буларак, үзен дә кертә.

Ялгыз гына киткән идек тә бит

Туган өйдән чыгып киткән көздә.
Авылыбызны килер буыннардан
Бөтенләйгә мәхрүм иткәнбез лә.
Үзебезнең гаепләрне ялгыш
Бүтәннәргә япсартмагыз тагын.
Синнән-миннән башка кемнәр булсын –
Алучысы бездер авыл җанын!..

Шигырь теориясе буенча лекция укыганда, мин студентларга Лев Толстойның «Сәнгатьнең төп бурычы – кешенең һәм халыкның җаны-рухы турында дөреслекне әйтү» дигән сүзләрен китерергә яратам. Харрас шигырьләрендә, шул исәптән хәтта табигатьне, авылны бөтен матурлыгы һәм кырыслыгы белән тасвирлаган әсәрләрендә дә мин Кеше Җанының үзәккә куелганын күрәм. Чөнки алар шагыйрьнең матурлыкка да, иләмсезлеккә дә үтә сизгер күңеле, «сандугач кайгысы өчен дә җылый торган», әмма «дөнья давылларына салып тирбәтүләр»гә дә бирешмәгән куш йөрәге аша үткәннәр. Ә инде «Көзге», «Көй эзләү» кебек күләмле әсәрләрендә-поэмаларында шагыйрь, кеше рухының чын инженеры буларак, җанның тагын да тирәнрәк катламнарына үтеп керергә омтыла. Моның өчен ул баштагы әсәрендә көзгедән файдалана һәм гади көзге түгел, ә күңел һәм хәтер көзгесе генә кемнең кем булуын, җаныбызның сафмы яки шакшымы булуын дөрес итеп күрсәтә ала дигән кинаяле фикер үткәрә.

«Көй эзләү» дигән поэма, миңа калса, Харрасның Моң мотивына корылган шигырьләренең үзенчәлекле дәвамы һәм үстерелеше булып тора. Шагыйрь иҗатында моң образы гаҗәеп күпкырлы: ул орчык җыры һәм чүлпы чыңлавы да, тургай тавышы һәм каеннар шаулавы да, сагыну сагышы һәм гомер агышы да. Һәм, ахыр килеп, ул ата-бабалардан килгән атаклы «Иске кара урман» җыры да.

«Көй эзләү» поэмасына килсәк, анда Көй, күп мәгънәле булудан бигрәк, «буыннардан буыннарга күчеп йөргән бердәнбер көй» рәвешендә аңлашыла. Ләкин ул да, моң шикелле үк, кешене гомере буена озата барырга тиешле рухи юлдаш кебек кабул ителә. Алай гына да түгел, ул байлыгы өләшенгән-таланган илгә, «башы иелгән» һәм кыйбласыннан яздырылган халыкка көй-

сез дөньясын көйгә салу өчен кирәк. Шагыйрьнең фикер сөреше менә шундый нәтиҗәгә илтеп чыгара. Әмма, ни кызганыч, ул көйне без югалтканбыз, ят көйләргә алмаштырганбыз. Хәтта «Туган тел» көе дә «газиз көй бит – нигә өзелә?» дип ачыргалана шагыйрь һәм ничә еллар буена үзенең җан газабы кичереп, «кайчак шыбыр тиргә төшеп», шул югалган көйне эзләве турында белдерә. Әлеге миссиясе белән поэма авторы безнең алдыбызга бүтәннәрдән бер башка югарырак торучы һәм алар язмышы өчен янучы-борчылучы романтик рухлы лирик герой булып килеп баса. Кемгә ничектер, романтик шагыйрь җан атып эзли торган Көйне мин үзем татарның хәзерге көнгә кадәр булмаган яки табылмаган Милли идеясенә тиңләп күз алдына китерәм. Сәяси юлыбызны һәм үсеш офыкларын билгели торган милли идеябезне эшләргә кирәклеге бүген аеруча кискен булып көн тәртибендә тора. Харрас, минемчә, кинаяле шигъри тел белән нәкъ шуны әйтергә тели дә:

Күкрәгеңдә көең исән булсын,
Халыклар да бетә, көй үлсә.
Эзлик әле, гармун,
Уйныйк әле –
Яшәү юктыр ул көй өзелсә!..

Шагыйрьнең дөньяга карашы, уй-кичерешләре эпик планда һәм киң экранлы масштабта ачыла торган «Су хәтере», «Базарлар», «Биш вакыт намаз» дигән поэмалары да бар. Миңа калса, Тарих, Вакыт, Милләт, Яшәеш турында уйланулар рәвешендә иҗат ителгән бу әсәрләр үзара тоташкан бер чылбыр, киң колачлы бер цикл тәшкил итәләр. Беренче поэма маңкортлар онытса да Казан-су онытмаган канлы бәрелешләрне искә төшерүдән башланып китә. Ата-бабаларыбызның бүрәнәләргә бәйләп агызылуын да, «адәм әүлиясы Кол Шәриф һәм сатлык җан Шаһгалиләрне» дә су һаман хәтерли икән. Ары таба әлеге фаҗигагә яңалары өстәлгән: байлыгыбызны талау белән генә чикләнмичә, явыз тиран мәчетләребезне яндырган, бабаларыбызның кабер ташлары өстенә чиркәү салган, канлы куллары белән Иманыбызга үрелгән. Ахыр килеп, соңрак чор палачлары хал-

кыбызның асыл уллары булган Туфаннарны, Кәримнәрне нахакка җәзалаган. Шагыйрь безне корбанлы тарихыбызны онытмаска, уяу булырга чакыра һәм әсәрен мондый юллар белән тәмамлый:

Сулар да бер кайтачак.
Су хәтере – безнең хәтер! –
Туфан булып калкачак...

«Базарлар» дигән икенче поэма, дәүләтчелек идеясен дәвам итеп, укучыны беренче мәмләкәтебез булган Болгарның «Ага базары»на илтеп чыгара. Һәм затлы күн-мехлары, арзанлы асыл товарлары, янә дә төрле илләрдән җыелган сәүдәгәрләре белән дан тоткан әлеге базарны автор үзе бәрәңгегә чират торган «колхоз базары» белән чагыштыра. Аннары бер-бер артлы төрле заманнарның һәм төбәкләрнең базарларына сәфәр кылына. Арада «коллар базары» да бар. Монысы империячел дәүләт составында татар халкының да кол хәленә төшерелүе белән тәңгәл килеп тора. Ә инде «дөнья базары»нда сатыла торган үз нефтебезгә үзебезнең хуҗа була алмавыбыз исә бу фаҗигане тагын да көчәйтә генә. Шагыйрьнең ачынып һәм уфтанып әйткән түбәндәге юлларында нәкъ менә шундый мыскыллы-колониаль хәлебез ярылып ята:

Их, итексез калыр идекмени –
Ага базарлардан
Аерылмаган булсак әгәр?!

Ахыр килеп, «Биш вакыт намаз» поэмасы турында берничә сүз. Белүебезчә, намаз укылып беткәннән соң, мөэмин-мөселман кеше җае килгән саен дога укый, үз теләндә моң-зарларын һәм теләк-ихтыяҗларын белдереп, Алладан ярлыкау яки ярдәм-шәфкать сорый. Әлеге әсәр дә шагыйрьнең Аллага юнәлдерелгән, әмма шул ук вакытта Шәхес һәм Милләт язмышы турындагы уйлануларын да эченә алган «догасы»-лирик монологы. Анда төп сүз тоталитар режим чорында атеистик тәрбия алган һәм Алла урынына совет кумирларына яки юлбашчыларына табынган дәһри турында бара. Әмма бу кеше (аның урынына лирик

герой төсендә шагыйрь үзе сөйли) яңадан халыкка кайта башлаган дин тәэсирендә, тәүбә итеп, Аллага сыгына башлый һәм иманын үзенең чын мәгънәсендә халыкчан булган иҗаты белән дә бәйли:

Безнең өчен иман шулдыр: бу дөньяның
Карасына мана-мана җаның агарт.

Мин бу киңәйтелгән дога-монолог рәвешендәге әсәр белән атаклы грузин кинорежиссеры Тенгиз Абуладзеның «Покаяние» («Тәүбә итү») дигән фильмы арасында зур уртаклык күрәм. Ул кинофильмда да совет тәрбиясе алган кешеләр, Сталинга табынудан ваз кичеп һәм тәүбәгә килеп, дин храмына юнәләләр. Минемчә, Х.Әюп поэмасының бөтен кыйммәте дә әнә шунда, ягъни хәзерге заманда барган гаҗәеп гыйбрәтле һәм әһәмиятле үзгәрешләрне чын сәнгать ядкарьләре югарылыгында гомумиләштерүендә.

Сүземне шагыйрьнең исеме дә җисеменә туры килеп торуына игътибар юнәлдерү белән тәмамлыйсым килә. «Харрас» дигән гарәп сүзенең безнеңчә мәгънәсе – саклаучы, яклаучы. Ялкынлы иҗаты белән Табигатебезне һәм Милләтебезне яклау белән шөгыльләнүче Мөслим егетенә бу исемне Ходай үзе иңдергәндер кебек.

*Марсель Бакиров,*
*филология фәннәре докторы,*
*профессор*

# I. Су хәтере

...Бүгенгесен, үткәндәген жуйса,
Киләчәктән мәхрүм ул халык...



## ХӘТЕР

Безгә хәтер юкка бирелмәгән,
Яшәмәде халык хәтерсез;
Томаларга теләсә дә еллар,
Бәреп чыкты барыбер әйтер сүз.

Гөрләгән дә булды, дөрләгән дә –
Язып бара хәтер барын да:
Югалтырга безнең юк хакыбыз
Яманын да, яхшыларын да.

Мәкер өчен түгел безнең хәтер,
Зураймыйдыр һичкем үч алып.
Бүгенгесен, үткәндәген җуйса,
Киләчәктән мәхрүм ул халык...

Халык хәтереннән аерылганның
Яшәве дә әрәм, гел зая.
Азга гына килә җиргә кеше –
Хәтерләрдә гомер озая.

Яшералмас вакыт пәрдәләре,
Киткәннәр дә кире кайтырлар –
Безгә хәтер юкка бирелмәгән,
Югалмасын бары хәтерләр!..

* * *

Яулардан һәм сугышлардан тора
Бу тарихның калку нокталары.
Көн дә килә берәр шомлы хәбәр,
Кан коюның юктыр туктаганы.
Йөрәкләргә килеп кадалалар
Катламнардан чыккан ук очлары,
Табылалар һаман үткәннәрнең
Вакыт күмеп киткән кылычлары.
Берәр ачып күз сал юри генә –
Шыплап тулган тарих сандыклары;
Таралышып ята кыйтгаларда
Үтеп киткән мәхшәр калдыклары.
Әгәр җырың бүленмәсен дисәң,
Кабаланма, шагыйрь, уяу бул син!
Шартламыйча калган миналарга
Юлыкмасын ялгыш каләм очың...
Дәверләрне бер кичмәкче идем –
Яулар белән челтәрләнеп беткән,
Искитәрлек:
Кеше бу көннәргә
Ничек үтеп чыга алды икән?!
Ничек итеп киләчәккә барыр,
Киселмичә кайнар сулышлары? –
Бер атуда күпме гасырларны
Тишеп чыккан чакта ук очлары!..

* * *

Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлҗамал...

*Халык җыры*

Утлар яна...
Шәмнәр генә микән? –
Еракларданн төшә яктысы,
Белмим инде, ничек кенә түзә
Йөрәккәең синең... Аһ, Кеше!

Ут эчендә калган бәгырькәең
Ничек чыдый янып бетмичә?
Шәмдәлләрдә генә утлар яна...
Күкрәкләрдә янган ут ничә?!

Утлар яна...
Әллә янгын микән –
Заманнарның йөрәк янгыны?
Их! Безгә дә каба бугай инде,
Болытларга төшә ал нуры.

Күкләр яна,
Төнге шәүләләре
Тәрәз саен керә уятып.
Сүндералмый –
Җаннар янган чакта
Бер чарасыз, көчсез бу Вакыт!

Бик еракта калган шәмнәр яна,
Ничек сүнми икән бу шәмнәр?
...Киткәннәрнең йөрәк уты булып,
Киләчәккә бара исәннәр...

# КАЗАН

Талгын гына агып ята Идел,
Чыгып баскан берәү тын ярга:
Юатырга әллә чал елганы,
Йөрәгендә әллә моң барга.

Кеме калды икән аргы ярда? –
Үрелеп карый еллар аркылы.
Тоташ ялкын кичке Идел өсте,
Әйтми елга шуннан артыгын.

Агымсуда җанын юа Казан...
Якты җырлар булсын ак биләү,
Йөрәк башларыннан кан тамганда,
Яраларны бәйли «Тәфтиләү».

Легендалар булып терелгәндә,
Кемнәр килмәс аны тыңларга? –
Талгын гына агып ята Вакыт,
Әллә шәһәр, әллә моң ярда...

# МӨСЛИМ МУЗЕЕНДА

Егерменче гасыр тышта калды...
Без эчкәре уздык – үткәннәргә.
Берәм-берәм кайтып керде бире
Бу дөньяда яшәп киткәннәр дә.

Нидер эрли, нидер суга һаман
Каба-орчык, көре-тәбәлдерек[1];
Киндер сөлге ирләр белгәндә –
Михнәтләрне сала әйләндереп.

Бәрелеп сына корыч ихтыярга
Шакшы куллар, таштан авыр сүзләр –
Яши алмый Мәкер бөтен килеш:
Үткәннәрдә кала обрезлар!

Күтәрелә елга төпләреннән
Эре сөякләре мамонтларның,
Калыккандай чорлар төпкеленнән
Сынмас рухы кыю халыкларның...

Татар өе. Затлы чүпләм сөлге –
Кайсы туйга кемнәр әзерләгән?!
Урамдагы егерменче гасыр
Якты булып төшә тәрәзләрдән.

Күз генә син ташла – шул мизгелдә
Телгә килә көре-тәбәлдерек,
Пәрдә читен ача үткәннәрнең,
Әкиятне чынга әйләндереп...

Күңелләргә якты сирпеләдер,
Киткәннәр дә кайта берәм-берәм;
Гасырларга сыймый –
Бу халкымның
Үткәне дә бүген безнең белән!

---

[1] Каба, көре, тәбәлдерек – җеп эрләү, киндер сугу кирәк-яраклары.

## ЫК БУЕНДА ҖИЛ ИСӘ...

Ык буенда тын каберлек,
Ык буенда җил исә...
Искән җилдә сибелә комнар,
Сибелә берни белмичә.
Сибелә ачык ярага –
Гасырларның ярасы.
Ничек түзә археолог? –
Көяр күк пумаласы.
Сибелә комнар...
Асларыннан
Богаулы куллар чыга,
– Чишегез! – дигән шикелле,
Каршыга еллар чыга,
Салдырып ала богавын...
Җанда әрнү, газап тик:
Кемгә шатлык – ничә гасыр
Соңга калган азатлык?!
Чорларны азат иткәндә,
Чишкәндә богауларын,
Археолог бар дөньяга
Бирәдер сорауларын:
«Елларны һаман да шулай
Богаулап салабызмы?
Кемнәр килеп богаулардан
Аралап ала безне?..»
Ык буенда тын каберлек,
Ык буенда җил исә;
Искән җилдә сибелә комнар,
Сибелә берни белмичә.

* * *

Туган ягың, табигатең булып,
Табигать тә түгел ирекле:
Үз җиреңдә бүтән бер халыкның
Кышларында йөрер идекме?

Борын-борынгыдан ярларында
Битен юып үскән кешегә
Кемдер, килеп беркөн, шул елгага
Үз исемен кушып эчерә.

Богау салган сыман, каеннарга,
Урманнарга исем тагылган:
Туган телләрендә шаулый алмый
Интегәләр кебек каеннар...

Сандугачка сайратмаслар иде,
Җырлатмаслар иде башканы –
Буйсындыралмыйлар гына әле
Үзләренә сандугачларны!

Мөһер сугылудан берәр ничек
Саклап кала алыр идекме? –
Әле ярый Җилнең тезгене юк,
Әле ярый Кояш ирекле...

# КАЗАНДА ЯҢГЫРЛАР...

Казанда – яңгырлар,
Урамнар манма су...
Туктамый. Әй, күге
Тишелде тәмамсы.
Чал шәһәр, яңгыр-шәл.
Ага су, тама су –
Кемгәдер юаныч,
Кемгәдер ямансу...
Күпләргә – яңгыр бу,
Кемгәдер бу – Хәтер:
«Без дә бит кайтмаска
Китмәдек!..» – дип әйтер.
Яңгыр-шәл...
Колак сал:
Кем тама торгандыр? –
Казанны ни гомер
Табалмый йөргәндер...
Томаннар, болытлар,
Явымнар артыннан
Чыгадыр чал шәһәр
Кайтканнар каршына.
Бар дөнья манма су,
Казанда – яңгырлар.
Заманда – яңгырлар...
Әй, бигрәк ямансу!

# БОЛГАРГА КАЙТУ

Ачык булса күңел капкалары,
Үткәннәргә һәрчак юл бар ла:
Мең ел кичеп гүя, ак теплоход
Килеп җитте менә Болгарга.

Бабайларның йөрәк тибешендә
Таралганга әле кай ара?!
Юк, килмәдек – кайттык бит без бүген:
Таныйсыңмы, Кече Манара?

Әйтерсең лә имгәтелгән хәтер –
Хан төрбәсе, Кара Пулат та;
Карамагыз үткәннәргә таба,
Үткәннәрдә кара таң ата!..

Ташлар калган... Колагымны куям...
Тынлык дәшә миңа, тыңла, ди.
Кара таңны ал җырлары белән
Ертып килеп чыга Кол Гали...

Ертып чыга гасырларны Болгар,
Кайттык менә без дә Болгарга.
Мең ел кичеп гүя, ак теплоход
Кереп бара килер елларга...

# СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫНДАГЫ АЙНЫ СӘЛАМЛӘҮ

...Бу тору, әйтергә мөмкиндер,
Кояшсыз-айсыз тору...

*Габдулла Тукай*

Исәнме, Ай!
Син янәдән
Халкым манарасында,
Олактырган булсалар да
Болытлар арасына.
Дөньядан Айны мәңгегә
Каплап куеп буламы? –
Таралып килә болытлар,
Абайлыйбыз кыйбланы...
Кыен иде синнән башка:
Чор караңгы... Юк юллар...
Бик күпләрнең иманына
Кара тәре сукты лар.
Ни гомерләр Айсыз булдык –
Абынды, ауды ирләр.
Дәшми торсаң, бу дөньяда
Кояшсыз калдырырлар...
Күтәрдек сине халкымның
Күңел манарасына.
Буе җитмәсен ятларның,
Бүтән алалмасыннар!
Яктырасың –
Ничә гасыр
Татар яше юганмы?
...Кабул кыл, Ай: сиңа карап
Кылдым шигъри догамны...

# ЯРА

Әрни... Әрни... Әрни...
Басылмый ул –
Күпме еллар, ничә гасыр инде!
Яңгырлар да юды, сөртте җилләр,
Ничә кабат ак бураннар күмде...
Сары яфракларын ябып карый,
Чәчкәләрен сибә ел да җирем.
Алай гына төзәлерлек түгел,
Төзәлерлек түгел ярам минем.
Кисteләр дә тоз сиптеләр һаман,
Инде хәзер тоташ яра бит мин.
Һаман аяк өсте...
Үтерүчем
Каршысына һаман барам бит мин!
Бер адымым – бер ел.
Канлы килеш
Инде дүрт йөз утыз тугыз адым...
Ауганымны көтә...
Тешне кысып
Булса да, мин атлыйм, атлыйм тагын.
Менә дүрт йөз кырыгынчы адым...
Кыйблам бүтән минем, юлым башка.
Егылганны көтә...
Егылсаң да,
Аның аягына егылмаска!
Әрни... Әрни... Әрни...
Басылмый ул –
Әрниячәк әле миннән калып.
Заманнарга тынгылык юк икән,
Җир йөзендә яраланса халык...

*1991*

## ТЕЛ КҮРСӘТӘ...

Улым, сиңа әйтәм...
*Мәкальдән*

Исем китеп торам кайчак:
Минем йортмы, бу кем йорты? –
Балаларда – урыс теле,
Үз телләре – ярым-йорты.

«Бисмиллаһ әйт, – диләр иде, –
Авызыңа шайтан керер...»
Кайчан керде балаларга?
Без күрмәгәч, кемнәр күрер?!

Терсәк якын – тешләп булмый,
Җитми икән буй терсәккә.
Үз балаңның авызыннан
Явыз Иван тел күрсәтә...

## ҮЗГӘРЕШЛӘР ТУРЫНДА

Еллар безгә үзгәрергә куша.
Ялгышлардан, әйе, арынып чактыр.
Кайберәүләр бер көн эчендә дә
Үзгәрәләр әллә ничә тапкыр.
Үзгәрәләр йөзләр, кыяфәтләр,
Асыллары ләкин шул ук кала.
Тыштан күпме ялтыраса да ул,
Мәкерленең һаман эче кара.
Заманына бик тиз җайлашалар,
Йома барып кеше сизгән эшне.
Әйтерсең лә алар әллә кайчан
Көтеп кенә торган үзгәрешне...
Яхшырасы, яктырасы килә,
Каршы түгел мин дә үзгәрешкә.
Капыл гына күтәрелеп әмма
Тәре сугалмыймын узган эшкә.
Хыялланып күпме яшәдек без –
Элек ният яман идемени?
Игелек кыл, диеп өйрәттеләр –
Бөтенесе ялган идемени?!
Чыгарып соң ничек түкмәк кирәк
Гомерең буе җанга җыйганыңны?
Стенага терәп атсалар да,
Алыштыралмыймын иманымны!
Үзгәргәннәр, әйдә үзгәрсеннәр,
Яңарсыннар. – Шулай тиеш, димәк.
Ләкин үзгәрешләр чорында да
Үзең булып кала белү кирәк...

## ҮЗ-ҮЗЕМӘ ГЕНӘ ТҮГЕЛ

Әле шөкер – өстем бөтен, тамагым тук,
Икмәк сорап елап торган балам да юк;
Юлым туры, уңга-сулга карамыймын,
Юк-бар уйлар керми башка, зиһен аек.

Җырласам да, тыңламыйлар – җырсыз яшим,
Теләгәнчә кимсетсеннәр – бер сүз дәшмим;
Үз дигәнчә яшәүчеләр җирдә күпме! –
Баш ияргә бер күнеккәч, һич көнләшмим.

Акылсызлар дәгъвалашсын – акыллы мин,
Кемгә биргән тагын мондый акылны, дим;
Сүзең – көмеш, тик торуың – алтын икән,
Ычкындырмыйм әле кулдан алтынны, дим.

Колак какма өлешеңнән, эләктер син,
Шуның өчен яратылган йөрәктер син;
Тарихыңны күмәр өчен кирәк кирәк –
Мондый эшкә бик тә кулай көрәктер син!..

# АВЫРТКАН ҖИР

Авырткан җир бәрелүчән була,
Тагын бәрдек сине, милләтем!
Чорга бәрдек,
Игелексез чорга,
Ничек түзәсеңдер син ятим.
Наркотиклар кадамакчы сиңа,
Чыгып басып кемдер мөнбәргә,
Күзләреңә карап алдамакчы...
Сөяк-фәлән юк шул телләрдә.
Авырткан җир бәрелүчән була,
Бу юлы да саклый алмадык.
Сизмәмешкә күпләр салындылар,
Дәрәҗәгә, малга алданып.
Мәнсезлекнең аның милләте юк,
Кемдер бәрә – халык сызлана:
Башкаенда йөрер йөз төрле уй,
Йөрәгендә сыкрар йөз яра.
Замананың башы авыртмый шул...
Булмаган баш ничек авыртсын!
Барсына да эндәшмичә түзгән –
Без бу чаклы нинди халык соң?!
Әллә халык, әллә кара сарык:
Тел – йозакта, язмыш – киртәдә.
Авырткан җир бәрелүчән була, –
Кая бәрелербез иртәгә?

# СУ ХӘТЕРЕ

## (Поэма)

Суның да хәтере бар...
*Картлар сүзе*

Ышкылгандай шәһәр диварына,
Ни гомерләр ага Казан-су! –
Магнитлы тасма сыман,
Безнең
Язмышларны язып алган су.
Вакыт чорный барган...
Болганса да,
Җуелмыйдыр сулар хәтере;
Кырылышып бетсә бетә халык –
Су бетмидер...
Мәңге ул тере!
Дошман сөенмәсен – маңкортларга
Әйләнде, дип, халык уллары,
Киләчәккә ага Казан-елга –
Онытмагыз әле ул барын...

*

Күрәчәгең булгач, күрми хәл юк –
Елга ничек йөзен капласын?
Хәтерләүләре дә – авыр газап
Ул көннәрне...
Алла сакласын!
...Ничәнче көн камалышта шәһәр,
Кальга өсләрендә ак төтен...
Сиңа шатлык каян килсен, Казан,
Сатлыклардан булгач бәхетең?!
Исәнгерәп кинәт, чайкалды көз,
Тыныч елга тетрәп аһ орды.
Сатлыкларның шакшы кулы белән
Шартлаттылар ничә гасырны!

Адәм әүлиясы Кол Шәрифнең
Су өстендә ап-ак шәүләсе.
Шагыйрьләрнең өлеше –
Халык өчен
Шәһит киту микән әллә соң?!
Ходай кушмагандыр бу язмышны,
Башкисәрләр безгә кушкандыр –
Илдән иман, ахры, Кол Шәрифләр
Җаны белән бергә очкандыр...
Урамнардан кызыл гөрләвекләр
Кушылдылар төшеп суларга:
Сулар хәтеренә Казан-елга
Канлы тасма булып чорналган...

*

Белеп торам: «Язганыңда
Су күп», – диячәкләрен...
Нишлисең инде сулардан
Булгач күрәчәкләрең?
Узган гомерләр – суларда,
Алар шаһит барына.
Качып китә Шаһгалиләр,
Сулар салып дарыңа.
Шәһәрне ничек саклыйсың
Чыланган дары белән?
Ул суларны кая куйыйм
Язмыйча бары белән?!
Белгәннәр суның куәтен.
Су белән булашканнар –
Казанны бер йотым сусыз
Итәргә тырышканнар.
Капма-каршы ике көчтер:
Берсе – су, берсе – дары...
Чишмәне шартлаткан чакта
Очрашкан алар тагы.
Бәхет дип сөйләнеп, бүген

Кемнәр ул дуамалланган? –
Халыкның гомер чишмәсе
Шул чактук томаланган...
Язарга кызык булганнан
Су кушып язмыйсың ла! –
Нишлисең, сулар күп булгач
Халкыңның язмышында?!
Шаһгалиләрнең гасырлар
Узып та беткәне юк.
Бар бездә дары... Тик аның
Әле дә кипкәне юк...

*

Кеше түгел бит ул онытырга –
Хәтере бар суның, хәтере бар,
Безнең ише хәтерсезләр өчен
Кире кайта-кайта әйтере бар.
Муеныннан бүрәнәгә бәйләп
Агызылган ирләр сүземе әллә?
Сабыйларның елашуы микән? –
И бу елга сабыр, түзем әле дә!
Бөтенесе инде кырылып беткәч,
Әче күз яшьләрен эчкә йотып,
Ахыр чиктә чыга хатын-кызлар
Илбасарга каршы хәнҗәр тотып...
Ела, Казан!
Ятим урамнарың
Ул чагында елый алмагандыр –
Сабыйларга хәтле каны аккач,
Яшен түгәр кеше калмагандыр.
Кырык җирдә кырылышып яткан
Татарларга кемнәр Ясин чыксын?
Мөселманнар килеп дога кыла
Менә бүген – ничә гасырдан соң?
Аккан сулар онытала диме
Ул суешны газиз каласында?

Ела, Казан! –
Таман бу кайгыңа
Ничә гасыр әле еласаң да!..

*

Ышкылгандай шәһәр диварына
Сулар аккан –
Сора сулардан:
Мәчет хәтле мәчетләрне тиран
Урыныннан нигә кубарган?
Йөрәгеңә чиркәү салып куйган,
Сызламасын нигә йөрәгең?!
Болгарыңда чиркәү –
Бабайларның
Кабер ташы белән түләдең...
Талап җыйган алтын-көмеш җитми,
Кирәк аңа синең Иманың –
Канлы кулын Иманыңа сузган,
Хөкемдары булып дөньяның.
Иван белән ярашмыйдыр Иман,
Хак Иманга барыбер кер кунмый...
Каеннарга кушып карый исемен –
Ә каеннар һаман чукынмый!..
...Үз юлыннан сулар ага торган,
Ә суларга бары да язылган.
Бу халыкның рухын сындырырга
Теләүчеләр әллә аз булган?!
Җимерелми калган Сөембикә
Манарасы кыяфәтендә
Ул бүген дә басып тора әле,
Яңа эзләр уя хәтергә.
Манараның үткен очы ерта
Кемнәрнеңдер мин-минлекләрен –
Шәҗәрәле була явызлык та...
Инде күпме авыз иткәнең!
Түкми-чәчми барсын салып бара

Агышына.
Сулар – хәтерле.
Аккан судай нигә озын булды
Безнең кимлек? – Сулар әйтерме?

*

Уйланабыз суга карап,
Үткәнне сагынабыз,
Туры килдек лә суларның
Айкалган чагына без,
Актарылган чакларына...
Бөтереп ала дулкын.
Чыгырдан чыккан суларның
Белә идек тә холкын,
Белгән көенчә дә, һаман
Саламга ябышабыз
Заманага ябышыр чакта...
Ялгышсыз ялгышабыз!
Кая карасаң да – сулар,
Биш диңгез порты – Казан –
Агасы икән лә безгә
Кайсы диңгезгә табан?!

*

Кемнәр генә җырламады
Бу бәхетсез нигездә:
«Минем дә кайгыларымны
Илтеп сал, дип, диңгезгә...»
Агызып алып киттеләр,
Авырсынмады сулар –
Халыкның кайгы-сагышын
Көн дә төн ташыдылар.
Ташыдылар...
Әллә нигә
Бетмәде кайгы гына –

Әнә тагын кемнәреңдер
Иленнән аерыла.
Суларга төшә шәүләсе
Кремль төрмәсенең...
Хәлеңнән килсә, и елгам,
Язмышка бирмәс идең
Асыл егетләрен илнең –
Туфанын, Кәримнәрен...
Кемнәр белсен нидән болай
Ярларга бәрелгәнең!
Су буйларында – авыллар...
Сулар ник ашыктылар? –
Корбанлы еллар кайгыны
Көн дә төн ташыттылар...

*

Идел... Кама... –
Сулар тоташ,
Беләсең, су, беләсең!
Туган авылын эзли берәү –
Кая борсын көймәсен?
Тирәндәме өй урыны –
Ташлансынмы ташкынга?
Ата-баба сөякләре
Кайсы дулкын астында?
Әллә чынлап та аларның
Җаннары тере микән –
Акчарлак булып, суларга
Сугылып йөри микән?
Ник болай хөкем иттеләр
Үзеңнән башка гына? –
Куялмыйсың башкаеңны
Нигезең ташларына...
Ничек хөрмәтләмәсен дә
Сулар,
Ничек белмәсен:

Кеше дип йөртәләр иде –
Әверелдең кемгә син?!
Чакырган җиргә барасың,
Куган җирдән китәсең...
Куган җирләр – Туган җирең
Булса, ни хәл итәрсең?

*

Сулар белән гел янәшә бит без,
Чагылабыз гүя көзгедә.
Бер сорарлар әле, таптырырлар –
Хәтерләп кал, дулкын, безне дә!
Ком кудыра иде земснаряд,
Камышлары Казан-елганың
Тирбәлделәр җилдә... –
И газиз су!
Яулыгыңны кемгә болгадың?
Дәшми-тынмый гына сулар ага,
Ага хәтер сулар эзеннән.
Кадер беткән чакта хәтерләр дә
Кала икән чыпчык тезеннән...
Кемлегебез чишмәләргә яздык,
Суга салдык күпме байлыкны!
Эремәде суда ул гөнаһлар –
Үлгән
Балык булып өскә калыкты.
Саекса да хәтер, еллар тирән –
Үзебезгә чоңгыл казылган.
Хәтерләп кал, дулкын: килер язмыш
Сәнәк белән суга язылган.
Кеше күзе үтерүчесе йөзен
Алып кала, диләр, үзендә.
Китеп бара сулар –
Безнең шәүлә,
Безнең сурәт сулар күзендә...

*

Гасырлар икән бит синдә...
Аңладым, су, аңладым:
Безнең болай булуларда
Гаебе юк Алланың!
Мулла да, кулак та түгел
Кешеләрнең дошманы,
Хак дошманың – үткәнеңне
Онытырга кушканы.
...Су буйларына төшәсең,
И, сулар бар әле дә! –
Кемнәр кергән булыр иде
Бу халыкның хәленә?
Иделеңнән аермасын! –
Шуны телә иң элек,
Болай да бит бар дөньяга
Бетә яздык сибелеп...
Җирдәге бар сулар тоташ,
Аксалар да кай таба,
Аккан сулар кире кайтмый,
Диләр дә бит... Кайтала!
Явызлыкта чама беткәч,
Сулар да бер кайтачак.
Су хәтере – безнең хәтер! –
Туфан булып калкачак...

# БАЗАРЛАР

*(Публицистик поэма)*

## 1. Базарга бару

Нихәл, базар халкы!
Иминлекме?
Бәрәкәтле булсын сәүдәләр...
Йөргәләдем мин дә базарларга,
Булмасам да, болай, сәүдәгәр.
Арба тартып онга бара идек...
Бәрәңгегә, иткә киленгән...
Яшелчәгә, җиләк-җимешенә...
Ни хак гомер? – Хәер, кем белгән!
Алып-биреп сатулаша халык.
Базар бәяләре төрлечә.
Әйберенә, кешесенә карап
Үзгәрә ул көнгә берничә.
Кемнәр маһир – шуларныкы базар –
Кайсы үткенрәк, кем ушлы.
Сатып була монда... Була сатып –
Сатып алып булмый... Намусны!
Кайный базар...
Берни аласым юк.
Болай гына килдем бу юлы.
Шигырь әйтер чорлар инде узган...
Җитмәс иде барыбер кыюлык.
Базар карап йөрү – борынгыдан
Бабайлардан калган бер гадәт.
Илнең хәлен базарлардан белеш –
Йомышсыз да йөрим кергәләп.
Белешкәлим әйбер бәяләрен,
Булмасам да, болай, сәүдәгәр...
Сөйли базар, бөтенесен сөйли,
Колак салсаң бераз син әгәр.

## 2. Колхоз базары

Илнең хәлен базарлардан белеш...
Саекты шул базар, саекты.
Өстәлендә булсын –
Буш сүз белән
Сыйлау нигә бүген халыкны?
Илне базар ясап,
Ничә еллар
Сатулашып гомер уздырдык.
Күкрәк кагып,
Бөтен дөньясына
Кычкыручы җирдә – без булдык.
Арта барды яшәү бәяләре –
Бар тапканың түләп аласы,
Гомер – кыйбат...
Ил каршында гына
Арзан тора адәм баласы!
Шул кадерсез башны базарларга
Алып чыга, баса чиратка –
Җитми кала.
Өйгә буш кул белән
Кайтып керү – хурлык ир-атка.
«Булдыклылар» тапмый калмый малны:
Яшерен көч кулда – мафия!
«Җирдә бүтән тиңе булмаган» ил
Мафиягә бүген баш ия.
Үзгәрергә бер дә охшамаган,
Чират тора халык әле дә.
Үкенәмен кайчак
Илнең хәлен
Базарлардан белешкәнемә...

## 3. Печән базары

Бик тә кирәк булгач, әрсезләнеп,
Вакытлардан фәрман сорадым –

Чикне үтеп,
Төрле заманнарның
Базарына барып чыгамын.
Иске Казан...
Печән базарында
Ит чабалар, җиңне сызганып...
Елый базар әһле –
Кисекбашны түгел,
Безнең башны, ахры, кызганып.
И беркатлы халык! –
Төреп алып,
Карәхмәткә тагын ялына...
Пәһлеваннар нәрсә бу заманда
Безгә килгән бәла алдында!
Печән базары шул... –
Колхоз базарларын
Каян килеп, ничек аңласын?
Ул Алласын белә.
Безмени соң –
Үз Алласын нигә алдасын?!
Ни теләсәң – шул бар.
Халык йөргән
Базарларның берсе инде ул.
Иртә көлгән Тукай –
Менә безнең
Заманнарны күрсен иде ул!

## 4. Әмәкәй базары

Ике хатын бер арбада –
Базар юлы ерак.
Күрәчәктер – бирде колхоз
Икесенә бер ат.
Берсе: «Икмәк кыйбат булсын», –
Диеп теләп бара.
«Ничекләр он алырмын?» – дип,

Берсе елап бара.
Колхоз рәисе кызы
Сата пешкән икмәк...
Биш балалы хатын – юклык
Белән газап чикмәк.
Икәү бара бер үк атта,
Ике якка карап...
Ниләр кылсын бүген базар? –
Эшләр аның харап.
Килә халык авыллардан –
Кемнәргә ярасы?
Күбесенең утырганы –
Аптырау арбасы.
Налогларын түләсенме,
Сатып мал-туарын? –
Ач балалар калды өйдә,
Көтеп кайтуларын.
Барлык белән йөрми кеше,
Куа аны нужа.
Ни эшләмәк кирәк; – Илгә
Ул – бердәнбер хуҗа.
Ике язмыш бер арбада –
Базар юлы ерак.
Берсе сата, берсе ала –
Икесенә бер ат...
Кемнең хакын хакларга соң? –
Аптырауда базар...
...Юк ул хәзер.
Таралганмы
Әллә шуңа-мазар?!

## 5. Болгар. Ага базар

Киләчәктә әле синең хакта
Ибне Фадланд, Мәрҗаниләр язар...
Казан тарафыннан бу фәкыйрьне

Кабул итче бүген, Ага базар!
Шаклар катып сөйләр заманына –
Үз күзләре белән калсын күреп.
Ят бер кавем баласыдыр диеп,
Читкә тибә күрмә аны берүк.
Бетерүгә хөкем ителгәндер... –
Ул да шушы болгар нәселеннән.
Каннан канга күчеп, хәтеренә
Ерак бабалары яшеренгән.
Базарларын эзләп килгән менә...
Сәйран кылсын синдә, күрсен-белсен,
Биредәге затлы әйберләрнең
Казанында күрәсе юк берсен!
Арзан гына затлы күн һәм мехлар...
Барсын күрү аңа кыйбат торыр –
Ул яңадан колхоз базарында
Бәрәңгегә ничек чират торыр?!
Византия... Рум... Төн илләре...
Кытайлылар монда, гарәп, урыс,
Еракларга киткән якты даның
Акылыңа сыйдырырга тырыш!
...Җитәр, Ага базар!
Газаплама –
Фәкыйреңнең кире кучәсе бар:
Бөек Болгарыңнан киләчәккә –
Мескен Казанына төшәсе бар...

## 6. Коллар базары

Эш ирләре – богауланган килеш,
Сатып алыр килеп кемнәр генә?
Җарияләр... – бәйләп куелганнар
Бер-берсенең нәфис беләгенә.
Гаиләле коллар...
Язмыш ачык –
Баласы да кол буладыр колның.

Каян килсен затлы беләзекләр,
Богау өчен яратылгач кулың?
Колларны бит элек заманнарда
Сатканнар, дип өйрәтәсең, Тарих!
Ялгышмыйсың микән бераз гына –
Коллар арасында мин дә бар ич...
Сорамыйлар ничек яшәвеңне,
Хуҗаларга синең көчең кирәк.
Дәшми генә башыңны и. Илдә
Кол булмыйча калган кеше сирәк.
Оныт үткәнеңне.
Азапланма
Халык, милләт, туган телем, диеп.
Ни кушсалар, эшлә күндәм генә,
Конституцион богау киеп!
Юньле коллар элек баш күтәргән.
Алардан да, ахры, түбәндер без –
Яңагыңнан ут күрсәтеп торткан
Кулны үбәргә дә җирәнмибез.
Базар тулы коллар...
Мин дә шунда –
Шул ирекле коллар базарында.
Сата безне мәрхәмәтсез заман.
Чит җирләрдә түгел – Казанымда!..

## 7. Кошлар базары

Чарасыздан кылган сәфәремнең
Якынлашкан чакта азагына,
Ялгыш кердем бугай билгесез бер
Атаудагы кошлар базарына.
Көтү-көтү –
Берсе килеп төшә,
Берсе дәррәү күтәрелеп китә.
Кычкыралар – аңлашылмый гына,
Тынып тормый шау-шу кич һәм иртә.

Сатучысы да юк, алучы да –
Бөтенесе тигез бу базарда.
Океан кичкән чакта азга гына
Тын алырга туктап уза бар да.
...Без дә кошлар идек бу галәмдә,
Җир исемле иде безнең атау...
Мәңге шунда – шул базарда калдык,
Ясалгандыр нинди космик хата?!
Дөнья – тоташ базар...
Анда хәзер
Бары да үтә, үтә – ни сатасың.
Илен сата кеше, телен сата,
Күз дә йоммый сата үз атасын...
Таный алмый йөрим кешеләрне,
Кая килеп чыктым, нишләдем мин? –
Сәфәремдә, кошлар базарына
Диеп кенә, бире төшкән идем.
Кычкыралар...
И аңларга иде –
Сатмыйлар шул кошлар үз телләрен!
«Кешеләргә әйләнмәскә!» – диеп
Кисәтәләрме әллә бер-берләрен?..

## 8. Сорочи базары

Куып таратып та карадылар,
Шәһәр читләренә сөреп тә –
Бетмәде ул...
Якшәмбеләр җитсә,
Мохтаҗларны үзенә йөгертә.
Бер булса да – берәгәйле базар:
Бөтен шәһәренә билгеле.
Илдә юкны табалсаң да анда,
Кимсетә соң нигә гел мине?
Базарлардан таныйм илнең хәлен,
Заманаының йөзе – базарда.

Толкучкалар – юклык хикмәтедер,
Каян юкса болай азарга?
Кирәгеңне әллә кайдан эзләп,
Кибетләргә чабып талчыкма,
Сатып алаласың өч бәягә –
Ил байлыгы шунда – Талчукта.
Талаулардан гарык булган иде,
Көткән иде халык бүтәнне –
Бу үзгәреш шул ук оятсызларның
Базарларын гына күтәрде.
Энә төшәр урын табалмассың,
Төрткәләшә базар, айкала.
Шундый хәлеңдә дә нигә, илем,
Купшы сүзгә синдә җай кала?
И сабыр да икән мескен халык...
Ышанырмы һаман – чыдармы?
Нигә әле коммунизм юлы
Толкучкага илтеп чыгарды?!

## 9. Дөнья базары

Язды шагыйрь:
«...Татарстан, мənə
Күр, кайларга илтә товарын...»
Танып була, була үз малыңны,
Бер әйләнсәң дөнья базарын.
Европаның нефть тамырында –
Татарстанның йөрәк тибеше.
«КамАЗ»ларның безне бар дөньядан
Әйләндереп кайтып килеше.
Затлы мехлар...
Дөнья каршысына
Күрсәтергә генә куймаган.
Кулың алтын булса, товарыңны
Сораталар әллә кайлардан.
Итекченең ләкин итеге юк...

Халык шулай җырлый өйрәнгән –
Гомер буе үзе иген иккән,
Арба тарткан үзе, теләнгән.
Үз малына хуҗа булалмады
Беркайчан да илдә татарлар.
Бил генә бөк –
Тапкан табышыңны
Синсез дә бик әйбәт сатарлар.
Энәңне дә әрәм җибәрмәсләр,
Монда малны таный беләләр!
Их, итексез калыр идекмени –
Ага базарлардан
Аерылмаган булсак без әгәр?!
Кешечә бер яшәп карар идең,
Татарстан – кесәң бик такыр.
Әле генә дөнья базарында
Булган, диеп, сине кем әйтер?!

## 10. Базардан кайту

...Җирдә базарлар күп.
Бу сәфәрдә
Мин барсын да йөреп чыгалмам.
Хурлануга чыдамастыр каләм.
Ул чыдаса – үзем чыдамам...
Илнең хәлен базарлардан белеш –
Сөйләделәр инде, сөйләде...
«...Рәхәт тормыш – бездә генә», – диеп
Җырлый идең юкса син әле!
Җирдә халыклар күп.
Синең кебек,
Синең хәлгә төшкән бармы соң?
Берни аласым юк, дигән идем –
Ничек итеп гыйбрәт алмыйсың...
Кирәк икән базар карап йөрү,
Булмаса да, болай, алырың.

Базар халкы!
Үпкәләмә миңа –
Кемлегеңне әйтеп калдырдым.
Яман теләк теләмәдем сиңа,
Йөрәгемә төбәп ук атма.
...Гомер кыйбат!
Аңа да бит чират...
Чиратыңны берүк югалтма!..

# II. Гомер сандыгы

...Оныкларга кала гомер-сандык,
Эчләрендә аның ни ятыр?!



## ГОМЕР

Бер башында сабый бала –
Чәчләре житен генә:
Әллә кайларга житәсе,
Йөгереп китсен генә!

Бер башында йөзьяшәр карт,
Ак сакалын җил тарый,
«Их, куып җитсә шул бала!..» –
Каерыла да карый,
Каерыла да карый...

* * *

Япа-ялгыз яланнарда йөрим:
Берүземә күпме яктылык!
Кул тимәгән гөлләр никадәрле...
Күкләремдә күпме ак болыт!

Ничә төрле кошлар сайрап тора –
Миңамы соң болар барсы да?
Бутамадың микән, и Табигать,
Мин кем әле синең каршыда!

Җәберсенеп калган чакларымда
Кул бирәсең миңа – малайга.
Зурлыгымны оныттырмас өчен,
Янәшәмдә син бар алай да...

# БОЛЫН

Болын түрләрендә ал рәшә,
Җәйге ялкын капкан болынга.
Җилфердәшеп яна алсу җырлар –
Кем хакында,ниләр турында?

Күтәрелеп астан, бик тирәннән,
Гөлләр буйлап үрли югары, –
Нинди моңга, кайсы бәгырьләргә
Кагылалар минем кулларым?

Кайсыгызның күңел аклыклары
Ак чәчәкләр булып яктыра?
Нинди хыял шытып чыкты икән,
Кулын сузып өскә, яктыга?

Болын өсләрендә ал рәшә,
Уйнавына исең китәрлек! –
Тирбәлешеп басып тора гөлләр,
Заманнарны күккә күтәреп...

## АК МЕТЕОР

Бер күренеш китми хәтердән:
Идел. Ак «Метеор». Аксыл эз.
Сызылып узган чакта су өсләп,
Дулкыннарга төшә яктыбыз.

Катлам-катлам текә ярлар да
Сузылып яткан Идел өстенә,
Әйтерсең лә елга бер тында
Дәверләрне кыеп төшергән.

Карап калды безгә Мезозой,
Палеолит... Бозлык... Таш гасыр...
Яр башында ап-ак каеннар –
Соңгы дәвер, безнең яңа чор.

Вакыт җәясеннән ычкынган
Уктай оча безнең «Метеор»,
Елга буйлап барган чагында
Ышкыла күк җанга ике яр.

Сызылып кала аксыл эз генә,
Дулкын кага ярга ишелеп.
...Ак метеор чорлар өстендә –
Балкып узып бара Кешелек...

* * *

Җир-суларым иркен сулап ята,
Кырларымда иген өлгерә.
Сайрасыннар әйдә – кошларыма
Җырларымны бирдем өлгегә.

Колачымны җәеп чыгып басам:
Болытларым килә, җилләрем...
Кешеләрем – йөрәк түрләремдә, –
Һичбер вакыт ятка бирмәмен.

Күкләремне карап кына торам,
Гел янымда кояш-айларым.
Һич зарланмыйм керфек какмасам да –
Бу язмышны үзем сайладым.

Китә алмамдыр җирдән,
Юкса дөнья
Кемгә калыр, нигә юлыгыр?
Яз-көзләрем барлап чыгыйм диеп
Йөрү генә минем бу гомер...

* * *

Үрләде таң офык читләреннән, –
Кабындылар каен башлары.
Сиздермичә генә ярала көн,
Бүлдермәскә сандугачларны.

Өр-яңа һәм иң борынгы телдер –
Сөйли урман туган телендә.
Энҗе ява үлән башларына
Кош сайраган агач төбендә.

Тирәкләргә түгел,
Сандугачлар
Йөрәкләргә кунып чутылдый,
Һәр тойгыны сыйдырырлыктыр ул –
Каян алган кошлар бу телне!

Берәр вакыт без дә гел шул телдә
Сөйләшербез, бәлки, кем белә?!
...Иң кадерле серен сөйли урман
Халыкара бөек тел белән...

* * *

Белеп торам: елау – бәхет түгел,
Кызыкмыйдыр һичкем елауга;
Тик шунсы бар – безнең бу гомердә
Бәхет түгел елый алмау да.

Елаган чак – иң саф мизгелләре,
Илаһи бер хәле җаннарның;
Биеккәрәк күтәрелгән чагы
Гамьсезлектә калмаганнарның.

Юк, сөенмим кеше елаганга,
Һәм шатланмыйм еламаганга.
Мин бәхетле – еламаган чакта,
Мин бәхетле – елый алганда.

## ЯЛГЫЗЛЫК

Җил сызгыра чигә чәчләреңдә,
Офыкларга күзең төбәлгән;
Гомер сиңа бүген көлмәк чигә
Әллә нинди моңсу көйләрдән.

Тынлык өсләренә сузып куйган
Үзәк өзгеч нечкә җепләрен,
Хәтердәге газиз мизгелләрнең
Сагыну белән кайый читләрен.

Баш очында төпсез зәңгәр күкләр –
Тавышларың китеп югала.
...Йөрәгеңнән кысып тоткан җиһан,
Түзәлерсең микән, и бала?!

* * *

Күпме генә озак яшәмәсен –
Юк, бер гомер бик аз кешегә,
Шуңадыр ул, бәлки, чордан чорга
Әкиятләр булып күченә.
Ерак кардәшләрем!
Күрәләрме,
Аңлыйлармы безне, дисезме?
Әкият итеп, хыял итеп түгел,
Исән итеп тоям мин сезне.
Әллә каян, тирән катламнардан
Бәреп чыккан чишмә шикелле,
Әкиятләр миңа сезнең җаннан
Таралышкан моңны китерде.
...Гаҗәеп бер әкият эчендә без:
Сөенәбез... Газап чигәбез...
Янып көл булабыз...
Ул әкияттән
Китмибез соң әле нигә без?
Борынгылар үз әкиятендә калган,
Үз диюен җиңгән һәр Алып...
Безнең әкияттән дә бер яктылык
Китәр сыман җиргә таралып.
Җирдә яшәгәннәр әкиятне дә
Калдырырга тиеш җылытып.
Гаҗәеп бер әкият эчендә без –
Бер сөйләрләр, бәлки, чын итеп...

## Мәрхәмәт

Каннан – канга, җаннан җанга күчеп,
Килеп җиткән безгә Мәрхәмәт,
Күңелләргә ул кагылды исә,
Үзгәрә дә куя бар халәт.

Эреп китә таштай бәгырьләр дә,
Канатлары аның тигәндә;
Күтәрелгән балта туктап кала,
Инде килеп төштем дигәндә.

Җир йөзендә күпме җан иясе,
Ничә йөрәк аңа бурычлы –
Эреткән ул күпме ядрәне
Һәм сындырган күпме кылычны!

Кил, Мәрхәмәт,
Җирдә һәр Усаллык,
Һәрбер Мәкер калсын җиңелеп;
Дошманыма, дусларыма кил син,
Үземә кил ләкин иң элек!..

* * *

*Улым Айдарга*

Нәселемнең мин бер тәрәзәсе –
Киереп ачып куйган дөньяга,
Карап тора әллә ничә буын:
Җир йөзендә нинди моң ага?

Әткәмә һәм ерак бабайларга
Мин быелгы җәйнең гөлләрен,
Урманнарын, суын күрсәтәмен,
Улларымның ничек көлгәнен.

Керфек какмый кайчак төннәр чыгам –
Күрсеннәр, дим, таңнар атканын,
Алар белгән көйнең ничек итеп
Киләчәккә күчкән чакларын...

Күзләремне мин дә бер йомармын,
Соңгы төсен алып бу юлның.
Буыннарның өмет-карашлары
Күзләренә күчәр улымның.

Шул күзләрдән мин дә текәлермен
Бу дөньяга, сагынып-җирсеп бер –
Нәселемнең ачык тәрәзәсе
Киләчәктәнниләр күрсәтер?!

# ҖЫЛЫ КИЛӘ

Араларда ничә мең ел –
Бабаларым ерак-ерак,
Аргы башта – алар җаны,
Ә биредә – минем йөрәк.

Еллар буйлап тамырлардан
Җылы килә, җылы килә,
Теге башта ни хәлләрдер –
Сагышлары, моңы килә.

Бирге башта – минем йөрәк,
Килер чорда – оныкларым;
Белерләрме гомерләрен
Нинди дулкын җылытканын?

Араларда ничә мең ел!
Җылы исән, юлы исән:
Кемдер сыкрар киләчәктә,
Әгәр бүген мин егылсам.

Сагышларым эчкә йотам –
Бәгырьләрен яралар дим:
Сизмәсеннәр гасырларга
Таралышкан балаларым!

...Дөнья буйлап тамырлардан
Җылы килә... җылы килә, –
Мәңгелекнең Кеше дигән
Кабатланмас моңы килә...

## ГОМЕР САНДЫГЫ

Ак калайлы гади зәңгәр сандык,
Сандык эчләрендә ни ятыр! –
Ачкан саен, үткән кире кайтыр,
Керфек очкайларын чылатыр.
Кыз чакларның олы истәлеге –
Ука күлмәк, көмеш беләзек;
Булган икән, ай-һай, билләр нәзек,
Кадерләрен, ахры, белмәдек...
Кершән-иннек бүләк иткән иде,
Тотылмаган гел дә диярлек. –
Әйтелмәгән икән күпме сүзләр,
Тынып калган шуңа ияреп...
Тәүге чәче, нәни башлыгы бар,
Ләкин улың күптән үзе юк,
Болыт түгел Көнбатышка аккан, –
Хәсрәтләрең бара сузылып.
Кызларыңның язган хаты исән,
Орден-медаль – ирең калдырган...
Хәтер кебек, тулган тыгызланып, –
Шул сандыкта икән бар булган!
Өләшәсе күптән барлап куйган,
Әзер инде үлемтегең дә;
Тик... җибәрми тартып тора һаман, –
Нәрсәдер бар сандык төбендә:
Ачкан саен кагылыр ул җанга,
Төшләреңә кереп уятыр, –
Оныкларга кала гомер-сандык,
Эчләрендә аның ни ятыр?..

# ҖӘЙГЕ АГЫМ

Яп-якты көн.
Идел буйларыннан
Сулап туймас дымлы җил килә.
Аксылланып тузгый яшел таллар,
Тирбәлә җәй моңлы бер көйгә.

Урамнарга керә җәйге агым,
Түтәлләрдә ауный, юлларда...
Сабырлыгын җуеп сарыла ул
Җиңел күлмәк кигән кызларга.

Айкап уза ишегалларыннан,
Йолыккалый ап-ак керләрне;
Сизми сабый ачык тәрәзәдән
Нинди төшләр агып кергәнне.

Алып чыга шәһәр өсләренә
Уйнаклатып карлыгачларны;
Елатканчы, юатканчы чайкый
Моңлы җанны, зарлы башларны.

Мәңгелек җил җирдә, мәңгелек сил –
Беркемне дә юктыр онытасы.
...Башларымнан сыйпап уза гомер.
Яп-якты көн.
Җәйнең уртасы...

# ТЕЛ АЧКЫЧЫ

Байлык-фәлән теләмәде безгә,
Кичерсәк тә гәрчә кыен чак –
Тел ачкычы тели иде әнкәй,
Берәребез юлга җыенсак.
Җаныбызга салып шул ачкычны,
Сәфәрләргә киттек өйдән без.
Серле ачкыч булган икән лә ул,
Адашмадык дисәм нидән без.
Ачып кердек күпме күңелләрне,
Серен белдек күпме бикләрнең!
Бәхетсезгә әйләнгәнен күрдек
Туган телен үги иткәннең.
Игелегең кабул итмәсләр күк,
Үзеңә кайтыр сыман – ук атсаң.
Гасырлардан күчә-күчә килгән
Бу ачкычны әгәр югалтсаң.
Тел ачкычы тели иде әнкәй,
Бүтән тагын нәрсә теләсен.
Туган телем!
Белгән бит ул минем
Ни кылсам да сиңа киләсем...
Байлыгымның олылыгын тоеп,
Ышанып керәм якты көнемә.
Дәверләрне ачар ачкычым бар –
Рәхмәт яусын туган телемә!

# ОЧУ

Төшләремдә очканымны күрәм –
Карасана: мин бит канатлы!
Кеше заты шул канатлар өчен
Күпме гомер инде җан атты...
Ә мин очам,
Безне кызыктырган
Юлларына төштем кошларның;
Гаҗәп түгел берни –
Әйтерсең мин
Еллар буе шулай очканмын!
Бик түбәндә калды бөтен ваклык,
Мәшәкатьләр, дөнья чүп-чары –
Юкка чыкты бүген бөтенесе,
Алар өчен юллар юк ары.
Сафлык Иле! –
Менә кайда икән
Безнең җанга зарур иркенлек!
Шул киңлекне тойган күңел өчен
Кеше гомере – бары бер көнлек...
Мин уяндым:
Канатлар юк инде...
Тик түбәнгә инде төшмимен, –
Оча беләм,
Җирдә яшәсәм дә,
Күкрәгемдә барыбер кош минем!..

* * *

Үлгәннәрнең җаны күбәләк булып кайта, имеш...

*Халык ышануларыннан*

Ышанасы иде шуңа...
Белмим бүтән чарасын –
Вакытсыз киткән җаннарны
Әй килә кайтарасым!
Килә бер генә булса да
Карыйсым, эндәшәсем...
Һәм терелә күбәләкләр,
Бу җәйге көн яшәсен!
Гөлләргә кайтып куналар
Ерактан авылдашлар:
Күтәрелә күңелләрең,
Турая авыр башлар...
Табышалмый йөрибездер
Кояшлы болынымда,
Гөлгә әйләнимме, әткәй?
Монда мин, улың монда-а-а!
Кайсы күбәләк икән син,
Сабыем, нарасыем?! –
Тынымда җылытыр идем...
Чәчәгең кая синең?
...Вакытсыз югалганнарны
Терелтеп күңелемнән,
Көн буе йөрдем болында
Сөйләшеп шулар белән.
Бушандым.
Ярый, яшәүнең
Ышану-йоласы бар.
И, әле бар бит безнең дә
Күбәләк буласылар!..

## ХАЛӘТ

Учакларда дөрләп ут яна...
Утлар яна,
Йөрәгемә каба,
Кайлардан соң табыйм, ни чара?

Дәрьяларны иңләп су ага...
Сулар ага,
Ярга дулкын кага,
Тик табылмый җанга һич дәва.

Агачларны тарап җил исә...
Җилләр исә,
Бәгырьләрне кисә,
Хәлләремне минем белмичә.

Утлар, сулар, җилләр ни белсен?..
Ниләр белсен,
Ни әмәлләр күрсен? –
Утлар-сулар гына түгел син!..

# САБАНТУЙ БУЛЫП УЗГАН МӘЙДАНДА

Кичә монда сабантуй гөрләде,
Җыйды, көрәштерде бу мәйдан,
Бабайларның кайнарлыгы кайтты,
Кунакчыллык күчте еллардан.

Атлар чапты...
Колга башларына
Менеп җитте кичә Кыюлык;
Хаклык батыр калды.
Мактанчыклык
Капчык тигәч төште егылып.

Эчкерсезлек кайткан кунак булып,
Тапкырлыгы шунда, җорлыгы.
Һәр кешенең җанын сыйпап йөрде
Гасырлардан килгән җыр-моңы...

Халыктагы матур гадәтләрне
Берәм-берәм җыеп еллардан,
Бер күрсеннәр әле диеп, ахры,
Дәшеп алган безне бу мәйдан.

Бүген менә тагын таралыштык.
Ераклардан килгән җылылык
Мәйдандагы ак багана сыман
Күңелләрдә калды сузылып...

## БЕРМУД ӨЧПОЧМАГЫ

Әллә нинди шайтан өчпочмагы:
Самолетлар, имеш, юкка чыга,
Ялгышлар компас һәм сәгатьләр...
Ни хикмәт бу? – Дөнья гаҗиз шуңа.

Кораблары табыла исән килеш:
Бетми калган эчкән чәйләре дә,
Сигаралар сүнмәгәннәр –
Бары
Кешеләр юк менә әллә нигә...

...Кешеләр юк, һаман кешеләр юк:
Шәһәрләре табыла, сарайлары,
Ук-кылычлар чыга катламнардан –
Чәчелешеп җирдә калган бары.

Кая ашыкканнар – алтынга да,
Энҗе-мәрҗәнгә дә ис китмәгән;
Нинди хәтәр өчпочмакта дөнья –
Күз күрмәгән, колак ишетмәгән?..

Гасырлардан барлыйм – кешеләр юк!
Бу югалту җирдә кемгә хаҗәт?
Кешелекне йота бара Вакыт...
Беркем гаҗәпләнми –
Шунысы гаҗәп!

* * *

Әле генә зәңгәр язлар иде...
Кай арада инде көзләр кергән! –
Яшел төсе җирнең сиздермичә
Чыгып китеп бара Сентябрьдән.

Кырау төшә...
Гомер җәйләренең
Сиздермичә көзгә авышканы;
Ераклаша, һаман ераклаша
Яшьлектәге кәккүк тавышлары.

Җилләр генә җанда, давыл гына:
Яшьләр, инде күптән елап, кипте.
...Килер җәйләр моңга ничек чыдар? –
Йөрәгемне кошлар тыңлап китте!..

# ӘБИЛӘР ЧУАГЫ

Табигатьнең, Вакыт каршысында
Тып-тын калып, башын игән мәле.
Тезелешеп, җәйне озатырга
Чыгып баскан печән кибәннәре.

Күз килүгә, ак җәймәдәй булып,
Сузылып ята җиргә ап-ак томан;
Кояш нурларында пәрәвезнең
Тирбәлгәне ишетелә сыман.

Тик бер генә күзнекеме соң бу? –
Урманнарны моңсу сагыш сарган.
Кыштыр-кыштыр килеп, алларыңа
Ялкын өзлеп төшә агачлардан.

Ерак үткәннәргә, киләчәккә
Ишетелер күк, әгәр аваз салсаң;
Күптән киткәннәрне табарсың күк
Болыннарда бүген, эзләп барсаң...

Чал Вакытның, дөнья каршысында
Тып-тын калып, башын игән мәле. –
Табигатьнең шушы мизгелендә,
И, җаннарны чайкыйсы бар әле!..

# ВАСЫЯТЬ

Кешенең үлгәч тә өч көнлек эше кала...

Язмыш шул ук: дөнья мәшәкатен
Бер мин генә очлап китәлмәм, –
Башкарырга соңгы эшләремне
Миңа да бер килер бүтәннәр...

Юк-бар эшкә әрәм итмәгез тик
Миңа дигән соңгы өч көнне:
Илтегезче Аңа,
Гомерем буе
Йөрәгемдә йөрткән гыйшкымны.

Ара ерак диеп көрсенмәгез,
Зинһар өчен, вакыт табыгыз:
Бүленеп калган җырым авылымның
Чишмәсенә илтеп салыгыз.

Хәбәремне ишетер дошманнар да,
Ишетерләр якын дуслар да;
Күктә бер кош артыр...
Какмасыннар –
Әйтсәгез лә шуны кошларга!..

## НИЧӘ ГАСЫР ЕЛЫЙ ЙАГКУБ...

Ничә гасыр елый Йагкуб –
Йосыфтан язган, мескен!
Елый-елый күрмәс булган,
Юата алмый һичкем.

Яшь түгә каһарманнары
Кол Гали кыйссасының;
Гасырлар елый,
Җаныңны
Язмышлар кысса синең.

Чорларга кереп югалган
Никадәр газиз җаннар!
Тарихның һәр чаты саен –
Йосыфлар... Галимҗаннар...

...Ничә гасыр елый Йагкуб
Халыкның йөрәгендә! –
Сөртергә икән күзләрен
Кемнәрнең кулмәгенә?!

* * *

Сандугачлы һәм тургайлы дөнья,
Нинди серләр сөйлисеңдер миңа?
Тик аңламыйм,
И, тел белмәгәнлек! –
Күпме уйлар шулай онытыла...

Хәтерләтер өчен кемнәреңне
Күрсәтәсең нәфис гөлләреңне? –
Искә төшерәлмим,
Җуйган тарих
Еракгагы алсу көннәреңне.

Ачылыр дип, бәлки, боларга син –
Сылуларны каршы чыгарасың,
Ни үкенеч адәм баласына! –
Нигә, дөнья, болай соңарасың?

Газаплама бүтән, җитәр инде,
Кайтар миңа, кайтар хәтеремне:
Сандугачлар төшенерлек итеп
Әйтеп китим җиргә әйтеремне!..

# ТАҢ СУЫ

Таң сызылыр-сызылмас мәл...
Дөнья әле уянмаган.
Кош-корт тынган... Җил дә исми...
Чишмә-сулар болганмаган.

Шулчак Кеше суга килгән,
Шифалы, саф Таң суына;
Балаларын юындырган,
Авырса да кайсы гына.

Ышанычы, өметләре
Шунда булган бөтенесе.
Әйтерсең лә күңелен дә
Таң суында юган Кеше...

Таң сызылыр-сызылмас мәл...
Челтер-челтер Таң сулары, –
Илаһи бер пакьлек булып,
Кичә килә гасырларны,

Күңелләргә күчә килә...
Мең сырхаудан савыктырыр;
Кайгыларны, хәсрәтләрне
Ак өметкә алыштырыр.

Бар җанымны ачып салам,
Халкым, сиңа киләмен дә.
Дәверләрне дәвалаган
Таң суы бар йөрәгеңдә...

* * *

Җилләр – җилфер-җилфер,
Утлар – елтыр-елтыр,
Сулар – челтер-челтер...
Каршылады дөнья бүген таңда:
Җиргә килде кемдер.

Җиргә кемдер килде,
Елады да көлде,
Гөлләр җыеп йөрде;
Никадәрле генә яшәсә дә, яшәп
Туймаслыгын белде.

...Җирдән китте кемдер,
Озатып калды дөнья бүген таңда:
Җилләр – җилфер-җилфер...
Утлар – елтыр-елтыр...
Сулар – челтер-челтер...

И гомер!

* * *

Бигрәк озак тоела иде безгә:
Үскән чаклар – тауга менүдер.
Хәзер инде һич туктатып булмый,
Чана шуу сыман бу гомер...

## ЙӨГЕРМӘКТӘ КЕШЕ

Сабый чакта кеше йөгермәктә,
Йөгерүе белән сөйдермәктә;
Бер гамең дә куып җитә алмас,
Җилләр генә туладыр күлмәккә...

Үсеп җиткәч кеше йөгермәктә:
Юл белмәктә үе, җир күрмәктә;
Туган өйдән еракларга китеп,
Аналарын, ярын көйдермәктә.

Олыгайгач та кеше йөгермәктә:
Ил йомышын йомышлап йөрмәктә;
Әйткән сүзе, кылган эше белән
Җирдә яшәгәнен белдермәктә.

Картайгач та кеше йөгермәктә:
Үткәннәргә кабат кул бирмәктә –
Хыял белән көнгә ничә тапкыр
Дөньяларны гизеп өлгермәктә.

Гомер буе кеше йөгермәктә,
Бөтен күргәннәре – бер йөрәктә.
Язмышларны узып киталмыйбыз,
Никадәрле генә йөгерсәк тә!..

## КОЯШ

Кояш белән без бит авылдашлар –
Ничә еллар бергә уйнадык;
Бергәләшеп кичен өйгә кайттык,
Аның белән бергә уяндык.

Озын көннәр буе Кояш – бездән,
Без – Кояштан тотам калмадык.
Озаграк чыкмый торса әгәр,
Майлы ботка биреп алдадык...

Безнең белән бергә ул да көлде,
Безнең белән бергә елады;
Хәлне белде төшеп тәрәзәгә,
Мин бит – Кояш, диеп тормады.

Барган саен яктырдылар еллар,
Тартылдылар һаман Кояшка.
Юлларыбыз аннан аерылмады
Инде менә ирләр булгач та.

Кояш белән без бит авылдашлар –
Бергә янып, бергә туңганнар.
Каралтырга базмас бу дөньяны
Күңелендә Кояш булганнар!..

## ИҢНӘРЕМӘ САЛ БАШЫҢ...

Ай-һай дөнья, чал башың,
Иңнәремә сал башың,
Бер тирбәтим чал башыңны –
Хәсрәтләрең калмасын.

Күкрәгемдә – йөрәк бу,
Авыр чакта терәк бу,
Синең борчуларың төяп
Китәр өчен кирәк бу.

Буйлыйм Иделләреңне,
Уйлыймын илләреңне;
Яндырып кал: беләсеңдер
Мәңге түгелләремне.

Ай-һай дөнья, чал башың,
Йөрәгемә сал башың,
Кайгыларың алып китим –
Бүтәннәргә калмасын!

# ГӨЛЛӘР ИСӘН...

Әй, дөньяда гөлләр исән әле...
Тамырланып элек-электән,
Тәрәзеннән балкып күренеп торган –
Күңелендә халкым гөл йөрткән.

Кайсы чорда ни күрсә дә башы,
Яшәсә дә ничек көн итеп,
Кайгысын да җирнең, шатлыгын да
Ул үстерә белгән гөл итеп.

Тәрәзәдән йодрык күрсәтмәдек
Узып барган чакта читләргә –
Өебезгә бүген кем килсә дә,
Гөлебез бар бүләк итәргә.

Тамырлансын кучеп һәр күңелгә,
Сөенсеннәр әле, көлсеннәр;
Өйдән өйгә, илдән илгә китсен –
Калмасыннар җирдә гөлсезләр...

Әй, дөньяда гөлләр исән әле,
Бу күңелләр нигә боексын!
Гөлләр булып сибелик җилләргә без,
Һәр тарафка бездән нур йоксын...

# НӘСЕЛ АГАЧЫ

Нәсел агачы дип тормаганнар,
Җае килсә, балта чапканнар –
Кәүсәсендә тирән җөйләр калган,
Ботакларын утка якканнар.

Янган агач...
Башы утта булса,
Ташлар аралаган тамыры.
Бирешмәгән утка-суга гына
Агачларның җирдә калыры.

Язмыш бердер барлык чорларда да:
Агач булса – балта табыла.
Ләкин белә тарих агачларның
Балталарны ваткан чагын да...

Тамырлары кысып кочаклаган,
Җибәрмәскә тоткан, уралып –
Чорлардан син йолкып ташлап кара,
Гасырлардан кара кубарып!

Шул агачтан бит без...
Бурыч уртак –
Җирдә ничек яшәп китсәң дә.
Яфрак булып ярыл киләчәккә,
Тамыр булып тарал үткәнгә...

# ТИРӘНДӘРӘК ӘЛЕ...

Мәңге нидер эзли, эзли кеше:
Тәвәккәлне дулкын күмәлмәгән.
Мин дә чумып энҗе тапмак булдым,
Диңгезләрдән түгел – күңелләрдән.

Энҗе-мәрҗән – дуслар күңелендә
Икән лә бит, диеп йөргәндәрәк,
Әйдәкләде сыман кемдер мине:
– Тирәндәрәк, улым, тирәндәрәк!..

Ата-баба нигезенә кайттым...
Туфрагына кулым тигәндәрәк,
Ишетелде миңа шул ук тавыш:
– Тирәндәрәк, улым, тирәндәрәк!..

Мин халкыма килдем.
Эзләгәнем
Шушында дип башым игәндәрәк,
Яңгырады кебек әлеге өн:
– Тирәндәрәк, улым, тирәндәрәк!..

Ныграк тарта икән сихри нуры,
Төшә барган саен тирәнгәрәк:
Табыламы әллә ул энҗеләр
Йөрәк соңгы тибеш биргәндәрәк?..

* * *

Гел кояшлы түгел дөнья:
Бер елап, бер көлеп торам –
Болыт артында һәрвакыт
Кояш барын белеп торам.

* * *

Бер яман сүз җиткерделәр миңа...
Эчкә йомдым аны, таратмадым,
Җаным кара көеп янса-янды –
Якты калды дөнья, каралтмадым.

Җилләрне дә тыңлый белү кирәк –
Колагыңа килеп, ниләр салмас!
Каян иңә аклык җир йөзенә?
Үзе каралмаган – аңлый алмас...

# БИЕКЛЕК

Без диңгезгә чыктык.
Тынып тормый,
Һаман сөйли экскурсовод,
Таулар белән таныштыра бара,
Күңелләргә бара уй салып.
Таулар белән таныштыра бара:
Кара Тау* да – янар тау булган,
Түбәсендә аның ташбалталы
Кешеләрнең эзе табылган.
Бу тауларга Вакыт таянгандыр...
Тауларның да була терәге:
Әйтерсең лә күккә тартып тора
Тау түбәсен шагыйрь йөрәге**.
Акчарлаклар уйный,
Озын Сырттан***
Күтәрелгән очкыч шикелле;
Кыюларның даны – мәңгелеккә
Очып киткән бер кош шикелле.
Таулар белән таныштыра бара –
Кешеләрне сөйли тау, диеп.
Уйлый китсәң, таудай гынамы соң:
Кешеләрнең җаны, һай, биек!
Карап барам шундый биеклектән,
Карашларым әллә кайларда.
Сизеп торам:
Безнең белән бергә
Биегәя бара таулар да...

* Кара Тау – Кырымдагы тау.
** Шагыйрь М.А.Волошин Күк Түбә тау башында күмелгән.
*** Озын Сыртта космик корабльләр конструкторы С.П.Королев яшьлегендә планер белән беренче очышларын ясаган.

## ӘТКӘЙ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

### 1

Кайтуын кайттым да яныңа –
Белмим шул, әткәем, кабереңне!
Каеннар зиратта, шомыртлар...
Кочаклап елыйсы һәрберен.

Ни булды, нишләдем әле мин? –
Син җирдә каберсез калгансың!
Кайлардаен, әткәем, мин синең
Бу чаклы хәерсез балаң соң?!

Гөнаһсыз булса да сабый чак,
Кичермәм, беркайчан кичермәм:
Дөньяда әткәем үлгәнне
Ничек соң чыгардым исемнән?!

Мин синең туфракны белмичә,
Ничек соң җибәрдем елларны?
Ник алар әйтмичә киттеләр
Вөҗданым бер кайтып сорарны?

Килдем дә яныңа,
Син диеп
Сыйпыймын инде һәр әремне.
Каберсез түгел син, әткәем –
Йөрәккә күчердем кабереңне...

### 2

Сиңа бит җиталмый торгандыр
Барыбер уйнаган көйләрем –
И Әткәй!
Нигә соң син мине
Гармунчы итәргә теләдең?

Нечкәрер көй саен, өзелер:
Бер җанга күбрәк түгелме? –
Тоташтан моң була икән бит
Болай да ятимнәр күңеле.

Барсын да сыйдырып юатыр
Гармунын кайлардан аласың? –
Белмәдеңмени соң әнкәйнең
Актыккы сыердан каласын?

Кайгысын, шатлыгын – барын да
Уйнарга өйрәндем мин инде.
Төсеңне табалмый интегәм –
Әйтмиләр яраткан көеңне.

Кагылмый калалмас сиңа да:
Гармунда нинди моң, дисеңме? –
И Әткәй!
Ничә ел тоташтан
Уйныймын бит инде мин сине!..

## 3

Атадан балага ни кала? –
Һичкайчан әйталмам мин ансын.
Ә минем үземә гомерлек
Йөрәктер – калдырган мирасың.

Бүтән ни чыдасын кайгыга? –
Иң башлап шул йөрәк кирәкте,
Ни кыен булса да түзде ул,
Мине дә түзәргә өйрәтте.

Нишләтер идем мин сөюне,
Нәфрәтне, давылын-җилләрен? –
Күтәрде, барсын да күтәрде:
Алай да бар иде йөрәгем!

Бүген дә минем шул йөрәккә
Таяна – күк булсын, җир булсын...
Белгәнсең син, әткәй, күргәнсең:
Йөрәксез ул нинди ир булсын?!

Атадан балага ни кала? –
Гомерлек мираслы иткәнсең;
Иртәрәк китсәң дә,
Син мине
Барыбер йөрәкле иткәнсең...

* * *

Баш очыңда күкләр нинди тирән,
Офыклар киң, көннәр нинди якты!
Үтәр юлың шул яктылык аша –
Тууыңнан туфрагыңа чаклы.

Мәңгелеккә китеп югаласың,
Шул яктыга кереп чыгасың да;
Үзең белән көн яктысын түгел,
Алып киталмыйсың чырасын да.

Яктылыкта калып буладыр ул
Кушсаң гына аңа үз яктыңны.
Тууыңнан туфрагыңа чаклы
Түгәсең бар әле йөз яктыңны!

* * *

Гомер юлым кая юнәлсә дә,
Кай тарафка алып барса да,
Кемдер килә,
Килә минем арттан –
Сулышлары бәрелә аркама.
Адымымны минем чамалар да
Менә-менә бирәр сүз әйтер;
Ялгыш кына читкә тайпылсам да,
Күз карашы белән төзәтер...

Берьялгызым түгел – юлыксам да
Бу язмышның нинди чагына:
Кемдер килә,
Килә янәшәмнән,
Иңнәремә иңе кагыла.
Һәр эшемә янда гына минем
Ул барлыгын тоеп тотынам.
Бер минут та ялгыз калдырмый ул,
Истән чыкмый торган уй сыман...

Юлларымның очы чуалганда,
Торган чакта җиле карышып,
Кемдер бара,
Бара минем алдан –
Юк, булмыйдыр аннан калышып.
Җиңеләя алыр сулышларым,
Аның белән юлда кем арыр?
Сизеп торам – ул барыбер мине
Максатыма илтеп чыгарыр...

* * *

Үз-үземне белә башлаганда,
Миңа гүя бары да таныш иде –
Әйтерсең лә инде икенче кат
Китергәннәр җиргә ялгыш мине!
Дөнья гына гаҗәпләнде бугай:
Чакырмады да ул, кумады да.
Шул көенчә калдым кебек яшәп...

...Таяндым мин кабат кулларыма,
Аягыма торып бастым тагын:
Бары да якын, бары да ымсындыра:
Әүвәл яшәвемдә кем идем соң?! –
Искә төшералмыйм шунсын гына.
Бик күптәнге таныш наз шикелле,
Битләремә җил сугылып китә;
Нидер җитми җирдә... Кемнәрдер юк –
Үзәк өзгеч моңсу булып китә...
Суын эчәм, сулыйм һаваларын,
Сайрар кошларына колак салам;
Иң кирәген күрми каламдыр күк,
Кайдадыр ул? – Әле табылмаган...

...Бу юлы да яшәп бетералмыйм,
Узып барам инде, булмый туктап;
Нидер кала һаман –
Әле җиргә
Киләсем бар бугай тагын бер кат!..

# КИЧКЕ УЕН

Кичке уен иде бит ул –
Ничек әле төнне кичте?
Айлар-еллар аша үтеп,
Сагындырып искә төште.

Җәйге ындыр артларына
Чакырадыр тальяннары...
Мин монда да –
Егетләрнең
Кайда икән калганнары?

«Чума үрдәк, чума каз...» – дип,
Шулардыр – кул чабып тора.
Сөйгәннәрнең елмаюын
Йөрәгенә салып тора.

Салып тора әйтер сүзнең,
Бер-бер артлы, җырга – барын;
Бөтенесе белеп тора
Җырның кемгә җырланганын.

Кызлардагы уңганлыкны
Уенда да күреп була:
Түгәрәкнең уртасында
Гөлләр үскән кебек була...

Авылларда кичке уен
Булмый инде, онытылды...
Яланнарда әллә кайчан
Тальяннарның моңы тынды.

Клубларын, сарайларын
Тарсындымы кичке уен –
Яланнары белән бергә
Хыялларга күчте... Кыен!

Кичке түгел – гомерлектер
Инде безгә ул уеннар,
Озынайта ул кичләрне,
Озынайта һаман еллар.

Кызларның-егетләрнең дә
Мөһим түгел кайдалыгы –
Йөрәкләрен җылытадыр
Кичке уеннар кайнарлыгы...

## АКЛЫК

Моңсулыкка чумган көзге көннәр
Каян ала дисәң яктыны,
Казлары бар икән әле җирнең,
Күкләрендә – казлар аклыгы.

Язмыш тарафыннан йөз алданып,
Өметләре сынган кешегә
Казлар шулай бу дөньяда әле
Канат барын искә төшерә.

Офыклардан офыкларга күчә,
Күкләрендә – җаннар аклыгы!
...Гомереңә, әй, җитәрлек итеп
Сибеп китте казлар яктыны...

# КОЯШ ЧЫГЫШЛАРЫН КАРАП ТОРАМ...

Кояш чыгышларын карап торам –
Садә чагын көннең, тын чагын;
Нурга куям җанны,
Ничәнчедер
Гөнаһлысы булып дөньяның...

Ничәнчедер кеше булып җирдә
Кояш белән бергә яшим мин.
Бәхетләрем – аның яктысында,
Ул – шаһиты тамган яшемнең.

Күгендәге караңгылыкларны
Сылтап барсаң һәрчак болытка,
Яктылыкны белми калуың бар,
Кояш белән чордаш булып та.

...Кояш баешларын карап торам –
Ал яулыгын болгый китәргә;
Мин болыттан аралаган кояш
Кемнәр өчен чыгар иртәгә?!

# БАШ ОЧЫҢДА БЕР КОШ

Бик биектә,
Безнең баш очында
Туктамыйча бөтерелә бер кош,
Еллар буе бөтерелә шулай...
Бер хикмәте бит булырга тиеш!
Юкка гына күтәрелмәс кошлар,
Нәрсә сискәндергән, илдә ни бар?
Нинди кош ул? –
Билгесездер монсы,
Белсәк тә без, гәрчә, әлләниләр...

Баш очында бөтерелә һаман –
Синең кошыңдыр ул, минем кошым.
Үз-үзенә урын табалмаган
Җаннарыңны синең кая куйсын?!
Уйларыңа җирдә әле ирек
Җитмәгәндә, күксез буламыни?
Куначасы сындырылган кошлар
Бүтән куначага кунамыни?

Бик биектә,
Безнең баш очында
Еллар буе бөтерелә бер кош.
Кошлар күккә күтәрелә икән –
Берәр хикмәт чыгарырга тиеш!..

## ШӘҺӘРГӘ КИЛГӘН АВЫЛ БАЛАСЫНА

Сагынганың сиздермәскә теләп,
Яшерен генә елап аласың –
Шәһәрләргә кереп адаштыңмы,
И авылның моңлы баласы?!

Карашларың нигә яшерәсең?
Чит-ят түгел ич мин, оялма!
Хыялларың китергәндер сине...
Адаштыра кайчак хыял да.

Атаң-анаң, туган җирең калган.
Туган телең... –
Калыр ансы да:
Милләтеннән йөз чөерсә әгәр,
Берни тормый монда сансызга.

Тыңлап үскән назлы көйләреңне
Алмаштырсаң, әзер мең алмаш.
Күндәм генә җырын җырлар булсаң,
Арбасына сине кем алмас?!

Елый-елый үзгәрәләр шулай,
Монда килгәч, синең кебекләр:
Хыялыннан, иманыннан язган,
Юлларыннан – күпме егетләр!

Иманнарын сатып, креслога
Үрмәли дә
Халкы өстенә
Дошманнарыңа да күрсәтмәстәй
Этлекләрне инде өстерә...

Юк, юк!
Сине битәрләвем түгел,

Ник кимсетим адәм баласын? –
Килә минем барлык афәтләрдән
Күңелеңне саклап каласым.

Елый алган чакта ела, якташ,
Елаганда – әле өмет бар...
Шәһәрләргә килеп,
Адашмыйча
Калалсагыз икән, егетләр!

* * *

Барыбыз да – ата балалары,
Һәркайсыбыз – бала атасы.
Никадәрле тармаклансак та без,
Тамырыңа кире кайтасы.

Кемдер кайта йөз яктысы булып,
Йөз карасы булып – кемнәрдер.
Утлар-сулар кичкән нәсел-ыру
Ак-караны байтак күргәндер.

Гасыр иңләп кайтыш...
Йөзләренә
Кер кундырмас өчен тырышам:
Бер ягымнан әткәй җитәкләгән,
Бер кулыма улым елышкан...

# МӘҮЛЕТ КИЧЕНДӘ

Гүр иясе күрше карчыклары!
Кичерегез барсы өчен дә –
Кайтарасым килде бүген сезне
Бик күптәнге мәүлет кичәнә.

Утырырсыз өстәл тирәсенә,
Кайберегез сәке читенә. –
Ул кич мине инде ничәнче кат
Менә шулай тартып китерә.

Без сабыйлар өлеше – тыңлап тору,
Урыныбыз – бүлмә эчендә.
Изге китап сүзе генә өйдә,
Гайбәт йөрми мәүлет кичендә.

Күбегез тол.
Яшьләр кипкән инде
Чаба-чаба колхоз эшенә.
Җанын сыйпап бер юатыр өчен
Мөнәҗәт тә җитә кешегә...

Күпләрегез иман яңарткандыр,
Сабырлыклар җыеп ул кичтә.
Дөнья малы – тик өч кенә көнлек,
Иман кала үзең үлгәч тә.

Сезнең якты әле дә төшә безгә...
Бүгенгеләр нәрсә калдырсын –
Уң белән сул тәмам буталган чак,
Кая карыйк – кыйбла бармы соң?!

Юл тапкансыз,
Юкса лампагыз да
Җиделе генә иде ул чакта.

Ә без менә юлдан язып беттек,
Ильич яктысында булсак та...

...Гүрләреннән кире кайтардым да
Карчыкларны,
Инде нишләсе –
Кемнәрне соң чакырырга икән?
Бүген бездә мәүлет кичәсе...

* * *

Сандугачлар сусап су тапмыйлар,
Баласыз каз ялгыз каңгыра;
Нидер булган быел бу җәйләргә –
Явалмыйча йөри яңгырлар.

Бу җәйләргә быел нидер булган –
Каеннарның сары очлары;
Арабыздан әле ять-яшь килеш
Алып китеп бара дусларны.

Чит илләрдә калган балалар бар –
Күзләр инде көтеп зарыккан;
Нидер булган быел бу җәйләргә –
Ярга чыгып үлә балыклар...

Гөнаһлысы миндер кебек җирнең,
Кичерерме, гафу сорасаң?
...Мәңге шулай интегер күк җәйләр,
Гөнаһыңны әгәр юмасаң...

## УТ АРКЫЛЫ СИКЕРҮ

Сыер саклый язгы кичтә
Җыен бала-чага,
Коры-сары җыештырып,
Көн дә учак яга.

Чатыр-чотыр яна учак,
Ялкыннары биек.
Чиратлашып ялкын аша
Әй сикерә идек!

Кызык итә сикерүне
Бары да ут аркылы:
Ут булса да, юк бит аның
Безне тотар кулы.

Бәреп кала кайнар дулкын,
Каш-керфекләр көя...
...Ул чактагы утлар һаман
Сүнми икән нигә?

Яна хәтер...
Ут аркылы
Сикерәбез һаман –
Кемдер үтә, ә кемнәрдер
Ут эчендә кала.

Аның саен калкына ут,
Күтәрелә бара.
Гомер биеклеге утны
Йә, сикереп кара!..

## КОШ ЕЛАВЫ

Яланнардан бер әйләним дисәң,
Кошлар елый...
Нинди коштыр алар? –
Баш очында бөтерелеп һаман,
Җан ачысы белән кычкыралар.
Синнән шулай курыктылар микән,
Бу тирәдә бармы оялары?
Югыйсә бит бер дә елатырга
Теләмәгән идең син аларны.
Үзәк өзгеч итеп кычкыралар –
Капланып хет ела яланнарга.
Сизгәннәрме әллә – яшәвеңне
Хәвеф-хәтәр тулы заманнарда?
Кычкыралар...
Белгәннәрме әллә –
Синең дә бит бар иде лә канат!
Киселгән шул. Тик күнегеп булмый,
Егылсаң да инде ничә кабат...

Талпынасың кошлар булмасаң да.
Башың килеп ташка бәрелүгә,
Йөрәккәең күккә томырылып,
Мәңгелек бер кошка әверелә:
Җан ачысы белән кычкыра ул,
Шул кошларга кушылып, яланнарда.
Кошлар елый, хәерлегә булсын...
Сабырлыклар бирсен заманнарга!

* * *

«Җидегән Йолдыз!» – Җиде әйтсәң – савап, имеш...
Шушы сүзен әбиеңнең онытмадың.
Изге әби! –
Абындырмас өчен җирдә,
Йолдызларга табындырган оныкларын.

«Җидегән Йолдыз!» – Җиде әйтсәң, савап, имеш...
Ничә кабат әйтелгәндер – санамадың.
Бер булса да ярлыкарга җитәр микән
Гөнаһлы бу бәндәләрен замананың?

Җитәр микән күктә йолдыз! –
И әбекәй!
Белгәнсеңдер – нигә әйтми китеп бардың?
Инде күккә очып бетеп килә бугай
Язуы да синнән калган китапларның.

– Җидегән Йолдыз!
– Җидегән Йолдыз!
– Җидегән Йолдыз!.. –
Әллә савап иңә җиргә, әллә җавап:
Яшь җемелди күзләрендә йолдызларның,
Бу җиһанның газиз баласына карап...

## ПЕСНӘК

Тукта, Кеше!
Тәрәзәңә
Песнәк кунган бит әле!
Кирәкми аңа нинди чор,
Ничәнче ел икәне –
Пыяла артында кем ул,
Ни эшли, нәрсә яза?
Миһербан бармы җанында,
Кылмасмы бәла-каза?
Карый ике кара сәйлән,
Икеләнеп-сагаеп.
Әйтәдер төсле: «Йа Хода,
Монсыннан да файда юк!..»
Урманына кире очты,
Килде дә китте песнәк.
Ул китте... китеп югалды...
Калдым мин әллә нишләп.
Яман эш кылып тотылган
Кешедәй торам басып:
Чынлап та песнәк идеме –
Кем китте миңа дәшеп?

# АВЫЛДАШЫМ ӨММЕҺАНИ АПАГА АЧЫК ХАТ

Авылдашым Өммеһани апа!
Язмый калсам әгәр мин бу хакта,
Гөнаһ булыр. Аяк баса алмам
Мин яңадан кайтып туган якка.

Авылда бер чая хатын идең,
Җебеп яшәмәдең – каты идең.
Туры сүзле булдың. Әҗерен дә
Үз җилкәңдә бик еш татый идең.

Урак урдың, көлтә бәйләдең син,
Эш дигәндә җенгә әйләндең син.
Ничек итсәң иттең – бу язмышны
Алдар өчен таптың хәйләне син.

Бәхетеңне Алла каргамасын! –
Хәтерлим мин Өммай карамасын:
Шул агачка кабык бишек асып,
Балаларың кырда карагансың.

Ятимнәрең кеше иткән чакта
Кылдың микәнни соң берәр хата –
Нигә болай булды картлык көнең,
Авылдашым Өммеһани апа?!

Картлар йорты – синең йортың түгел:
Бер тын тормас идең, бер көн түгел.
Очып кына кайтыр идең дә бит –
Балаларыңа син беркем түгел...

Йа хикмәти Хода, таң каласың:
Сизгән кебек көнең караласын,
Күптән инде яндырганнар иде
Авылдашлар Өммай карамасын.

Гыйбрәт итеп, бер-берсеннән алып,
Ходай суккан, дип сөйләде халык:
Инде сиңа кайтып җиттем, дигәч,
Кече улың үлгән йөрәк ярылып...

Белмим ничек юатырга сине,
Нигә генә сүз башладым, тиле?!
Карамага бишек элмәс идең,
Үткәннәргә кайталмыйсың кире.

Авылдашым Өммеһани апа!
Рәнҗемә берүк син бу хатка,
Исән барып җитә алса әгәр –
Көл булмаса янып юлда чакта...

* * *

Бу дөньяда мине яраттылар.
Дөньяларын мин дә яраттым:
Ак җанымны җилләренә җәеп,
Шул дөньяда йөзеп каралттым.

Дөньяларын мин дә яраттым ла,
Яраттым ла азга булса да –
Яратканнар – кала...
И җир йөзе!
Миннән соң да назга сусама...

# АБЫЙ!..

*Беренче укытучым*
*Хәсән ага Салиховка*

Бала күңеле – язылмаган кәгазь.
Кәгазьләрегезне җил тараткан...
Гомер буе язганнарыгызның
Мин – бер генә бите бер тарафтан.

Кемне кая илтеп ташламыйдыр:
Җил генәме – давыл бит бу, абый!
Югалырлык түгел язганыгыз –
Сезнең кулны күзсезләр дә таный.

Нинди кара белән язгансыздыр:
Бозып карадылар туксан тугыз –
Бозалмыйлар.
Безгә язган чакта
Йөрәк булган кара савытыгыз...

Кәгазьләрегезне җил тараткан...
Ут аркылы чыгасы бит, абый!
Утка төшеп, көлгә әйләнгәнче
Укып биреп бетералсам ярый!..

# ТЕРЕЛТМИЧӘ КИТМӘ!..

*Җырчы Зәйнәп Фәрхетдиновага*

Сине безгә Ходай җибәргәндер:
«Заманалар кырыс, – дигәндер. –
Йөрәкләре ташка әйләнмәсен,
Бәндәләрне моңга кинәндер...»

Килми калмас идең син болай да,
Җырлар идең үзең белеп тә:
Җан ачысын сала бит ул халык
Синдәйләргә, синең кебеккә.

Заманасы аптыраштa калган,
Гаҗизлеккә төшкән көннәрдә
Безгә сине Ходай җибәргәндер,
Җибәргәнен белеп кемнәргә.

Белгәнсеңдер син дә, –
Тавышыңа
Куша алмас идең чорларны,
Кайтаралмас идең милләттәшләр
Җырлый алмый киткән җырларны...

Кагылырсың җирдә һәр йөрәккә –
Моңның аның бардыр мең җаны,
Сине безгә Ходай җибәргәндер:
Терелтмичә китмә дөньяны!
Терелтмичә китмә...

* * *

Булыр-булмас арба юл бозар, ди,
Булыр-булмас мулла дин бозар...
Без дөньядан узып барган чакта
Карап тора күктән йолдызлар.

Сиңа кадәр күптән бозылган юл
Син узганга ничек төзәлсен?
Дөньялардан узып барган чакта
Кычкырмыйча ничек түзәрсең?!

Барчабызга җирдә юл бер генә:
Кемнәр төзәтер дә, кем бозар...
Мин дөньядан узып барган чакта
Карап калды күктә йолдызлар...

* * *

Кемнәр генә җирдә яшәмәгән,
Миңа инде ни сан?!
Әллә артык зур булды бу дөнья,
Әллә инде кысан:

Иртә-кичен моңга әйләнәдер,
Башларыңны куйсаң –
Дөнья хәтле дөнья бит әле ул!
Барсын җанга җыйсаң...

Зурлыгын да, хурлыгын да бергә
Сыйдырала җиһан.
Бар да ташлап китә тора никтер –
Дөньяларга ни сан!..

## КҮКЛӘР ШУЛ УК...

Эзләремне табалмыйча йөрим,
Юллар бүтән, юллар үзгәргән...
Баш очымда күкләр генә шул ук,
Ишеткәндәй булам: «Түз, бәндәм!..»
Күкләр үзгәрмәгән:
Кояшы да
Урынында икән, ае да.
Сагышлар да саргайталмаганнар,
Каралтмаган кара кайгы да.
Таралыштык.
Инде аннан бирле
Төрләнгәннәр монда кырыкка.
Күкләр бөтен калган,
Шушы авыл
Өсләрендә була торып та.
Күкләр бер үк шушы ил өстендә.
Еллар бүтән, еллар үзгәргән.
Нинди генә кием киенсәң дә –
Үз йөрәгең белән үз гәүдәң...
Алтыдагы язмыш – алтмышкадыр –
Синең белән бергә күченгән.
Эзләремне табалмыйча йөрим
Ботарланган заман эченнән.
Күкләр генә шул ук –
Баштан сыйпый,
Ишеткәндәй булам: «Түз, бәндәм!..»
Телләремнән тартып алган сыман,
Җавап бирә дөнья: «Түзалмам...»

# КҮТӘР!

Без бит болай түбән түгел идек,
Күтәр мине, күтәр, канатым! –
Ваклыклары өчен түгел, җирне
Аклыклары өчен яраттым.

Үткәннәргә кадәр күтәр мине,
Күтәр дә син, кире төшермә:
Түбәнлеккә төшүдән дә хәтәр
Нәрсә булсын тере кешегә?!

Биеккәрәк күтәр, биеккәрәк –
Замананың буе җитмәсен.
Үзең генә, үзең генә елат...
Үзең генә бары сөрт яшем!

Без бит болай түбән түгел идек,
Тарихтагы хата бу бары.
Бабайларның якты рухлары
Әле дә булса тарта югары.

Түбәннәрнең үзен уза алмый
Безнең хакта яман хәбәре.
Күтәр мине, күтәр, и канатым,
Үзебезнең күккә кадәрле!..

## ТАТАР ҖЫРЫ

Телсез кала язганда да
Җырлы булды Татар Иле –
Шушындадыр бу дөньяның
Бәрәкәтләр ятар җире.

Афәтләрдән тартып ал да
Асылыма кайтар мине –
Халык кадәр халыкны син
Яшәртәсең, татар җыры!

Гөл тамыры җирдә була,
Җырда була халык җаны.
Син бит аның өзгәләнеп
Упкыннардан калыкканы.

Тыйган чаклар булды сине, –
Бу яшәүнең хәтәр җиле...
Заманнарны җылытырга
Язган сиңа, татар җыры!

Илсезләргә ил булдың син,
Телсезләрнең теле булдың,
Илдә гөлләр беткән чакта,
Йөрәкләрнең гөле булдың.

Шушындадыр бу дөньяның
Бәрәкәтләр ятар җире:
Уятадыр, уйлатадыр,
Юатадыр татар җыры...

## ГАРМУН БӘЙРӘМЕ

Урамнарда гармун бәйрәмнәре,
Бәйрәмнәрдән ничек каласың?!
Өзгәләнә гармуннары илнең,
Уятырга адәм баласын.

Өзгәләнә гармуннары илнең...
Халык җаны, димәк, буш түгел.
Әйтер сүзен ул бит гомер буе
Гармуннарга, җырга кушты гел.

Буш булалмый бүген халык җаны,
Шуңа карап гамәл кылына:
Кемдер җирдә кылыч күтәргәндә,
Гармун ала татар кулына.

Гармун ала татар...
Җилкендерә
Эчләрендә җаны булганны.
Көйләр булып күтәрелә еллар...
Җиңеп кара шушы моңнарны!

Мәйданнарга гармуннары чыга
Ялганына каршы ятларның –
Кылычларың бер яктарак торсын
Гармуннары барда татарның...

Өзгәләнә гармуннары чорның,
Күңелдәген әйтеп, илдәген.
Бәйрәм генә булыр иде җирдә,
Тыңласалар халык йөрәген...

## КЫР КАЗЛАРЫ КАЗАН ӨСТЕНДӘ...

Канатларың булса, күтәрел дә,
Барып кушыл, бергә оч син дә:
Синең өчен ураулары бугай –
Кыр казлары Казан өстендә.

Урын бардыр,
Синең җаныңа да
Киңлекләре җитә күкләрнең...
Нигә болай калдың аерылып,
Бураннарны ничек үткәрдең?

Синең өчен ураулары бугай,
Кыйгак-кыйгак казлар кычкыра,
Аласылар сине шул төркемгә...
Оча алсаң, әйдә, оч кына!

Кыр казлары Казан өсләрендә,
Күктәгеләр барлый җирдәгеләр.
Карап калдым күздән югалганчы –
Казлар белән китте йөрәгем...

## БУРАН ТЫНГАН АРА...

Күкне – җиргә, җирне – күккә орды,
Атна буе котырынды буран.
Аннан тынып калды:
«Бу дөньяны
Нишләтәсең инде...» – дигән сыман.

Кар көрәде авыл агайлары.
Кар өстенә иңде караңгылык.
Җир йөзендә ак һәм кара калды,
Без кичәсе шомлы ара булып.

Тып-тын иде кышкы авыл киче.
Күңелләр көр, җаннар тыныч иде...
Яшен-картын сискәндереп кинәт,
Өстурманнан шомлы аваз килде.

Кабатланды тагын...
Бураннарда
Адашканмы әллә берәр бәндә?
Ачы итеп нигә кычкыра ул
Урман уртасында... Төн кергәндә?!

Ат җиктеләр ирләр...
Бөтен авыл
Эзләгәндер аны иртәнгәчә.
Мылтыклардан атып карадылар...
Таба гына алмадылар гәрчә.

Без кичәсе шомлы ара булып,
Җир өстендә йөрде ак һәм кара...
...Ул кич инде әллә кайда калды,
Ерагая, ерагая ара.

Тик хәтердән китми теге тавыш:
Ни дип аваз салды, кем булды ул?
Еллар буе нигә пошындырып
Искә төшә болай,
Ник моңлы ул?

Нигә әле аягына басты
Бөтен авыл ул чак, күрше-тирә?
Ак һәм кара еллар арасында
Ул аваз бит һаман ишетелә!

Ишетелә...
Бары яшь аралаш
Ишетмәскә генә салышабыз.
Җавап бирер хәлдә түгелдер шул
Давыллардан килгән тавышка без...

Нишләтәсең инде бу дөньяны –
Дулар буран...
Кар-бураннар тынгач,
Кычкырыр ул. –
Ишетсәгез әгәр,
Эзләмәгез – Өстурманда булмас...

## ГОМЕР БУЕ...

Чирәмнәрдән табан аерылса,
Сине юньләп танымыйлар икән:
Гомер буе – малай бит син юкса...
Шул малайга «абый» диләр икән!

Чирәмнәрдән табан аерылса,
«Җаный» диләр...
«Әти» диләр беркөн.
Теге «малай» уйный шулар белән...
Малай икәнлеген сизми беркем.

Замана да берни белми икән:
Зур-зур эшләр йөкли «малай»ларга.
Авыр булса булыр – күтәрәләр...
Җиргә җиңелрәк алар барда.

Ак сакаллы «малай» итә дөнья,
Калебеңә сала бер Алласын... –
Нинди кыяфәткә кертсәләр дә,
Шул «малай»лар бездә югалмасын!

Танымаслар...
Искәрмәсләр, бәлки,
Гомер буе – малай булганыңны.
...Дөньялыкка нинди хәлдә бирсә,
Шулай алсын Ходай бу җанымны...

## КӨЙЛӘР ТҮГЕЛ ИДЕ...

*Татарстанның атказанган табибы*
*Равил Шәймәрдәновка*

Исем китеп торам: хирургның
Бармаклары – гармун телләрендә.
Бүген илгә кирәк моңны, Ходай,
Биргәнсең лә менә кемнәреңә!
Менә кемнәреңнең җаннарында
Дөньяларга бүген кирәк иман! –
Көйләр булып саркый,
Ил табибы
Бары үзе генә белгән юлдан.
Агыла да һаман агыла ул,
Гармун юк чакта да кулларында...
Яши икән халык, яши икән
Мең шифага ия улларында.
Әйтерсең лә гармун урынына
Гомерләрне шулай кочаклаган.
Эзли бармаклары, таба көен,
Игелекне менә кем саклаган!
...Исем китеп тыңлап тордым беркөн
Хирургның гармун уйнаганын:
Бик күпләрнең язмышлары иде –
Көйләр түгел иде тыңлаганым...

# ҖАНЫҢДА КАЛМИЯ БАР...

*Ленар Вәлиевкә*

Бәхетләр ничә яшьтә дә
Үзеңнән калмый алар:
Синең дә сабый чактан ук
Җаныңда Калмия бар.

Казаннарны, заманнарны
Калмияда юасың, –
Дөньяларны үзең кебек
Яшәртмәкче буласың,
Яңартмакчы...
Гомерләрне
Озынайтасың шулай.
Игелекле кулларыңа
Ярдәмнәр бирсен Ходай!

Синең кебек егетләрнең
Яшьләре булмый аның.
Җаннарыңда Калмия бар,
Яше юк Калмияның...

*2 ноябрь, 2003*

* * *

Каерылам да карыйм:
Кар-буранда
Еллар һаман чана шуалар,
Күздән югалалар...
Чаналарда
Без дә барын белми шул алар!
Белми икән еллар.
Әмма ләкин
Гомерләрнең бердер чанасы:
Таудан төшкән саен күтәрелә,
Күтәрелә адәм баласы.
Һәм барыбер тау башында кала,
Мәңге кала – сана-санама.
И биек тә икән монда таулар...
Утыралмый еллар чанаңа!

## ТҮТӘЛ-ТҮТӘЛ АК БОЛЫТЛАР

Офыкларда ак болытлар түтәл-түтәл, –
Йа Ходаем, кемнәр нәрсә чәчеп үтәр?
Дөнья буйлап таралышкан түтәлләргә
Күз ташларга куркып торам: яшен үсәр!..

Ата-бабам күп заманнар моннан элек
Болытларга өмет төртеп киткән кебек:
Җәйләр җитсә, һавалардан җилли-җилли
Җир өстенә бәрәкәтләр ява килеп.

Җаннарында беркадәре орлык барда
Кыймылдыйсы улларыңа, оныкларга, –
Җиһан буйлап талгын гына агып бара,
Түтәл-түтәл ак болытлар офыкларда...

## БҮГЕН БЕЛДЕМ...

*Хәкимә апага*

Бүген белдем:
Күпме яшәмәсен –
Кеше – гомер буе бала икән,
Анасы да китә...
Туганнары
Ана урынына кала икән,
Башларыңнан сыйпый,
Тирбәтергә
Бәгыренә сине сала икән;
Байлыгыңны каннан-канга күчкән
Җан җылысы белән сана икән!
Гомер дигәннәрен бүген белдем:
Кошлар очып җитмәс ара икән.
Без җитәргә тиеш,
Мәңгелеккә
Җаннар җитәкләшеп бара икән...

* * *

Ышанычлар челтәрләнеп бетте,
Сыекланып бетте дөньялар.
Инде җирдән мин дә китеп барсам,
Иңнәреңә күкне кем ябар?

Тагын кая барып сөялерсең,
Язмышлардан шулай алдангач?
Чәчләреңне барыбер тарый алмас –
Давылларга чыкма яланбаш.

Җаннарыңа тими узмагандыр:
Гомеркәйләр безнең – авыр моң.
Бер җырларсың мине, бер еларсың, –
Киталмамын, синдә калырмын...

# ЙА ИЛАҺЫМ!..

Онытылмый кечкенәдән
Колагыңа кергән:
– Йа Илаһым!.. –
Аптыраган әнкәемнең сүзе...
Аның өчен тагын кем еласын?!

Йөрде ул сүз, өйдән өйгә йөрде,
Язмышларга каршы ни кыласың?
Яраланган саен, ярасына
Япты аны халык:
– Йа Илаһым!..

Инде менә мин әйтергә тиеш:
Ничек ишетмисең илнең «аһ»ын?
Бүтән сүзләр беткәнмени безгә,
Нигә болай соң бу,
Йа Илаһым?!

Бөтенесе белдеклеләр үзе,
Тик берсе дә белми ни буласын.
Мәңгелектән карап тора безгә
Аптыраулы кояш:
– Йа Илаһым!..

# ДӨНЬЯГА ҮПКӘ СҮЗЕ

Үз теләгем белән килмәдем бит,
Ихтыяры шулдыр Ходайның!
Күрсәтмәдең якты чыраеңны,
Танымаган булып кыландың.

Мин таныдым сине:
Нужаларың
Байтак сеңгән нәсел канына,
Миндә алар хәзер, минем белән, –
Танымасаң, әйдә, таныма...

Түмгәк саен башны идерәсең,
Гомер дигән юлны үткәндә.
Син үзең дә бит мәңгелек түгел,
Ул кадәрле борын күтәрмә!

Бөтенләйгә каласым юк синдә,
Өзгәләнмәм алай, ялынмам.
Сине кызганырмын, фәкыйрь Дөнья,
Мәңгелеккә китәр алдыннан...

## СУЛАР ТИРӘН...

Иделләргә төшсәң, сулар тирән,
Тел тибрәтәсе булсаң, сүз тирән.
Сиңа тигән хак язмышлар тирән,
Тирән булгангадыр – күз тигән.

Күзләр тигән – өмет өзелмәгән,
Мәсхәрәләгәннәр – түзелгән.
Иделләрдә сулар тирән дә бит,
Заманалар чыпчык тезеннән...

## АТ ҖИКТЕ МАЛАЙЛАР...

Ат җикте малайлар.
Шул көнне
Аерылып калгандыр малайлык.
Калгандыр... Җәяүле гомергә
Атларны узардай чама юк.

Ат җикте малайлар.
Юлларда –
Һаман да җигүле атлары,
Тарталар... Елларның тын гына
Ир булып өлгергән чаклары.

Ат җикте малайлар, ат җикте! –
И, инде әткәйләр куаныр.
...Малайлар җиккән ул атларны
Беркөнне бабайлар тугарыр...

# ХӘТЕР ТАУДА

Язганнарым әгәр ялган булса,
Үпкәләмәм, Вакыт сызып ташлар:
Басканнар да Хәтер тау башына,
Кул болгыйлар миңа сабакташлар.

Менеп кенә булмый, –
Күпме җәйләр,
Күпме күзләр анда киртләч-киртләч;
Биегәя гомер узган саен.
Сузылырсың – сулуларың җитмәс...

Кул болгыйлар...
Ниләргә дип инде
Алар шулай биек менде икән?
Хәтер тауларыннан төшәлмәсне
Берсе дә соң әллә белми микән?!

Ул тауны бит сабакташлар белән
Бергә өйгән идек, ташлар ватып.
Мин күчереп кенә алдым бары...
Сыза алса, сызып ташлар Вакыт.

Сызып ташлар,
Ләкин гөнаһысы,
Гөнаһысы берүк миңа түгел!
Күпме таулар калган...
Кул болгыйлар...
Бездән генә күчкән йола түгел!..

* * *

Кояш чыгар.
Сулар сулкылдашыр.
Еракларга сузылып, җил исәр...
Искән җилдә, исен җыялмыйча,
Иләсләнеп йөрер бу исәр:

Тауга менәр,
Үзәннәргә төшәр,
Урманнарга кереп югалыр...
Юкка гына,
Юкка гына йөрер, –
Әйталмаслар икән шуңа бер!

Иләс-миләс килеш китеп барыр.
Өсләренә кыргый гөл үсәр...
Акыллылар арта барган саен,
Шул исәрне эзләп җил исәр...

* * *

Йөрәгемдә йөрткәнгәме –
Гөл, диделәр ярамны.
Гөл, диделәр...
Алсуланып,
Яраннарга таралды.

Минем генә ярам түгел,
Тимәгез яраннарга:
Ал буласылары бардыр,
Заманнар каралганда...

* * *

Тартылган кыл сыман зыңлап тора
Шыр ялангач калган бу киңлекләр.
Ямансудыр... Бәйрәм түгел инде
Җир йөзенә килгән ятимлекләр.

Кими бара дөнья:
Арабыздан
Җелек кебек замандашлар китә.
Кителә чор...
Бөтенлектән безне
Нигә болай иртә мәхрүм итә?!

Сагыш арта. Чаларадыр чәчләр.
Олыгая адәм балалары.
Киткәннәре – җилдер,
Шул җилләрдә
Саргаялар икән калганнары.

Бер-бер артлы замандашлар китә,
Өлгералмыйсыңдыр кул болгарга.
Карап торасыңдыр
Күз алдында
Бетә барган фани дөньяларга...

* * *

Замананың шакшысына
Бетәсең дә буялып,
Яшисең гомер буена,
Үз-үзеңнән оялып.

Чыгарга кыенсынасың
Кешеләр каршысына:
Төртеп күрсәтер шикелле
Аларның барсы сиңа.

Кайберәүләргә килешкән
Битлек бирәләр – алмыйм:
Битлек инде – читлек бит ул,
Ничек читлектә калыйм?

Карыймын да бер як-якка,
Бер алдыма, бер артка,
Дөньяга куям йөземне, –
Киндерне туң агарта...

* * *

Дөньялыкны кичеп чыгып барам,
Үзем генә белгән юл кала...
Сулкылдаган күкрәгемне куеп,
Бер суларга җитте бу ара.

Үзем генә белгән юлым кала,
Бүтәннәрнең миндә ни гаме?!
Кайгыларың чаклы дөнья бит ул –
Бер сулышта кичеп чык аны!..

# И ЭЗЛӘРСЕЗ ӘЛЕ...

*Харис җырлаганда*

«Кара да гына урман, караңгы төн...» –
Кем баласы урман эчләрендә?
Төнгә каршы кая бара болай,
Ни гомерләр җырга күчкәненә?

Урман эчләрендә кем ярасы? –
Кагылмагыз берүк, сорамагыз.
Ил кадәрле ил имгәнгән чакта,
Берьялгызы сызлар бу ярагыз...

Җан ачысы белән кычкырасы –
Урман эчләрендә урман икән.
Карурманнар булып, башкайларны
Заманалар көтеп торган икән!

Агачлардан агачларга сугыл:
Тып-тын калып тыңлар алар сине.
Булыр әле илләрнең дә, бәлки,
Үз баласын бирәр аңлар көне.

Төнгә каршы кая бара болай? –
Кайгыларга кабат сала безне.
И эзләрсез әле
Урманнарда
Адаштырып киткән балагызны...

# III. Гамәл дәфтәре

...Үз дәфтәрем ләкин үзем язам, —
Фәрештәләр кулы чыдамас!..



* * *

Бу туфракка күпме җылы сеңгән,
Елгаларда күпме җыр аккан,
Никадәрле гөлләр сулып кипкән,
Җир өстенә күпме ел яткан!

Бер тамчы да үзгәрмәгән хәят,
Әй, җиһанның изге баласы!
Сиңа кадәр күпме шулай булган
Һәм күпмегә шулай каласы...

Ләкин җирдән эзсез китәбез дип
Дулама, җан, әрнеп елама.
Елгаларда әле чит җыр түгел,
Ят җыр түгел, – безнең җыр ага.

Мең елдан соң, бәлки, тагын берәү
Без тукталган шушы урында
Башкаларга сөйләр бу туфракка
Бездән сеңгән җылы турында...

## ТӨНБОЕКЛАР

Төнбоеклар, төнбоеклар...
Күл өсләре чуп-чуар,
Күзләреңә бу кадәрле
Карый икән ник шулар?

Судагы килеш яналар
Алсу сер учаклары,
Аңларбыз сыман шул утка
Йөрәкне куйсак бары.

Хәтта еллар җитмәс кебек
Дөрли-дөрли янарга,
Калыкса чорлар төбеннән
Барлык асыл җаннар да.

Без ишетмәгән исемнәр,
Без белмәгән ирләр күп.
Заманалар...
Заманалар –
Төнбоеклы күлләр күк!

* * *

Акты Вакыт.
Сиздермичә генә
Узган чакта безнең аркылы,
Кагылды да йөрәкләребезгә,
Төрле төскә кереп саркыды.

Әллә ничә төргә таркалдылар
Безнең җанда көннәр-сәгатьләр:
Сөенечкә, кайгы-хәсрәтләргә,
Мәхәббәткә, моңга –
сәбәп бар!

Еллар килә...
Кырык төрле кылга
Сүтеләдер бездә бу Вакыт.
Мин гомердән торып калырмын күк,
Кырык кыллы сазым уйнатып...

* * *

Төнге күктә кемдер шырпы сыза, –
Офыккача сузыла эзләре,
Тик кабынмый никтер шырпылары...
Кайсыгызның нәрсә эзләве?
Яшь гомерне югалттыгызмыни,
Табалырсыз микән сез аны?
И интегә берәү,
Төннәр буе
Әрни бәгырь шуны кызганып...

* * *

Нигә болайдыр язмышлар,
И табарга бирәр әмәл:
Янар өчен яралып та,
Зая узган гомерләр жәл.

Әрәм кала күпме сөю –
Каян килгән кадерсезлек!
Үкенечкә булмас микән
Бездәге бу бәгырьсезлек?

Күпме хаклык тел очында
Әйтелүне көтеп тора,
Шул хәлендә безнең белән
Дөньядан да китеп тора...

Көтми безне,
Бөтенесен
Бара вакыт туфрак итеп,
Яшәмибез микән кайчак
Бу яшәүне исраф итеп?..

* * *

Күпме шәфәкъ ябып киткән нурын –
Заманнарның өсте – ал юрган,
Бөтенләй үк күмәлмәгән вакыт
Үткәннәрне, –
Безгә калдырган.

Бер карыйсы килә,
Офыклардан
Шул юрганның читен күтәреп;
Үткәннәргә бер дәшәсе иде,
Юл табылып җаның үтәрлек.

Катлам-катлам вакыт асларыннан
Тавыш килә бугай, чү, каләм!
Заманнарның кайтавазларыннан
Шаулап тора сыман бу Галәм.

Бик күптәннән яңгыраган моңнар
Өлгермәгән әле тынарга,
Офыкларга карап кулым сузам –
Кагылырмын сыман шуларга.

Баеп бара кояш...
Җир өстенә
Пәрдә яба вакыт ал нурдан.
Сизмичә дә кереп бара дөнья –
Үткәннәрнең өсте – ал юрган...

* * *

Тагын берәү – кемдер яши миндә,
Кычкыра ул әнә сузып-сузып;
Сыймый моңы күкрәгемә генә,
Таралмаса җилләр белән тузгып.

Сискәнешеп гөлләр баш калкыта,
Моңланалар түзми яз кошлары. –
Эчкәредән килгән ул тавышта
Таныйлармы әллә язмышларны?

И кычкыра –
тиеп китә өне
Даладагы кабер ташларына,
Күтәрелә болытларга кадәр
Һәм сарыла кылган башларына.

Агачларга кагылып узды әнә –
Коелып калды сары сагышлары,
Диңгезләргә барып җитте бугай –
Ярсуланды дулкын кагышлары.

Бу йөрәктә бер кузгалган аваз,
Юк, басылмый икән басылмаса!
...Кемдер дулый миндә –
Тарсынмыймын,
Әгәр мине үзе тарсынмаса...

## САБЫРЛЫК

Җирдә таулар – күк терәве сыман,
Җилләр сүтә болыт-чалмасын.
Илдә картлар – чор намусы сыман,
Мең уена төргән чал башын.

Таулар дәшми,
Алар телгә килсә,
Тирә-ягын ялкын-ут баса.
Картлар сабыр...
Картлык буламыни
Бар хәсрәтен эчкә йотмаса!

Чал башларга басып тора Вакыт –
Хикмәтле бер хәлдер сабырлык, –
Җирдә таулар, илдә картлар барга
Сизелмидер төсле авырлык...

## САНДУГАЧ ҮЛЕМЕ

Урманнарга сыймый,
Бу җаннарга
Ничек итеп сыйсын көйләре!
Башка үлем юктыр сандугачка:
Ярыладыр моңнан йөрәге...

* * *

Тирәләре яшел үлән,
Түбәләре күккә тигән;
Кемнәр чапкан, кемнәр өйгән:
Болыннарда – кибән... кибән...

Кибән-кибән тезелешеп,
Җәй көннәре китеп бара
Саубуллашкан кошлар сыман,
Ераклаша һаман ара.

Уза гомер...
Кибән түгел,
Эскерт-эскерт булыр сыман
Җыеп өйсәң җаннардагы
Моңсулыкны... Кеше – чыдам!

Быел печән өсләрендә
Авыл җәйне җыеп өйгән.
Һәр кибәне бер гомер күк,
Түбәләре күккә тигән...

# ХИРОСИМА ТАШЫ МОНОЛОГЫ

*Атом бомбасы шартлаганда нурланыш нәтиҗәсендә бер кызчык сурәте ташка уелып калган.*

Бу җиргә мин мәңгелектән килгән
Эремәс бер гади таш идем,
Кешеләргә катылыгым белән,
Салкынлыгым белән фаш идем.

Җир ярылды, таулар ишелделәр,
Еллар янды – ләкин дәшмәдем, –
Мин битараф калдым барсына да...
Күпме еллар шулай яшәдем.

Ә ул көнне миңа бер кыз килде,
Ак күбәләк уйнап йөргән күк...
Бер мизгелдә ташка әйләнде ул,
Яман әфсен укып өргән күк.

Күбәләктәй көйде кызчык утта,
Һәм... Җан керде миңа шул мәлдә;
Таш булсаң да түзәлмисең икән,
Гөнаһсызлык утка кергәндә.

Фотопластинка түгел идем,
Гади бер таш идем мин бары;
Бу мизгелне төшереп алу өчен
Түзми иде кеше куллары.

Мин төшердем...
Менә – күкрәгемдә
Ничә еллар инде бу рәсем,
Җинаятьнең бер шаһиты булып
Киләчәккә барын сөйләсен.

Ә сабыйны эзләп интекмәгез,
Ул нәни кыз – менә мин булам,
Таш түгел мин, –
Дәвер күкрәгендә
Ташка уеп язган моң булам.

Таш булсаң да түзәлмисең икән...
Җир йөзендә күпме таш калыр –
Күбәләктәй көйсә гөнаһсызлык,
Кешеләрдә булса таш бәгырь...

* * *

Бөтенесе туфракка сеңгән –
Яңгырлар да, аккан сулар да;
Үлән төпләренә вакыт сеңгән,
Сеңгән чорлар... Иеләм шуларга.

Кайгы-шатлык, сөю-нәфрәтләрдән
Тора бугай баскан нигезем:
Барысы кичте җаннан –
Шул туфракта
Тамырланган бер гөл мин үзем...

Үткәннәр дә сулый, сөйли бугай:
Чишмәләргә колак салыгыз –
Бу бит тирән катламнардан чыккан
Бик борынгы сабый чагыбыз.

Үтеп китми вакыт – җиргә сеңә,
Күпме гасыр туфрак эчендә?!
...Кайсы төшкә атларга да белми
Басып торам чорлар өстендә...

## БЕЗ — БЕРБӨТЕН

Аералмый кешеләрне Вакыт –
Бер җан бугай алар тоташтан:
Бу дөньяның бөтен дәверләре
Каннар белән безнең тоташкан.

Чишелмәслек булып бәйләнгәннәр
Ялгау төеннәре күкрәктә:
Ерак үткәннәр һәм килер көннәр
Җитәкләшә безнең йөрәктә.

Без – бербөтен,
Шуңа күрә бүген
Әрнү килә миңа үткәннән;
Күпме төен аша киләчәккә
Тетрәнүем күчәр бу тәннән.

Текәләм мин килер көннәремә –
Ниләр кичәр безнең бу баштан?
...Кайсы чорда яшәсә дә Җирдә
Бер җан икән Кеше тоташтан!..

# СУЛАР АГА

> Идел буйларына барсам,
> Әйтер идем Иделгә,
> Минем сагышларымны да
> Илтеп сал, дип, диңгезгә...
>
> *Халык җыры*

Чишмәләрдә сулар ага,
Челтер-челтер ага сулар...
Су алырга төшкән кызлар
Йөрәк серен сала шуңар.
Уйный-уйный сулар ага,
Ага сулар инешләрдә.
Бәхет иңә дулкыннарга,
Яшь киленнәр көлешкәндә.
Сулар ага елгаларда,
Ага сулар сулык-сулык, –
Яшьли калган әнкәйләрнең
Саркып бетмәс моңы булып.
Дөнья буйлап сулар ага,
Бертуктамый ага сулар:
Хәсрәтләр, сөенечләр.
Үкенечләр, яратулар...
Кая таба карасам да –
Сулар гына, сулар гына...
И йөрәкләр...
Диңгезләрне
Хасил иткән шулар гына!..

* * *

Тагын бер көн китеп барды бездән
Тавыш-тынсыз гына,
Ерактан
Кул болгады бугай: күк читендә
Ал яулыгы калды уйнаклап...

## БЕР УЙЛАСАҢ...

Төн эчендә чәч агара, диләр,
Кинәт килгән авыр кайгы барда...
Саргайганнар бары төн узганчы –
Нинди хәсрәт төшкән каеннарга?

Көз килүгә сылтап куябыз да, –
Белмибез шул агачларның хәлен,
Сизмибез шул, җәйге яфракларның
Мәңгелеккә саубуллашкан мәлен...

Яфрак-яфрак көннәр китеп бара –
Берәребез шунда сагаер ник!
...Бер уйласаң, безнең бу гамьсезлек
Төн узганчы чәчләр агарырлык...

## БӘЙРӘМНӘР

Кешелекнең үзе шикелле үк,
Борынгыдан килә бәйрәмнәр,
Шатлыкларын бәйрәм итә кеше, –
Бәйрәмнәрдә олы ямьнәр бар.

Җир шаулатыр бәйрәмнәрең булсын...
Бәйрәме бар халык – бай халык,
Гасырларның бәйрәм җилләрендә
Җыры кала,
Байраклары бара чайкалып.

Бәйрәмнәрдә – бәхет тантанасы,
Җан сафлыгы, күңел яктысы.
Гомер буе озатып бара безне
Бәйрәмнәрнең керсез ак төсе.

Тар күңелдә була алмый бәйрәм...
Бәйрәмнәргә кирәк мәйданнар;
Борынгылар җаннар матурлыгын
Мәйданнарга,
Гасырларга җәеп салганнар...

Кешелекнең үзе шикелле үк,
Борынгыдан килә бәйрәмнәр;
Бәйрәмле дә, җырлы да син, халкым, –
Киләчәккә иңәр ямьнәр бар...

# ИСӘНЛЕК

Кичләремә: «Хәерле кич!» – диләр,
«Исәнмесез!» – диләр иртәмә.
Көннәремнән хәл белешә дөнья,
Уйга салып йөртә-йөртә дә...

Һәр теләге ләкин кабул булмас,
Хәл белүдән дәрман табылмас:
Илгә-җиргә тоташ ирләр җаны
«Сау бул!» – диеп кенә сау булмас.

Ир саулыгы – ил тынычта гына,
Бәхет белән көннәр хәерле;
Исәнлекме – үксез сабыйларның
Күз яшьләре телсә бәгырьне?!

Явызлыклар өстен чыкса әгәр,
Егылып калса сафлык, тапталса...
Җинаятьтер – җирдә хаксызлыкны
Күрә торып, җаның сау калса!

«Исәнме?» – дип хәл сорыйлар дуслар,
Дөрес булыр икән ни дисәм?
Илләр имин чакта – бәхетле мин,
Бәхет барда җирдә – мин исән!..

## ОЧА КОШЛАР...

Язлар килә, җәйләр җитә,
Көзләр керә, кышлар уза. –
Һаваларддан күзем алмыйм:
Кошлар оча... кошлар оча...

Оча кошлар...
Кайсы чордан
Кемнәр җаны күтәрелгән? –
Кәрван-кәрван узып бара
Безнең дәвер күкләреннән.

Гамьсезлекне ертып уза
Үзәк өзгеч тавышлары, –
Йөрәкләрнең моңын болай
Кая алып барышлары?

Ничек көйми канатлары? –
Бәгырь аша оча кошлар;
Канатланып очар икән
Җаннардагы бу сагышлар!

Һавалардан күзем алмыйм –
Кошлар оча... кошлар оча...
Күтәрелеп барам сыман
Очкан кошлар арасына...

# ДӨНЬЯ БҮГЕН

Иренендә – сөт тамчысы,
Белгәне дә – «әни» генә.
Бар да яңа, бар да гаҗәп! –
Дөнья әле сабый гына...

Иңдә – хыял канатлары,
Уза алмый бер җилең дә;
Никадәрле сафлык җирдә! –
Дөнья бүген унҗидедә...

Иңгә төшкән олы бурыч,
Аны ничек онытасың?!
Ил кайгысы башкайларда, –
Дөнья бүген – ир уртасы...

Артта калган бөтенесе,
Кулдан барлык эшләр киткән.
«Булды микән соң ул яшьлек?» –
Дөнья инде бер карт икән...

Артык та һәм ким дә түгел:
Дөнья – бары бер гомерлек;
Җирдә безгә бертуктамый
Гомер буе йөгерерлек!..

# НИГӘ БОЛАЙ?

Ераклардан урап-урап, нигә болай
Көне-төне туктамыйча ага сулар? –
Үләннәргә, игеннәргә, агачларга
Шифа-шәфкать, гомер алып барасы бар.

Нигә болай бу мәһабәт кыя ташлар
Сузылганнар болытларга терәк булып? –
Ни килсә дә сыгылмыйча, мәңге шулай
Торасы бар чыдамлыкка үрнәк булып.

Күз яуларыңны алырлык гөлләр белән
Балкый нигә болыннарда җәй уртасы? –
Бар икән шул ел да бер кат бу дөньяга
Сафлыкны һәм матурлыкны танытасы...

Ни әйтәсе бар соң безгә Табигатьнең,
Күңелләр ник тартылалар һаман шуңар? –
Үзебезнең кем икәнне онытмыйча,
Киләчәккә Кеше булып барасы бар!..

Буразналар шунда кучкәнмени –
Маңгаенда бары сыр да сыр,
Дәшми-тынмый карап тора миңа
Ап-ак чәчле тулы бер гасыр...
Күпме күргәндер ул!
Ә үзенә
Тора-тора хәйран калырлык:
Гасырлар шул сүзгә саран була,
Гасырларның холкы – сабырлык...
Әйтмәсә дә ачык: печән чапты,
Иген икте, бура бурады,
Яулар кичте...
Утлар-сулар аша
Гасырларның үткән юллары!
Сүзләр нигә? –
Кылган гамәлләре
Бөтенесен безгә белдерде:
Яманлыкның юлы кыска була,
Ә игелек – озын гомерле.
Ләкин җаны һаман тыныч түгел, –
Күргән аһ-зар һичбер онытылмас;
Аның өчен еллар – малай гына...
Ул малайлар Җиргә ни кылмас?!
Бер үк теләк бугай гасырларда,
Гасырларда – шул ук тиңдәшлек:
Кисәтәләр сыман,
Сүзсез генә
Киләчәккә таба эндәшеп...

## ҖИРДӘН КИТКӘННӘР СҮЗЕ

Бу дөньяда без дә яшәп киттек:
Тир агыздык... сөйдек... еладык...
Кичергәннәр – ерак дәверләргә
Зур бер дастан итеп юлларлык.

Сөйгән саен – сөю арта барды,
Җырлаганнан – сагыш бетмәде;
Уйларыбыз елгаларда акты,
Биегәйтте зәңгәр күкләрне.

Яшәп киттек без дә, яндык-көйдек...
Эзләмәдек шуннан артыкны:
Безгә кадәр берни түгел иде –
Тарих итеп яздык Вакытны...

## КОЯШ ТОТЫЛГАНДА БЕР УЙ

Ай барыбер Кояш булалмый,
Кояшны каплап кына;
Дәрәҗә килми кешегә
Кешене таплап кына.

Мәкерле җан нинди генә
Юлларын эзләмәсен –
Күрәлмәс, мәңге күрәлмәс
Кояшның күләгәсен!..

# КАРАШ

Балкып очкынлана, үзенә тарта,
Борчуларны оныттыра, –
Ул күзләрдән кем соң карап тора?

Ышана, иркәләнә, җанга сарыла,
Ярата һәм яраттыра, –
Ул күзләрдән кем соң карап тора?

Мөлдерәп тула, ярдәм сорый, инәлә,
Өметләнә һәм ялвара, –
Ул күзләрдән кем соң карап тора?

Бел син, Кеше –
Бөтен ышанычын сиңа төбәп,
Сабый күзләреннән Киләчәк карап тора...

# АКБҮЗ АТ

## I

Яшел чирәм безнең капка төпләре...
Балачакны җәеп куйдык чирәмгә:
Кем булсаң да, сакланып бас аңар син,
Юлың төшеп, безгә керим дигәндә.
Чит-ят хәбәр калып торсын урамда, –
Ак бәхетләр өчен генә бу нигез!
Әнкәй мескен инде көтеп аргандыр,
Ә без әле өйгә һаман кермибез.
Әткәй дә бит никтер менә күренми,
Ул кайтасы иде бүген ат җигеп.
Тәгәрәшеп яшел чирәм өстенә,
Дүрт күз белән и көтәбез, чак түзеп...

## II

Нигә болай зарыктырдың син безне,
И әткәем, тордың икән ник озак?!
Иртәдән үк безнең капка төбенә
Сине эзләп килгән иде Акбүз ат,
Җанга тиде сузып-сузып кешнәве...
Шуннан бирле инде менә ничә ел! –
Китми һаман, ак ялларын тузгытып,
Җәйдән – көзгә, кыштан – язга күчә ул...
Кайларда соң синең җиккән атларың,
Кайчан яныр, кайда туфрак булдылар?
Яу кырыннан, бер Акбүзгә әйләнеп,
Әллә инде кайттылармы соң шулар?
Әллә монда калган атлар елыймы,
Җан биргәндә буразнага егылып?..
Типмә, Акбүз, типмә капка төбенә, –
Йә өстеңә еллар төшәр убылып!

## III

Балачакны җәйгән идек чирәмгә,
Ак бәхетләр өчен иде бу нигез...
Мескен әнкәй инде көтеп аргандыр,
Җәй-кышларым, әйдә, өйгә керегез!
Ә Акбүз ат, ак ялларын тузгытып,
Иртәгәмә минем барыбер күчәр ул, –
Кешнәп йөри безнең капка төбендә,
Китми мескен менә инде ничә ел!..

# КҮЧТӘНӘЧЛӘР ТӘМЕ ТЕЛЕМДӘ...

Сезнең белән сөйләшергә
Сандугач теле кирәк...

*Халык җыры*

Кунак-төшем – бик борынгы гадәт,
Сүз генә бир җырга-биюгә! –
Тансыклаган, көткән кунак булып,
Бәйрәм кергән авыл өенә.

Гел кайгырып яшәмәгән татар,
Бәйрәм иткән язын... Кыш көне...
Күчтәнәчсез бәйрәм буламыни! –
Табыннарга килгән кош теле,
Чәкчәк чыккан...

Җан җылысын халкым
Күчтәнәчләр итеп өләшкән;
Бәйрәмнәрдә безнең ата-баба
Кош телендә генә сөйләшкән!..

Үткәннәрнең матур гадәтләре
Югалмыйча күчкән бүгенгә:
Бәйрәм гөрли татар өйләрендә,
Күчтәнәчләр тәме телемдә...

## УРМАННАРГА ҖӘЙЛӘР КЕРЕП КИЛӘ

Урманнарга җәйләр кереп килә –
Алдагы җәй, япь-яшь, өр-яңа,
Агачларга яшел балкыш сирпеп,
Сөю белән карый дөньяга.

Яшь кызлардай ул оялып кына
Кулын суза җиргә, Җил белән
Шуып төшеп бара сиздермичә
Ак шәльяулык җәйнең иңеннән...

Урманнардан җәйләр китеп бара –
Кичәге җәй, сулган, саргайган.
Моңсуланып карап тора сыман
Ераклардан, әллә кайлардан.

Без дә җирнең бер җәйләре генә,
Бер генә кат яфрак ярабыз.
Шатлык булып киләбез дә җиргә,
Сагыш булып китеп барабыз...

## ГАМӘЛ ДӘФТӘРЕ

Ишеткән бар: һәр кешенең, имеш,
Була икән гамәл дәфтәре –
Фәрештәләр язып бара икән,
Түкми-чәчми, кылган эшләрен.

Яхшылыгым, яманлыгым шунда,
Җимергәнем, урган-чәчкәнем.
Исәп-хисап – шушы дөньяда ук,
Гомер үзе – гамәл дәфтәре.

Кылыр эшләр тау кадәрле икән,
Яшәү дигән юлга чыгылгач.
Үз дәфтәрем ләкин үзем язам, –
Фәрештәләр кулы чыдамас!..

* * *

Гаҗәеп бер әкият эчендә без:
Сөенәбез... Газап чигәбез...
Янып көл булабыз...
Ул әкияттән
Китмибез соң әле нигә без?

Борынгылар үз әкиятендә калган,
Үз диюен җиңгән һәр Алып...
Безнең әкияттән дә бер яктылык
Китәр сыман җиргә таралып.

Җирдә яшәгәннәр әкиятне дә
Калдырырга тиеш җылытып.
Гаҗәеп бер әкият эчендә без –
Бер сөйләрләр, бәлки, чын итеп...

* * *

Башкаеңны кая куяр идең? –
Әле ярый, җирдә Моң яши,
Бер елата, бер юата җанны,
Сабыйларча хәлгә килгәнче.

Ул барында, сафлык-игелекнең
Торып торсын читтә мең юлы:
Кер-мәкердән азат Моңлы күңел,
Байлыктыр ул – җанда Моң булу!

Тиргәмәгез бәхет теләми дип,
Теләгем шул сезгә: Моң бирсен! –
Бара алсаң аңа юлдаш булып,
Бәхетлесе җирнең – синдерсең.

Ир-егетнең олы йөрәгендә
Атлар белән бергә Моң ятыр, –
Бу дөньядан инде өмет өзгән
Күңелләрне барып уятыр...

Соң сулышта кеше суга мохтаҗ...
Тик ул гына җанга аздыр ла:
Мәрхәмәтле дөнья,
Шул чагымда
Моңнан гына мине яздырма!

## КЫШКЫ ИДЕЛ ӨСТЕНДӘ

Идел бит ул, тирән бит ул...
*Халык җыры*

Ниләр генә күтәрмәгәнсеңдер,
Исең китмәс артык монсына:
Җилдәй уйларым да, чаңгыларым –
Йөк түгелдер, Идел, мин сиңа.

Кар өстеннән сизелмәс тә әле –
Идел өчен ни ул бер йөрәк!
Йөрәк өчен әмма Идел – илдер,
Сөйлә аңа: хәлең ниндирәк?

Шикләнмичә эчкәререк керсен,
Кыш уртасы инде – боз калын.
Уйламасын ләкин үткәнеңне –
Боз күтәрмәс диеп куркамын...

Борчуларын тышка чыгармасын,
Йөрәк бит ул: эчкә йотала!
Еллар күптән белә – синең сулар
Сабырлыкны өстә тотала...

Син барсын да күтәргәнсең, Идел:
Салмагандыр халык ниләрен? –
Сөйлә миңа –
Инде Иделләрне
Күтәралыр сыман йөрәгем!..

## ӨЙ САЛУ

Васыять итеп калдыргандыр безгә,
Юкка әйтмәгәндер бу халык:
Үз гомереңдә бары бер булса да
Син керергә тиеш өй салып.

Борынгылар шуңа тугры булган...
Үткәрмәгән яңгыр-җилләрне,
Яман күздән нәселен саклап килгән
Бабайларның салган өйләре.

Әтиләр дә салган үз өйләрен,
Бүрәнәнең сайлап юанын.
Ата йорты – бала өчен кыйбла,
Читкә типкән чагы юк аның.

Мин дә, менә, үз куышым салам,
Гомерем буе салам бер өйне.
Нәселемнең изге төсе итеп,
Бабайлардан алам өлгене.

Нигезе нык, һавасы саф булсын,
Иркен булсын, димен, эчләре;
Күңелләрне яктыртырлык булсын
Гадәтләрнең монда кучкәне.

Капкаларын бизәк-бизәк итәм –
Балкып торсын ил-көн каршында,
Үткән-сүткәннәрне тартып торсын,
Кунак итсен, чакырып алсын да.

Кеше өзелмәсен: керсен дуслар,
Төн кунарга төшсен юлаучы;
Балаларым кызармаслык булсын,
Оныкларга җитсен җылысы.

Бүрәнәдән, агач-таштан түгел,
Өйне салам күңел нурыннан –
Әллә каян-кая күренерлек
Итәр идем, килсә кулымнан.

Мин өемне гомерем буе салам –
Күрше-күлән гаеп итмәсен.
Бар өйсезләр өйле булсын, димен,
Килгән кеше кире китмәсен...

* * *

Күкләрдә – мәңгелек болытлар,
Борынгы суларда карашың;
Тыңлыйсың чал җилләр искәнне –
Моңаймый, олыгаймый кара син!

Агачлар яшәрә,
Болынга
Өр-яңа чәчәкләр сибелә.
Бар нәрсә яңадан туганда
Яшәрми нишләрсең син генә?

Җавапсыз табышмак шикелле
Килеше, яшәве, китеше –
Борынгы, мәңгелек дөньяда
Чал чәчле сабыйдыр бу кеше...

# КОЯШ ТОТЫЛУ

*31 июль, 1981*

Шомлы иртә:
Таңны сискәндереп,
Эт аталар...
Кояшны каршыларга чыккан
Йөрәкләрне туктаталар!
Чабып барган җирдән
Тәгәрәп китә гөнаһсызлык;
Эт йөрәген куып тота үлем,
Кеше йөрәгеннән сузылып...
Ни гөнаһлар шомлыгыдыр –
Иртә таңда
Эт аталар кояш тотылганда.
Кеше карашында оча үлем:
Күзен капла, дөнья, син,
Кояшны түгел!
Көчек булып
Үлән арасына кача
Гөнаһсызлык,
Эзләп табып, бәреп ега үлем,
Мылтык көпшәсеннән сузылып.
Сүнә бара кояш эт күзендә –
Тигәнме соң әллә ядрә
Кояшның үзенә?

## ГАҖИЗЛЕК

Хәйран калып карап тора агай
Гомер иткән өе урынына:
Каз оясы кадәр генә чокыр...
Ышанмассың нигез булуына.

Ак сакалын учлап, уйга баткан:
Иркенрәк иде бит соң өе!
Ничек болай кеп-кечкенә калган? –
Шунда гомер узган диген инде!..

Ничә бала үскән төштә хәзер
Кычытканнар бары, алабута.
Йома икән туфрак...
Киткәненә
Бик күп түгел әле алай ук та.

Истәлекләр эзләп кайткан иде –
Өй нигезе саклап торалмаган.
Тик тырнала күңел:
Еллар барысын
Тигәнәкләр итеп йомарлаган.

Кылган эше кая? –
Әйтерсең лә
Гомер буе монда чәчкән үлән!
Күрде агай үзе китеп баргач
Ни калганын кеше гомереннән...

* * *

Үз хәлеңне үзең генә белдең:
Суга төштең, утта яндың да;
Авыз тулы кара кан булса да,
Төкермәдең ятлар алдында.

Егет сере – кыныдагы хәнҗәр, –
Кулына сук, дошман үрелсә;
Аяк өсте тора алмас бәхет,
Ирләр йөрәгендә сер үлсә.

Сер тотмаган – илдә көн күрмәде,
Җилгә сер сөйләгән – сөртенде.
Сереңяшер дуслар йөрәгенә –
Гөлләр булып шытар беркөнне...

* * *

Елыйм, дисәң – күптән яшең чыкмый,
Җырлыйм, дисәң – җырлап көй бетми;
Күбәләкләр булып талпынасың –
Җаннарыңа синең ни җитми?

Җаннарыңа синең ниләр җитми,
Ник сөйлисең сереңкошларга? –
Җәйгә чыксаң, синдер урманнарда,
Бураннарда – керсәң кышларга...

Үткәннәрдән килеп, билгесез бер
Киләчәккә китеп барасың.
Нишләтергә йөртә икән болай
Сине дөнья – үги баласын?..

* * *

Үзеннән дә зурны күтәрә дип,
Сокланабыз карап кырмыскага.
Аның белән безне тиң күрәме –
Сайлап тормый йөкне, тормыш сала.

Кызганычтыр кеше:
Югыйсә бит
Болай, төпле генә бәдән була –
Ә шулай да үзеннән дә кече
Дан астында калып әрәм була...

Бер хаталык булып табигатьтә,
Җайга салган чакта бу дөньяны,
Кеше белән кырмысканың ялгыш
Буталмады микән урыннары?!

* * *

Нигә уфтанырга, арткан өчен
Башлардагы ак чәч бөртеге? –
Чал башыңны исәң кешеләргә,
Аклык бит ул әле – кер түгел!

Аклыгы да, картлыгы да килә,
Читләп үтми адәм баласын.
Чәч агара диеп кайгырма син –
Кайгырганга чәчләр агарсын...

* * *

Күзгә күренмәс булырга
Кем генә кызыкмаган! –
Абага чәчәгенә тик
Барыбер юлыкмаган.

Кемнең кемлеге шулай да
Тиз генә беленмидер:
Кеше, ахры, тулысынча
Кешегә күренмидер.

Никадәр мәкерле җаннар
Йөридер арабызда,
Сугып китәләр йөрәккә –
Күрмичә калабыз ла!

Юкка да алданмас идең,
Һәрбер сүз чыннан булса,
Уй-хисләр кеше күзенә
Күренә торган булса.

Урмангамы, елларгамы –
Каядыр барасы бар:
Күңелне күрсәтә торган
Чәчәкне табасы бар...

## АЕРЫЛУ

Күк күкрәде.
Иң беренче күкрәү.
Тәгәрәдек дәррәү җиргә ятып.
Җәй белән кыш аерылды бүген –
Күкри-күкри аерылды Вакыт.
Күкри-күкри аерылып калды
Узган кышта кичергәннәр безнең.
Дөньяларны ярып сөрән салмый,
Әле дә сабыр кеше, әле дә түзем!
Кире эзләп алалмаслык чаклар
Китә бездән, китә аерылып,
Күкрәүләр һәм тетрәнүләр аша
Узганнарга карыйм каерылып.
Үзенә күпме тартып кайтарыр да,
Ничә кабат әле тезләндерер:
Узган кышта, шушы узган кышта
Газизләре кала кемнәрнеңдер.
Көзләр, кышлар, язлар белән китә,
Акрын гына китә җирдән кеше.
Каерылып карыйм: күкрәүләрнең
Аргы якларында бөтенесе...
Тагын бер кыш калды аерылып,
Шуның өчен тетрәнгәндер күкләр.
Кешеләрнең күкрәгеннән бәреп
Чыга кебек миңа язгы күкрәү!

* * *

Яраткан да җан иясе итеп,
Йөрәк биргән Ходай, биргән сулу.
Беленәдер яшәп карау белән:
Җиңел түгел җанга ия булу!

Әле ансын сорый, әле монсын –
Читлектәге коштай талпына ул;
Сизми калсаң, көячәген белми,
Барып керә хәзер ялкынга ул.

Җаның теләгәнне эзли-эзли,
Бәла-казаларга юлыкканда,
Җавабын да сиңа бирәседер,
Ия булгач шул кыбырсык җанга.

Барсына да түзеп киләсең дә –
Нишләтерен әле кемнәр белгән?!
Риза булмый болай яшәвенә,
Чыгып китәр ул барыбер миннән...

## КАРА ТАУ

*Кара Тауның биеклеге –*
*диңгез өсте тигезлегеннән*
*577 метр.*

Диңгез төпкеленнән калыккандай,
Күккә ашып тора Кара Тау.
Узган халык – Кара Таулар калган,
Юк, тауларны булмый таратып...

Халык биргән исемнәре исән –
Киләчәккә карап юл саба.
Җирдә бездән Күк Түбәләр калсын,
Таулар калсын... кара булса да.

Диңгез булып, диңгез башын ия,
Туктап торып диңгезлегеннән;
Кара Тауның биеклеген үлчим
Карап чорлар тигезлегеннән...

* * *

Туган ил киң: җәелгән ул
Җәйләргә һәм кышларга;
Илеңнең бер кисәгедер
Күктә очкан кошлар да.

Китәләр көзен... Ямансу –
Илдән аерылам сыман,
Җил җәйге канатларымны
Минем каера сыман.

Уза кышлар да... Кайталар,
Кайталар туган илгә! –
Кошлар кайткан язгы мәлдә
Киңәеп китә ил дә...

* * *

Иң беренче – телгә төшә каргыш,
Әгәр сине язмыш каргаса.
Талга кунып, сандугачлар беркөн
Кычкырмаслар димә каргача.

Юкка гына булыр әйтүләрең,
Карга түгел бит син, сайра, дип.
Бәхәсләшер алар синең белән:
«Мин – сандугач түгел, карга», – дип...

* * *

Күләгәле дөнья, күләгәле...
Көйли белсәң, җаеңа көйләмәле.
Кояш яктысына чыкмак булсаң,
Гомер белән кайчак түләмәле.

Күләгәле еллар, күләгәле...
Күләгәләр аша күрәм әле,
Язмышларын янган утка салып,
Күләгәгә керми үлгәннәрне.

Җирдән төшкән кара күләгәне
Төн дип йөрткәннәрен беләм әле;
Күңелдәге нәни кояшымны
Төннәр өчен саклап киләм әле,
Күләгәле яшәү, күләгәле...

* * *

Яманладым бүген мин берәүне,
Әллә ничек, табып юктан гаеп –
Күз алдында бөлдем, зәгыйфьләндем,
Бөҗәк сыман калдым кечерәеп.

Берәүгә мин бер яхшылык кылдым –
Ышанып кул бирер кешем артты,
Иркенәеп китте сулышларым,
Калкынгандай булдым, көчем артты...

* * *

Утларга салмагыз җанны,
Суларда агызмагыз,
Энҗеләр генә түгелдер:
Эзләрсез – табылмабыз.

Югалткач, беркем табылмас
Зур бәһа түләп кенә;
Сатылмый гомер...
Дөньяда
Без бит – бер бүләк кенә.

Үзебез кешеләр булып,
Кешене танымасак!
...Утларга салмагыз җанны –
Утны ут таныячак...

* * *

Кышның инде соңгы бураннары,
Ә кемнеңдер соңгы кышлары:
Бураннарны алып китеп бара,
Шулай булгач язмыш кушканы.

Бураннарны алып китеп бара,
Соңгы карлар тына юлларда:
Карларга да җиңелрәк иде,
Күңеллерәк иде ул барда.

Хәсрәтләрен ятка белдермәде,
Тапламады һичбер җир ямен –
Бураннарга төреп йөрткәндер ул
Сызлаганда дуамал йөрәген...

* * *

Күпме җаннар канда килеш кала!..
Яшәү тигән безнең өлешкә;
Тик нигәдер аваз сала кеше
Бу дөньяга килә-килешкә.

Җир йөзенә килә-килешкә үк
Елаганбыз инде, көлгәнбез –
Гомерләрнең нидән торганлыгын
Сабый көенчә дә белгәнбез.

Яшәү тигән безнең өлешләргә –
Бәхетле без...
Зарлы-моңлы без...
Гомере буе җавап эзли кеше:
Ирекләме, әллә колмы без?!

* * *

Күңел яхшы иде.
Тик малай чак
Күңелне гел генә тыңламады –
Өлкәннәрнең каршысында башны
Иеп торган чаклар булгалады.

Инде өлкәннәр дә сирәгәя...
Бер-бер гаеп кылган бала сыман,
Башларымны иеп, тып-тын гына
Еллар каршысында басып торам...

# БЕР ГЕНӘ МИЗГЕЛГӘ...

Таңнардан торасың,
Бакчаңа чыгасың,
Ал нурлар сарыла битеңә –
Сизәсең назыннан:
Мәңгелек ягыннан
Сүрелмәс сагынулар китерә.

Ашкынып килә дә,
Тузгытып җибәрә –
Язгы җил аралый чәчеңне:
Наз итеп сиңа бер,
Барсын да җыядыр –
Кемнәрең дөньяга чәчелде?

Болында үләннәр
Аягың үбәрләр:
Дөньяның бу чаклы кеме син? –
Әллә кем түгел дә,
Бер генә мизгелгә
Чорларны үтәли күрдең син...

# ЙӨЗ ЯКТЫСЫ

Иннек түгел – төшми биткә,
Пудрадай ягылмый ул;
Сатмыйлар аны кибеттә,
Блат белән табылмый ул.

Кулларыңа ияләшми
Байлык-фәлән белән генә;
Буйсынмый ул көч-кодрәткә –
Яулап-нитеп алам димә.

Берәүләргә кара ягып,
Йөзең синең яктырмастыр.
Әмма кылган игелегең
Кеше җирдә яткырмастыр.

Каян табыйм икән диеп,
Баш ватасы түгел дәдер:
Безнең йөзләрнең яктысы –
Үзебезнең күңелдәдер.

## КАЕН

Ниләр синең башкаеңда –
Сыгыласың җил саен?
Җилләр белән җитәкләшеп,
Кая барасың, каен?

Җилләр юатыр дисеңме,
Сереңне сөйлисеңме?
Безнең кайгыларны илгә
Таратып йөрисеңме?

Авыл саен, урман саен,
Юллар саен, чор саен –
Безнең белән җитәкләшеп,
Кая барадыр каен...

* * *

Җирдән китү – үлем түгел әле,
Исән булса сине белгәннәр.
Чын үлемең килер –
Сине белгән
Соңгы кеше гүргә кергәндә...

* * *

Сокланмаган кеше юктыр, аның
Җәйге таңда ишетеп моңлы тавышын:
Урманнарны яра... бу җаннарны...
Күреп булмый ләкин сандугачын.

Күзләр җитә.
Тынып кала урман.
Агачлардан яфрак коела бары.
Шунда гына күзгә ташланадыр
Сандугачларның да оялары.

Уч төбедәй моң савытларында
Күреп сандугачлар тыйнаклыгын,
Мин, оялып-кыенсынып кына,
Үзебезнең хакта уйлап куйдым...

## БЕЗНЕҢ ГОМЕР

Безнең гомер – чишмә чылтыравы,
Таң атуы, кызлар көлүе,
Чәчәкләрнең чыкка манчылуы,
Ел да җиргә язлар килүе.

Безнең буын әзли әниләрнең
Ярасына кирәк дәваны,
Безнең гомер – сугыш кырларында
Өзелеп калган җырның дәвамы.

Куркуларны белми безнең гомер...
Шәфкать сорап бармас үлемнән,
Бу көнгәчә горур басып килә
Еraклардан, тарих түреннән.

Безнең гомер – әниләрнең җыры,
Язгы яңгыр, яшен яшьнәве,
Игеннәрнең өлгерүе кырда,
Безнең гомер – җирнең яшәве.

# САБАНТУЙ

Яланнарда сабантуйлар гөрли.
Яшь егетләр сыза гармунын,
Уйнаклатып җилләр алып китә
Еракларга гармуннар моңын.

Вак-вак атлап биегән кызлар ялгыш
Йөрәгеңә басар кебекләр.
Җаен табып кына сылуларга
Каш сикертеп уза егетләр.

Көрәш кыза мәйдан уртасында,
Дулкынлана халык: кем җиңәр?
Көрәшчеләр әле бил бирмиләр,
Чыдасыннар гына сөлгеләр!

Гасырларның йөген күтәргәндә
Бөгелмәгәч, бер кат сыналгач,
Гер ташларын чөйгән чакта гына
Бу беләкләр, беләм, сыгылмас.

Бәйгеләрдә – җилдән җитез атлар,
Дагалардан очкын чәчелә.
Ат өстендә килгән үсмерләрнең
Ут кабыныр сыман чәченә.

Яланнарда сабантуйлар гөрли,
Бәхетлесе илнең бүген мин.
Хәтфә кебек яшел яланнарга
Ачып салган халкым күңелен...

# ӘМАНӘТ

Дәверләрдән дәверләргә күчә
Җырларның тик илгә кирәге.
Ил җырлаган җырны ир онытмый –
Гөл корытмый ирләр йөрәге.
Барлык моңын, җылысын бирә аңа
Һәм, соңгы кат типкән урында,
Тапшыра ул ил җырлаган җырны
Үзеннән соң килгән буынга.
Әтиләрнең әманәте булып,
Бер изге җыр күчте миңа да.
Югалтмыйча шуны,
Улларыма
Бирер өчен яшим дөньяда.
Ничә тапкыр җиңгән үлемне ул,
Каралмыйча кайткан илемә:
Намуслары кебек ак һәйкәлләр –
Батырларның туган җирендә.
Яши ул җыр миндә сөю булып
Һәм гомерлек җылы наз булып;
Хаклык булып тибә йөрәгемдә,
Сөендерә җанны яз булып...
Шундый җырны мин югалтсам әгәр,
Мәхрүм итәр кояш нурыннан.
Гомерлеккә ләгънәт укыр әнкәм
Һәм баш тартыр газиз улыннан!
Әтиләрдән алгандагы килеш,
Сүрелмәгән ул җыр, – янымда.
Улларыма тапшырганчы аны
Җылытырмын кайнар канымда...

# ТӨНГЕ ОЧЫШ

Йолдызлар тарта, йолдызлар,
Күкләргә ашкан чагым;
Дөньялар каршына басып,
Талпына бүген җаным.
И Җирнең тиңсез-бәясез
Кадерле мизгелләре!
Кайларга сибелештегез?
Бу йолдыз диңгезләре
Кемнәрнең серен яшергән,
Кайларга дәшә тагын?
Агызып китәр шикелле
Мине бу төнге агым...
Галәм түренә нур булып
Таралган дәверләрне
Куып җитәрләр шикелле
Җанның бу давыллары.
Кагылыр сыман кулларым
Кемнеңдер толымына, –
Ышанмам аның кайчандыр
Җир кызы булуына.
Танырмын әллә кайлардан
Җиремнең тәүге җырын;
Алдына башны куярмын
Ул җырны җырлаучының.
...Төнге дөньялар каршына
Нур булып агам сыман...
Югалсам, эзләрсез мине
Йолдызлар арасыннан.

* * *

Агач башлары шаулыйдыр –
Җилдәнме, яңгырданмы;
Әллә елларга сөйлисе
Моңнары авырданмы?

Җилләргә сибелә җырлар,
Яфраклар тузып кала;
Көз түгел, урман өсләтеп
Гомерләр узып бара.

Сыгыла агач башлары,
Безнең бәгырьгә тиеп,
Шуларны тыңлыйсыз бугай
Агачлар шаулый, диеп.

Киткән-озаткан чакларда
Түзәлер кемнең җаны?
И сабыр икән урманнар! –
Шаулыйлар гына бары.

## БЕЗ — КОЯШТАН

Без – Кояштан, Кояш яктысыннан,
Кояш нуры сеңгән каннарга, –
Шуңа кайнардыр без, кызурактыр...
Яктылыктан тора җаннар да.

Җирдә әле – без ясаган язлар,
Безнең назлар юлдаш сөюгә.
Сүнеп барган өмет кабынып китә,
Кулларыбыз килеп тиюгә.

Гел аклыкта, гел пакьлектә ният,
Күңелдәге нурдан яралып,
Безнең хыял җәйге болыннарга
Чәчәк саен төшкән таралып.

Һәр бәхеттә безнең аклык нуры,
Һәр учакта безнең җылыбыз.
Каралыкка киртә булып баса
Януыбыз, тоткан юлыбыз.

Җаныгызга җылы кирәк булса,
Эзләмәгез башка урыннан, –
Хәят уты безнең йөрәкләрдә...
Без – Кояштан, Кояш нурыннан!..

## ТИК БЕЗ ГЕНӘ

Бәйгеләрдә чапкан аргамактай,
Ялларында давыл уйнатып,
Яшәү дигән зур бер дулкын бара,
Вакыт океаны буйлатып.

Безнең турга килеп җитте менә –
Мәңгелекнең кайнар турына;
Тын алырга кыймый басып торам,
Заманыма карап, чорыма.

Киләчәкләр әле уянмаган,
Үткәннәрдә инде тып-тыныч;
Вакыт океаны уртасында
Тик без генә, хәтта куркыныч!

Бөтенләе белән безгә калган
Җирләр-күкләр, таулар-диңгезләр...
– Нишләтерсез икән? – дигән төсле,
Күзгә карап тора йолдызлар.

Бәрә дулкын безнең йөрәкләргә, –
Яшәү дигән шаулы чорда без;
Мәңгелектән аваз килә сыман,
Бер ышаныч булып:
– Чыдагы-ы-ыз!..

# УЧАК

Күкләргә сузылып карый –
Буе җитми учакның;
Кемнәре бардыр биектә,
Ник талпына бу чаклы?

Нинди омтылыш аңарда,
Каян килгән кайнарлык?
Берәр хәсрәте бар микән
Дулый-дулый янарлык?

Ерак күкләргә кадәрле
Ашканмы очкыннары?
Нинди аваз ишетелә,
Кемнәрнең кычкырганы?

Никләр шулай ялкынлана,
Ниләр яна учакта?
Нигә тыныч түгел җаным,
Ник ямансу бу чакта?

Яктылык булып учактан
Карый берәү – кем икән?
...Кайсыбыз яна далада –
Учак микән, мин микән?..

## СОҢГЫ АТ

Ничек кенә сөйлим бу төшне:
Дөнья буйлап соңгы ат бара,
Ап-ак ялы җирләргә тигән,
Бәкәлләре генә кап-кара.

Соңгы көне икән бу аның,
Тоякларын соңгы чык юган...
Соңгы кешнәү ярды тынлыкны,
Дәверләргә куйган чик сыман.

Ул кешнәүнең аргы ягында –
Күз күреме җитмәс киң дала,
Моңсу тынлык буйлап җил йөри...
Ярылырсың, йөрәк, тыңлама!

Ә кылганнар, нидер тойгандай,
Чал башларын җиргә игәннәр, –
Тоякларның тупырдашканы
Ишетелә бугай тирәннән.

Тукта, Вакыт! Соңгы кешнәүнең
Кире кайтар теге ягына –
Тулпарларның, болын тутырып,
Уйнаклашып чапкан чагына.

Атлардагы кыңгырауларның
Тавышлары кайтсын чыңгылдап!
...Каян килеп кердең бу төнгә,
Төш кенәме соң син, соңгы ат?..

# IV. Тәкъдир каләме

...Бер елыйдыр тәкъдир каләмнәре
Тәкъдирләрне язар алдыннан...



## КӘГАЗЬ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

И ак кәгазь! –
Җырланмаган җырым,
Көйләнмәгән көем син минем. –
Ничек башларга да белми торам,
Изаланып беттем инде мин.

Килер көннәндерме, үткәннәнме,
Сөюме син, әллә нәфрәтме?
Гомерләргә иңәр бәхеттерме,
Үкенечле берәр хәсрәтме?

Кагылырга куркып торам әле
Синдәге бу моңлы көемә, –
Кинәт дөрләп яна башларсың күк
Каләм очым килеп тиюгә...

* * *

Тузга язмаганны сөйләмәскә
Өйрәткәннәр иде олылар.
Шул киңәшне искә төшерәм мин,
Каләм тоткан саен кулыма.
Еллар күмеп киткән нигезләрдән
Хатлар чыга – тузга язылган.
Каен тузы...
Син дә минем кебек
Уйга чумдың бугай, карурман!
Миңа чорлар карап тора сыман
Күмерләнеп беткән тузлардан, –
Кемнәр бәхете шулай янды икән,
Кем йөрәге шулай сызланган?!
Ил өстенә килгән афәтләрне
Белгерткәндер, ахры, бу хәбәр;
Ирләр белән бергә янганнардыр, –
Көймәс иде тузлар бу кадәр!
И каеннар, ап-ак чордашларым,
Алдыгызга килеп тезләнәм:
Гасырларның мәрхәмәтсез җиле
Тиеп узган икән сезгә дә.
Тигәннәрдер булат хәнҗәрләр дә,
Кадалгандыр үткер уклар да...
Тынгы күрми икән каеннар да
Нәфрәт барда җирдә, ут барда.
Бу халкымның йөрәк яраларын
Язып барган булсаң тузларга,
Бер каен да исән калмас иде
Сагынганда карап узарга.
...Әллә син дә шуны уйладыңмы,
Тирән уйга чумып, карурман? –
Һәрбер агач шуны сөйли кебек,
Шушы хакта тузга язылган...

* * *

Җанда шигырь бөреләнгән саен,
Мин бер сәер тойгы кичерәм:
Килер чорга ишек шакыймдыр күк...
Әллә иртә, әллә кичегәм.
Барып керү әрсезлектер сыман
Үзең өчен ят бер дәвергә.
Әйтер сүзе барда, мондый адым,
Юк, әрсезлек булмас шагыйрьгә.
Әдәпсезлек булмас,
Мәкерләрне
Бүлеп әгәр кара юлыннан,
Оныкларга дигән пычакларын
Төшерәлсәң бәреп кулыннан.
Мәңгелеккә барыр Мәхәббәтне
Сагалаган чакта Хыянәт,
Үткәннәрдә генә торып калсаң,
Кичералмас сине бу хәят!
Җанга – җылы, дөреслеккә – калкан
Кирәк булыр килер чорда да,
Бәхет дигән олы җыры җирнең
Шул тавышка гына җырлана.
Җанда шигырь...
Ишекләрен шакыйм –
Бездән ерак чорлар ишетсен:
Изге ният алдан барып керсен,
Яманлыкка юлдаш – кичексен!

# ХАТЛАР ЮЛЫ

Хатлар – юлда,
Мәңге юлда хатлар...
Белмим кая барып җитәрен –
Саргаешып карап тора безгә
Еллар аша дәфтәр битләре.

Ничә кабат инде укылганнар,
Күпме җанга килеп тигәннәр,
Тик һаман да исән, һаман сөйли, –
Хат өстенә үсми чирәмнәр...

Ташка язган, каен тузларына,
Пергаментка язган кешелек,
Берсен дә ул уйлап чыгармаган –
Йөрәгеннән куйган күчереп.

Китерәләр хатлар Тукайларны,
Җәлилләрне, Кутуй, Такташны –
Белә алар безнең югалтмасны,
Бер югалтсак – кабат тапмасны!

Саргайса да килә, таушалса да,
Ут эченнән солдат хатлары:
Беркайчан да таушалмады сөю,
Ир намусы җиргә ятмады.

...Киләчәккә хатлар китеп бара,
Хатлар юлы – чорлар аркылы;
Заман өсләренә хат язалган
Ир-егетләр карый калкынып...

# ТӘКЪДИР КАЛӘМЕ

Тәкъдир каләмнәре үзем булсам,
Болай язмас идем тәкъдирне...

*Халык җыры*

Яхшысын да яза, яманын да, –
Кем төшергән мондый хәлләргә?
Ниләр өчен генә биргәннәрдер
Бу җәзаны мескен каләмгә? –

Көлә Кеше... Бер минуттан – үлем...
Шуны яз син, көндер кулларны;
И беркатлы адәм балалары! –
Утта-суда тилмерт шуларны.

Яхшысын да, яманын да яза, –
Мондый эшкә ничек алынган?!
...Бер елыйдыр тәкъдир каләмнәре
Тәкъдирләрне язар алдыннан...

* * *

«Кыйгак-кыйгак, кыйгак-кыйгак!» –
Казлар кайта, казлар китә, –
Болытларга канат манчып,
Казлар нидер яза күккә.

Алып кайта, алып китә, –
Нидер ташый газиз җаннар;
Канатлардан кан тамамы –
Болытлар ник кызарганнар?

...Ни кагылды җанга дисәм –
Каңгылдашып казлар үткән;
Баш очымда – серле язу,
Кемнәр укып бирер икән?!

* * *

Уйларымны сыйдыралмыйм сүзгә,
Әйтелмәгән нидер кала сыман.
Нилектәндер әле мин һаман да –
Теле ачылмаган бала сыман.

Төшенәбез ләкин балаларның
Ни әйтергә безгә теләгәнен.
Сабый теле сыман аңлаешлы
Булса иде сезгә сөйләгәнем!..

# ТЕРЕК СУЫ

Яхшы сүз – җан азыгы.
*Мәкаль*

Сибәр өчен үлем ярасына
Эзләп тапкан кеше терек суын.
Яктыргандыр күпме әкиятләр,
Савыккандыр аннан ничә буын!

Без соңгарак калып туганбыз шул,
Әкиятләрдә яшәү язмаган ла!
Тик яманлык барда, терек суы
Кирәк икән, кирәк һәр заманга...

Яман сүзләр авыр яра салса,
Телгәләсә әгәр сезне бүген,
Җаныгызны савыктырыр өчен
Каян алыйм икән терек суын?!

Кешегә бит бер җылы сүз җитә...
Шул булгандыр, бәлки, терек суы;
Бер-беребезгә дәвадыр без юкса –
Аңлап кына җиткермибез шуны.

Яхшы сүзем!
Терек суы булып
Сибел әле бүген чорыма син!
...Һәрбер күңел шундук савыгачак –
Терек сүзе бездә корымасын...

# ШИГЫРЬНЕҢ ӨЧ ХАЛӘТЕ

## 1. Кар өстендәге шигырь

Көннең яңа битен ачып,
Кулларыма каләм алсам,
Кошлар инде миңа кадәр
Язып куйган әллә кайчан:
Яңа яуган кар өстендә
Тәпи эзе, канат эзе –
Язмышларын язган кошлар...
Укып була кирәк сүзне.
Үзебез дә кошлар бит без –
Иңнәрдә юк канат кына;
Үзгәрми лә икән язмыш,
Канатсызга карап кына!
Карлар ява, исә җилләр,
Җәйләр уза, кышлар чыгам –
Без барабыз,
Дөнья буйлап
Җәяү киткән кошлар сыман...
Бу шигырьне иртән-иртүк,
Декабрьнең суыгында
Кар өстенә кошлар язган...
Укып бирдем шуны гына!

## 2. Тәмамланмаган шигырь

Әйтелми сулган сөюдер,
Канаты сынган көйдер,
Өзелеп калган гомердер –
Тәмамланмаган шигырь...

## 3. Соңгы шигырь

*(Мең дә беренче тәүбә)*

Иләс-миләс җырлар аркасында
Ишеткәннәр әллә аз булды? –

Инде җитәр!
Иртәгәдән ташлыйм,
Бөтенләйгә, шигырь язуны.
Бу – соңгысы.
Моннан ары бер дә
Газапламам кәгазь-каләмне;
Мин соң әллә, җыру чыгармасам,
Тамак туйдыралмас адәмме?!
Такмак өчен тапмагандыр әнкәй,
Юньле бала булыр дигәндер:
Мин әле дә аның хыялында
Сабан сөреп, иген игәмдер.
Булды, җитте!
Инде шигырь диеп,
Төне буе бүтән җенләнсен;
Рифма-фәлән килсә телләремә,
Авызымнан минем җил алсын!
Язылмый кал лутчы,
Ил телендә
Яманат алганчы: «Буш шигырь...»
Яхшы чакта аерыла белик
Бер-беребездән – ярый, хуш, шигырь!

# ҖИЛӘК ҖЫЮ

Урман эчендәге авыл...
Ындыр арты – җиләклек...
Тагын еллар артындагы
Җиләклеккә эләктек.
Алларыма аллы-гөлле
Ашъяулык япкан кебек,
Тезләнәм,
Шул ашъяулыкта
Кыйбламны тапкан кебек.
Тезләнәм, башны орамын...
Өзалмыйм җиләк кенә,
Җиләк-җиләк уйларымны
Бирсәм тик сөйләп кенә...
Җыямын еллар буена
Җырларым – җиләкләрем.
Ник, авыл, җиләк җыюның
Серләрен өйрәтмәдең? –
Җыям өлгергәннәрен дә,
Өзәм бөреләрен дә,
Күзгә күренгәннәрен дә,
Күренмәгәннәрен дә.
Шуңа күрә җиләкләрем
Булмас гел татлы гына;
Савытым да тулар-тулмас –
Җыялган чаклы гына.
Алларымда җыелып бетмәс
Җиләклек яткан кебек, –
Баш орам,
Шул җиләклектә
Кыйбламны тапкан кебек...

## ЯШЕН ВАКЫТЫНДА ЯЗЫЛГАН ШИГЫРЬ

Сискәндереп гамьсез көнне кинәт
Телеп узды яшен,
Калтыранды тәрәзәләр... Намус,
Синме әллә дәштең?
Синмени соң, Хаклык, ахыр чиктә
Түзалмадыңмыни? –
Азды шул бу мәкер: кешеләрнең
Башларыннан йөри.
Кылычыңны син дә кынысыннан
Чыгардыңмы, әй, Үч,
Тәрәзәләр түгел, җан сатканнар
Калтырарга тиеш!
Син кайттыңмы, үлем белән гүргә
Томаланган Чынлык –
Бу дөньяны бераз дөресләргә
Булдыңмыни чыгып?
Ялгыштыммы, буталдымы юлым,
Дөрес яшәмимме? –
Нәселем рухы! Әллә шулай миңа
Син соң дәшәсеңме?
Сискәндереп гамьсез көнне кинәт
Кемдер телеп узды,
Гөнаһ юктыр корыган карамада –
Анысын белеп узды.
Ялваруларыңны кабул итмәс,
Теләк теләвеңне,
Яшен булмастыр ул – сукса беркөн
Әгәр йөрәгеңне.
Дөньяларны айкап кемдер йөри,
Түгелдер ул яшен.
Ни югалган икән, нәрсә җитми? –
Белмисеңме, Кешем?!

## ЯЗМЫЙМ ИНДЕ...

Каян алып,ниләр язам,
Ничек язам? – Беркем белми.
Язмыйм инде... Тыңлыйм бары
Дөнья шавын, көн-төн дими.

Тыңлыймын да әкрен генә
Кушыламын шул авазга.
Җәйләр кичә тоташ бер өн,
Кышка керә, чыга язга.

Ифрат җиңел кайчак миңа:
Сүзләр әзер, көй сибелгән –
Җырлыйм бит мин җиремдәге
Һәрбер яфрак исеменнән.

Өмет өзгән чаклар була
Җиткерәсен җиткерүдән,
Дәшәлмисең – болыннарда
Риза түгел тик бер үлән...

Рөхсәт ителмәгән миңа
Арттырулар, киметүләр.
Сүзләремдә һәр бөҗәкнең
Ышанычы-өмете бар.

Каян алып, ниләр языйм? –
Язмыйм инде... Тыңлыйм бары.
Тыңлыймын да, үз телемә
Күчерәмен мин дөньяны.

* * *

Болыннарда күбәләкләр –
Тере шигырь дәфтәрләре,
Шагыйрьләре күптән юктыр...
Шуларныңмы дәшкәннәре
Ишетелә җәйге җилдә? –
Тын алмыйча тыңлап кара!
Дәфтәрләре тик бер көнгә
Терелгәндер – кыска ара...
Очып китә лепер-лепер –
Үкенечтер соңга калсаң;
Бәхетле син – гөлләрдәге
Күбәләкне укый алсаң...

## ШӘМ ЯКТЫСЫ

Кайчак миңа якты җитми башлый,
Дөньясында җылы азая.
Өстәлемә шәм яндырып куям –
Шәмнәр белән кичем озая.

Җиңеләеп калган кебек булам,
Борчуларым гүя йота шәм.
Әйтерсең лә шәм яктысы аша
Ерак чорлар белән тоташам.

Шәм ялкыны аша әйтерсең лә
Үткәннәрнең нуры сирпелә;
Кемнәрнеңдер сагыш күләгәсе
Шәм төбенә килеп төртелә...

Төннәр буе җылы сүзләр эзлим –
Үткәннәрне мин дә юатам.
Шәмнәр белән бергә янган чакта,
Нидер табам, нидер югалтам.

Өстәлемдә сабыр-салмак кына
Шәмнәр яна,
Яна Мәңгелек.
Мәңгелектән кайтып яктырталар
Калалганнар җирдә шәм булып...

## ГЫЙБАДӘТ

Әле шөкер! –
Иманымнан тәкъдир
Бөтенләй үк мәхрүм итмәгән:
Җаным таланганда, ялгыз калып,
Гыйбадәткә кереп бикләнәм...

Дога белмим, дөрес. Оныттырып
Өлгергәннәр инде догамны...
Булдыралса, ярлыкасын Ходай
Бу юлы да йола бозганны:

Күңелемә нинди сүзләр килә –
Шуны укыйм, шуңа инанам.
Язып юанамын мин аларны,
Аларны мин сызып кыйналам.

Арып-талып, тынычланып туктыйм.
Сез әйтерсез инде: бу шашкан!
Шашкандырмы-юкмы,
Әмма ләкин
Күкләр белән күңелем тоташкан...

Шигырь укып йөрер заманмыни! –
Акыл керер чактыр миңа да:
Ни гомерләр яшәп,
Бишегемнән
Чыгалмыйча калдым – дивана...

Сезне дә мин тирбәтмәкче булам:
Юанырсыз, димен, ничек сез?
Сиртмәсенә кагыласы итсәм –
Күбегезнең җаны бишексез...

Кем күтәреп алыр, кем юатыр? –
Җаннарыгыз һаман сабый ла!
Сарыла ул...
Тирбәтмиләр генә
Тирбәләсе килгән чагында.

Сиртмәсенә кагыласы итсәм,
Күпләрегез бүген бишексез.
Бәгыреғез катыланып беткән
Таш өстенә егылып төшеп сез.

Мин бит сезне һаман тирбәтмәкче,
Җырларыма салып – дивана.
Чыгалмыйча калдым бишекләрдән...
Тирбәтүче юк шул миңа да!

* * *

Су буенда казлар төзәтенә,
Уйнап туйганнар да инештә.
Ап-ак булып әзерләнә алар,
Әзерләнә туйлар килешкә.

Агымсуда таллар чәч юалар...
Усакларда – алсу намазлык:
Гамәл-гыйбадәткә талганнардыр,
Илгә-көнгә теләп тазалык.

Ындыр артларында йокымсырап,
Кибән-кибән җәйләр утыра.
Күчмә кошлар күккә шигырь яза,
Яза алар –
Укы-укыма!..

Ә мин каләмемне куеп торыйм:
Акын барда телең тый, диләр...
Сиңамы соң инде бу дөньяда
Ул көзләргә җиту, и юләр!..

Бәрәкәтле сулыш тараладыр
Дулкын-дулкын булып инештә.
Мәңге шулай әзерләнә җиһан
Яңа җаннар җиргә килешкә...

# БИШ ВАКЫТ НАМАЗ

*(Шигъри гыйбадәт)*

## Иртәнге намаз

Әгузебиллаһи... Ниятләдем намаз...
Намазлыгым минем – язылмаган кәгазь.
Юнәлде рухым изге кыйбла якка –
Газиз як иде ул... әнкәм исән чакта...
Кыйбла үзгәрмидер. Үзгәрә тик инсан:
Инде һәммә эшне кылып була, кылсаң.
Беләм, кычкырырлар: «Булмый намаз болай!..»
Юри кыланмыймын – ярлыкасын Ходай.
Нишлим «гыйлемлегем» шуңа гына җиткәч?
Бәлки, рәхмәтеннән әле мәхрүм итмәс...
Газиз әнкәм рухы! Рәнҗемәсәң иде...
Заман хастасыннан аралачы мине!
Намазлыгым – кәгазь, баш орасы акка.
Йа Раббем, безне яман чирдән сакла!
Бик тиз йога бит ул, төшә йөрәгеңә:
Бисмилланы хәзер әйтми кемнәр генә!
Хак Тәгалә исемен битлек итеп киеп,
Гөнаһ эшләр кыла адәм тау-тау өеп.
Кояш ярлыкасын, ярлыкасын Галәм...
Ә син ни кылырсың – нишләтерсең, Каләм?!
Асылына төшми, куя күрмә нокта:
Намазлыгың – кәгазь, башың – намазлыкта...
Кабул була күрсен – чын ихластан язам!
...Яңа якты көнгә кереп килә Казан...

## Өйлә намазы

Гомерләрнең өйлә туры җиткән...
Аерылып казна эшеннән,
Куеп торып дөнья мәшәкатен,
Кемлегемне искә төшерәм.

Теләк теләр изге сәгатьләрдә,
Фәрештәләр иңәр минутта
Үз-үземне искә төшерәмен...
Ходай барын белә торып та!
Бу юлларны укымый уз, туган,
Көфер сүздән әгәр курыксаң...
...Дәшмәвеңне күтә,
Яшәвеңне
Оныттыра дөнья, онытсаң.
Адәмнәр дә юктан бар булмыйдыр...
Шушындадыр нәсел-нәсәбем.
Ник соң болай, газиз нәселемнең
Кадерләрен белми яшәдем?!
Учагыннан читкә тәгәрәгән
Утлы күмер пыскып сүнәчәк.
Киләчәк бар...
Әмма сүнгәннәргә
Килмәячәк бит ул Киләчәк!
Җиде бабаң карап тора сиңа,
Җиденең дә җиде бабасы...
Күзләренә күренер дә идең, –
Югалгансың... Каян табасы?!
Гомерләрнең өйлә туры җиткән...
Синдә һаман сабый акылы –
Фәрештәләр канатында гына
Сикермәкче еллар аркылы.
Намазлыкка башың орасыңмы,
Елыйсыңмы җиргә капланып, –
Гамәл кирәк адәм баласына
Яшәгәнен җирдә акларлык.
Бер Ходаем гафу әйләр әле,
Гел ярлыкар диеп уйлама, –
Ходай бит ул сиңа үзең Кеше
Булсаң гына Ходай булала...
...Сәҗдәләргә китәм,
Үткәннәрнең

Аягына килеп егылам.
Үз-үземне мәңге табалмамын,
Кабул булмый калса бу догам...

## Икенде намазы

Якынрак булыйм диеп өммәтемә,
Язып-таеп керсәң намаз ниятенә,
Бүлдерәләр – алардан һич котылмак юк, –
Башкаеңа катлы-катлы уйлар килә.
Мәңгелекнең юл өстендә әле дә син бар –
Алмаштырып булмый торган гөнаһыкяр.
Сыялырмы Ходай җәйгән намазлыкка? –
Хәлләреңә инде синең дөньялар тар...
Гомереңне казаларга калдыргансың,
Ничек итеп кайтарыплар алырга соң?!
Сорап тормый-нитми генә чыгачаклар –
Тере мәетләр өчен дә бар ул Ясин...
Бүтән тагын кемнән сорыйм, и Раббем! –
Җир йөзенә гыйбрәт өчен ник яраттың:
Үлмәс борын мәхрүм иткәч йөрәгемнән,
Милләттәшләр каршысында ник ир-ат мин?!
Каләм шаһит: акка – кара, карага – ак,
Гомер буе шуны яза кабат-кабат,
Безнең өчен иман шулдыр: бу дөньяның
Карасына мана-мана җаның агарт...

## Ахшам намазы

Сиңа билгеле, Тәңрем, –
Дәһри буласы идем...
Югыйсә әткәм-әнкәмнең
Газиз баласы идем!
Ышандыкмыни ул чакта
Аларның догасына?
Юкка дисеңме шулхәтле

Зәхмәтләр йога сиңа?!
Елларны күпме елатып,
Мәңгелек каргыш алгач,
Җитәр микән – тәүлегенә
Биш кенә вакыт намаз?!
Бөтен миргә күрсәткәнне
Бер Ходайдан яшердек,
Рәнҗидер әнкәйләрдән
Алып калган бәхиллек.
Барын бар да ул кыйбла,
Намазлык ак та агын...
Сынкайларым белән катып,
Сыгылып төшәр чагым.
Синнән дә сорар улларың,
Каласы килер алып:
Изгелек бармы җаныңда
Бер хәер-фатихалык?!
Исләремә төшермәгез –
Дәһри буласы идем...
Кайчандыр әткәм-әнкәмнең
Газиз баласы идем.
Ут йотып эзләп килгәндер
Шуларның догалары...
Без ышанмаган идек тә, –
Дөрескә чыга бары.
Чорлары бүтән булса да,
Гамәле-йоласы бер:
Ахирәттә дә дөньяны
Афәттән йоласыдыр...

## Ястү намазы

Әле аны, әле моны язып,
Каләмне мин күпме изаладым!
Дүрт якта да түгел икән кыйбла...
Ходай ихтыярын бозалмадым.

Җиткәндер бу!
Юкса заманасы
Азганнарга болай азарлык та...
Килер көннең асыл яктылыгы –
Бабайлардан калган намазлыкта!
Шул яктыга җанны куям бүген,
Аның белән чыгам иртәгәмә.
«Намазлыгың – кәгазь генә бит», – дип,
И укучым, мине битәрләмә!
Ходай миңа шулай насыйп иткән...
Гамәлләрең синең ихлас булсын!
Көне буе шунда баш орасы... –
Укымыйча калыйм ничек монысын?!
Үзе белеп, күреп тора бит ул:
Безгә беркем намаз өйрәтмәде.
Шушы намазлыкка ятып елый
Гаҗиз бәндәләрнең йөрәкләре...
Еллар буе мин шуларны укыйм.
Догам шулдыр...
Изгелектә ният:
Бабайлардан калган яктылыктыр –
Күңелләрне шул яктыга иярт!
Иртәгә дә таңнар атасы бар...
Яктылыкка фида булсын җаным.
Изге теләк белән тәмам иттем
Намазымны!..
Йа Илаһиамин!..

# ЗАМАННАРНЫҢ ИҢ КИРӘКЛЕ СҮЗЕ

*Айрат Арслановка*

Юкка гына ук атыламыни? –
Тигәндер шул,
Илгә тигәндер...
Ил ярасы – ирләр йөрәгендә,
Аваз сала икән синнән бер:

Кычкырасың –
Йә ул шигырь була,
Йә күкләргә ашкан җыр була.
Гомерлек бер моңга әйләнергә
Яратыла икән ир бала.

Үзәк өзеп күтәрелә бит ул
Күкрәктән, йөрәк түреннән, –
Бәлки, күкләр газиз бәндәсенә
Эндәшәдер шулай, кем белгән?!

Савыгадыр аны тыңлаганнар,
Сабырлыклар җанга иңәдер.
...Заманнарның иң кирәкле сүзе
Ирләр йөрәгендә нигәдер...

Фәрештәләр канат җәеп тора:
– Күшеккәнсең бугай, кил, туган!
Шигъри сүздән җирдә ил җылынган,
Мөлдерәмә булып моң тулган.

Казанның нәкъ урта бер җирендә
Ел да шулай сихри җылыга,
Мәңгелек бу учак тирәсенә
Заманалар, чорлар җыела.

Монда бүген, монда бөтенесе –
Исәннәре, исән түгеле...
Тар җиргә дә сыя икән дөнья,
Киң булганда халык күңеле.

Казанның нәкъ урта бер җирендә,
Язмышларны язар айларда,
Сискәндереп килеп керәдер ул
Татар җаны әллә кайларга.

– Дөньяларың күшекмәсен берүк,
Соңга кала күрмә, бар, ашык! –
...Фәрештәләр канат җәеп тора,
Шигъри сүзне илгә таратып...

* * *

Дөньялыкны узып барган чакта,
Тик бер генә тапкыр кычкырдым –
Мин шунда ук инде беркая да
Куна алмый торган кош булдым.

Миннән башка җирдә бу Ходайның
Аз микәнни гаҗиз кошлары? –
Ни гомерләр инде бәндәләрнең
Яшен сөртә канат очлары!

Тик канатлар өлгерерлек түгел,
Мин дә сөртеп бетералмамын.
Оча икән кошлар
Кешеләрнең
Күктә йөртер өчен җаннарын.

Беркая да инде кундырмыйлар,
Тәңредән каһәр алдыммы? –
Дөньялыктан узып бара идем,
Мәңгелеккә шунда калдырды...

# ӨЧ КЕНӘ СҮЗ...

Бер ишеләр яратылган базар өчен,
Икенчеләр яратылган азар өчен,
Өченчеләр яратылган илдәгенең
Бөтенесен бәйнә-бәйнә язар өчен.

Базарларда йөргәнем бар, беләм ансын,
Төртеп куям, аз булса да телдә калсын:
Сине дә бит илең белән арзан хакка,
Сата заман, иренмәгән килеп алсын!

Азулары беркемгә дә ерак түгел.
Акыл-фәлән өйрәтмәгез, кирәк түгел! –
Күпме генә изге сүзләр сөйләсәң дә,
Нәфес – нәфес бит инде ул, йөрәк түгел...

Язар өчен яратылган – язар ла ул!
Һичберкайчан ярый алмас базарга ул.
Газраил килеп тотар бугазыннан, –
Өлгералмый калыр, фәкыйрь, азарга ул...

Гыйбрәт өчен алган идем өч кенә сүз,
Өч сүз аша язмышларны кычкырасыз,
И кешеләр!
Заманнардан олы килеш,
Кайчагында мизгелләрдән кечкенә сез...

# ЯЗМЫШ

Үткәннәрдән гыйбрәт алыр өчен,
Колак салыр өчен сүзенә,
Дөньядагы барлык дәверләрнең
Шагыйрьләрен җыйдым үземә.

Мине дә бер тыңласыннар, дидем,
Ишетсеннәр безнең заманны...
Белмәгәнмен икән:
Җирдә мәңге
Бер үк якты, бер үк караңгы!
Мәңге шулай үреләсе икән
Караңгыдан һаман яктыга,
Ике арада бәргәләнә икән
Кешеләргә дигән Ак Дога...

Дәверләрне, шагыйрьләрне күрдем,
Бәгырьләрне...
Түздем, дәшмәдем:
Без әрнегән җиткән, үткәннәрне
Әрнетмәсен ачы яшьләрем!

Дөньядагы барлык шагыйрьләргә
Бер үк якты, бер үк караңгы...
Чакырганнар иде, –
Китми калдым:
Үтәсе бар шушы араны...

## ГӨЛЧӘЧӘК

Моңсуланып кына карап тора
Юл буенда үскән гөлчәчәк.
– Кемнәр өчен алсуландың болай?
Күзләремә кара, көл, чәчәк!

Бик кыендыр бит ул яшәүләре,
Искән җилгә болай гел чәчәп,
Бер иркәләп йөрәгемә кысыйм,
Башкаеңны күтәр, кил, чәчәк!

Гөлләр булалмамын...
Ә җаннарым
Гөлдән артык минем, бел, чәчәк! –
Ул бит сине шулай алсу килеш
Мәңгелеккә кадәр илтәчәк...

...Җил дип белде бугай,
Ышанмады,
Ышанмады миңа гөлчәчәк,
Сизмәгәндер йөрәгемдә минем
Җырга әйләнүен ул чәчәк...

## ЯЗАЛМАГАН ЧАКТА ТУГАН ШИГЫРЬ

Бар бит ул шигырь дөньяда,
Бар бит ул, исән бит ул.
Исәрлегемне беләсез:
Миннән дә исәр бит ул!

Белә торып табынамын...
Кичерсен Ходай мине:
Сабый чакларымнан бирле
Кальбемдә – шигырь дине.

Дин генә булмады бугай,
Җен булды бугай ла ул:
Кубар идемени кинәт
Җанында болай давыл?!

Әйдә, кем генә булмасын:
Җен булсын, Иблис булсын –
Аның белән кылганым тик
Адәмгә изге эш булсын...

* * *

Кеше китә...
Бик кирәкле сүзе
Өзелеп кала кайчак иренендә...
Дәшәр өчен тел тибрәткән килеш
Җан бирүем бар ич минем дә.

Дошманыма әйтелмәгән нәфрәт
Билчән булып калкыр каберемдә.
Гөлләр үссә анда,
Дусларыма
Җырым калган булыр бәгыремдә...

* * *

Ишетми калма берсен дә:
Җырласын, еласыннар;
Илгә сайрарсың – мең елдан
Сандугач буласың бар...

## АККОШ КҮЛЕНДӘ

*Хәсән ага Туфан истәлегенә*

Аккош күле. Ак каеннар.
Беренче яз Туфансыз...
Күке елый: «Юк-юк, юк-юк!..»
Ничек яшәр ул ансыз?

Аккош күле. Ак чәчәкләр...
Аһ, гөлләр ятимлеге!
Күбәләк аларга соңгы
Сәламен әйтим диме?

Көннәрдә – аның яктысы,
Җилләрдә – аның назы;
Терелә Аккош күлендә
Гөлләрдәй җанның язы.

Аның өчен түгел икән
Бу дөньядан китүләр.
«Юк-юк, юк-юк... Ул китмәде!» –
Ышанмыйлар күкеләр.

# МОҢЛЫ БЕР КЫЛ

*Композитор Заһид*
*Хәбибуллин вафатына*

Дөньядан ул халык исән чакта
Китә алмый торган заттандыр,
Бүген аның скрипкасында
Тик яңа кыл гына арткандыр...

Моңлы бер кыл иде,
Бар күңелләр
Тоташкандыр, ахры, ул кылга!
Бик ямансу чакларыңда, йөрәк,
Шул моңнарга кушылып сулкылда.

Дөнья белән саубуллашкан чакта,
«Тәфтиләү»ләр булып талпынды,
Китәлмәде ләкин... –
Күңелләргә
Нечкә бер кыл булып тартылды...

## ИЛҺАМ ШАКИРОВ ҖЫРЛАГАНДА

Бик еракта калган бабайларым
Килеп гүя хәлем сораша –
Могҗизага хәйран калып торам,
Очраштык та менә җыр аша.

Әллә кайсы гасыр һаваларын
Тибрәндергән сихри аһәңнәр
Бүген менә безгә сарылалар...
Агыл, җырым, илдә бәһаң бар!

Исем китеп тыңлыйм халкымны мин:
Кайгысын да хәтта җыр иткән;
Вакламаган җанын, –
Гасырларны
Колачларлык олы, зур иткән!

Күтәрелдек дәвер күкләренә,
Тоташтык та менә җыр аша;
Киләчәккә китеп барыш безнең, –
Бабайларым хәлне сораса...

Аңарга да шул исемне таккан
Заманасы: «Халык дошманы...»
Нахак исем аша үрелеп карый
Бүген безгә Шамил Усманов.
Канлы күзен бәгырьләрдән алмый* –
Чәнчи кебек каләм безне дә:
Күрми икән ачы хакыйкатьне,
Исән калганнарга күз нигә?!
Үз күзләрен үзе чәнечсә дә,
Күрмәсеннәр диеп ялганны,
Күреп торадыр ул
Еллар буе
Дөреслектән качып калганны.
Күзләр хәрам безгә,
Усмановның
Күзендәге канлы каләмне
Тартып алып, язалмыйбыз икән
Ул каләмгә мәгълүм хәлләрне.
Халык дошманына тиеш исем
Халык улларына тагылган.
Юасы бар әле чорыбызны
Ахыргача алар канынннан.
«Халык дошманы»дай яманатны
Улларына халык кушмады.
Халык намусы ул –
Сынап карый
Безнең чорга Шамил Усманов...

* Ялган беркетмәгә кул куймас өчен, Шамил Усманов үз күзләрен үзе каләм белән чәнечкән.

## СИБГАТ ХӘКИМ ТӨШЕ

Туфан турындагы истәлектә
Әйтерсең бу – гади төш кенә.
Төш кенә дә...
Ләкин шундый төш бу –
Истән чыгар димә һич кенә.
Чынбарлыкка охшаш нинди төштер,
Сискәндергән, килеп кергән дә –
Хәсән Туфан белән Фатих Кәрим
Очрашканнар, имеш, төрмәдә.
Елый-елый кочаклашкан алар,
Бер ананың уллары сыман;
Каргап очырылган Сак-Сокларга
Бер могҗиза булганы сыман...
Әллә каян кермиләрдер төшләр...
Туфан авызыннан ишетеп,
Зирәк шагыйрь өндә булган хәлне
Язган икән бары төш итеп.
Тарих өчен теркәп куйган шулай,
Хәтәр чорда хәтәр заманны.
Язып калдырган ул төшләрендә
Күрергә дә ярамаганны.
Инде төшләр чынга әйләнер чак...
Кемнәр күрде, кемнәр күрмәде
Үзебезнең төрмәләрдән чыгып,
Илләренә кайткан ирләрне.
Туфаннарның баштан кичергәне –
Безгә хәзер авыр төш кебек.
Сөйли иде безгә Сибгат Хәким,
Шул төшләрне искә төшереп.

Китап әзерлибез.
Калын папка –
Истәлекләр Туфан турындагы.
Калка Туфан, хәтерләрдән калка,
Киртәләрне җимереп юлындагы.
Еллар аша,
Ут-давыллар аша
Калка Туфан...
Уралларны кичеп...
Төрмәләрне ватып калкып чыга –
Дертләп китә Вакыт әллә ничек.
Ык буеннан...
Ерак ком чүленнән...
Йөзләрендә – учак шәүләләре...
Калкып чыга Ил өстенә Туфан,
Болытларга җитә гәүдәләре.
Галәм түрендәге йолдызлардан,
Мәңгелектән инде карап тора...
Кешеләргә язмыш үлем биргән –
Китми Туфан аңа карап кына.
Кайта-кайта йөрәкләрне бәйләп
Йөри әле җылы, армас бер кул.
Калка Туфан,
Еллар буйлап калка –
Китапларга гына сыймастыр ул!..

## БӨЕКЛӘРНЕҢ ГОМЕРЛӘРЕ...

Кем булуга карамастан,
Аямыйдыр үлем, диләр...
Асыл затлар тереләргә,
Үләләргә бүленмиләр!

Үрелмәсен әле үлем,
Алып китәм диеп, тиккә:
Бөекләрнең йөрәкләре –
Буй җитмәстәй биеклектә.

Көчлеләрдән куәтлерәк,
Исәннәрдән исән алар –
Һәр кешенең йөрәгенә
Тоташ, нигә дисәң, алар.

Җирдән китеп барсалар да,
Үлем түгел үлемнәре:
Халык гомерендә була
Бөекләрнең гомерләре...

## БАРЫП ҖИТӘР КӨНЕ...

Кулларына каләм тоттырган да
Карап торган язмыш читтән генә:
Янәсе, ни язар икән ятим
Кыска гомеренең битләренә?
Бу дөньяда гаме булганнарга
Язар сүз бетәме исән чакта?
Ниләр язсын Тукай –
Баганага
Сөялгәндә еллар, чыгып чатка?!
Бирмеш көннәренең яраламый
гына киткәннәре аздыр аны,
Шигырь беләм бергә, хатлар язган –
Бар арада нужа яздырганы.
Дусларына хәл-әхвәлен язган,
Апасына – сәлам-сагынмалык:
Хәзер бөтен дөнья алып укый,
Юк, без генә аңа кагылмадык.
Колач җәеп, каршы чыгып тора
Шагыйренә инде ерак чорлар.
(Тарих өчен хатлар язып бүген,
Кайберәүләр Тукай булмакчылар!..)
Кыска гомеренең битләрендә
Хатлары бар кыска-кыска гына –
Килә тора язганнары һаман,
Карамыйча вакыт кысканына.
Ул хатларны ачып, үз чорына
Дастан итеп укый аңлаганы.
Алда һаман, Тукай хатларының
Барып җитәр көне алда әле...

# ТАКТАШКА ХАТ

Сез бу хатны минем укыганда,
Авыр еллар үткән булырлар,
Җирдә коммунизм булган булыр,
Безнең дәвер халкы онтылыр...

*Һади Такташ*

Такташ абый!
«Киләчәккә хатлар»
Килеп җитте... Күптән алганга...
Ләкин менә Сезнең ул хатларга
Каршы язылмаган һаман да.
Ничә тапкыр язмакчы да булдым,
Яза башлап, ничә тукталдым.
Нигә язалмадым? –
Акланырга
Сәбәбе дә болай юк аның...
Чорның билгесез бер кешесенә
Атап язган Сезнең хатларны,
Нәкъ үзенә төбәлгәндәй итеп,
Ничә буын укып ятлады!
Миңа да бит алар...
Җавап язсам,
Хакым бардыр кебек минем дә.
Сезнең белән килә киңәшәсе –
Уйлар тынгы бирми күңелгә.
Аксакаллар, мине кисәткәндәй,
Әллә кайчан юкса яздылар:
«Киләчәккә хатлар барып җитә,
Ә үткәнгә хатлар бармыйлар...»
Белә торып язам...
Мөмкин түгел:
Язмый кала алмый торган чак.
Юк, барырга тиеш! –
Бу бит үткәнгә дә
Бармый кала алмый торган хат...

Такташ абый!
Кичерегез мине,
Җаным шунсыз тынгы табалмас.
Күз алдыма гына китералмыйм:
Ни диярсез икән аны алгач?..

Икеләнү дә бар:
Мин иртәрәк
Язмыйм микән Сезгә бу хатны?
Алай дисәң, күпме гомер узган,
Сулар аккан инде ничаклы!
Авыр еллар, әйе, аз булмады –
Җаны белән халык күтәрде.
Бер гаепсез алып китте еллар,
Кире кайтармады күпләрне.
Туфаннарны суккан кара яшен
Тими калмас иде Сезгә дә...
Елларга шул кыен ышануы,
Узган саен төсе үзгәрә.
Сөйләделәр:
«Сиксәненче еллар –
Коммунизм!» – Безгә тыңларга
Күңелле дә иде...
Ерак икән,
Урау икән ләкин юл аңа...
Әле еллар чабаталы иде,
Киндер күлмәк, киндер ыштанлы;
Чиләк асып, кәлҗемәгә йөрде,
Тыңламады алар кушканны.
Чана тартты...
Чапкалап та кайчак
Ташлаучылар булды чанасын.
Нужа бар чагында илдә чана
Бетәмени? –
Тапты яңасын.
Итен-маен кысып йөдәттеләр,

Теңкәсенә тиеп беттеләр.
Түләмәсә – «контр» ясадылар –
«Кәнсәләр»гә чакырып сүктеләр.
Чабаталы гына булсалар да,
Түзде еллар, түзде барына:
Җан күтәрмәс кимсетүләренә,
Яшәү өчен налогларына...
...Авыр еллар, әйе, аз булмады
Җиңел түгел... түгел әле дә.
Берәү янып йөри,
Берәү көлеп
Карап тора илнең хәленә.
«Безнекеннән яхшы тормыш юк» дип
Алдадылар...
Күпме алдандык!
Тора-бара бик кыйбатка төште
Ил өстендә андый «алла»лык.
Кемнәргәдер «алла» кирәк әле,
Өйрәнмәгән алар «алла»сыз...
...Чәчәк аткан теләкләрегезне
Әле бездән таба алмассыз.
Безнең чорга түгел бугай әле –
Хатларыгыз һаман юлдадыр.
Киләчәккә ышанычны Сезнең
Шулай гына аңлап буладыр!..
...Хатларыгыз кабат-кабат укыйм,
Безгә дә ул, безгә түгел дә:
Сезнең хыял күргән матурлыклар
Аз шул әле бездә бүгенгә.
Күп илләрдән артка калдык никтер,
Проблема – кая карама.
Югыйсә бит ничә еллар инде
Сезнең белән безнең арада!..
Мохтар картның ике «мин»е булган.
Күпләрдә ул хәзер бер генә:
Кем яклыдыр,

Ансын шайтан белсен! –
Әмма ләкин керер күзеңә.
Кайгыручы бер син генә түгел,
Төн йокламый ул да кайгырыр;
Кайгырыр да, әмәлен дә табар:
Илгә бирмәс – илдән каерыр!
Капкаларын син какмакчы булсаң,
Үз капкаңны кагар – как белеп.
Аларны бит җилләр тидермичә,
Яман күздән саклый... партбилет!
Хлестаковлар нәрсә? –
Бездә кемнәр
Секретарьлык иткән, кара син!
...Бармас җирдән барыр Сезгә хатым –
Ничек итеп язмый каласың?!

Сезнең хыялдагы матурлыклар
Алдадыр ул, алда, күрәсең...
Тик ул чорлар Сезгә ничек итеп,
Кайсы телдә хәбәр җибәрсен?
Үз телендә уку хокукыннан
Бүгеннән үк мәхрүм ич алар!
Ни гаебе бардыр милләтләрнең –
Ирексезләп телен кисәләр...
Килер чорның яңа кешеләре
Хатыгызны таный алырмы?
...Үткәннәргә, бәлки, баралыр да,
Киләчәккә хатлар барырмы?!

Такташ абый!
Килер дәверләрне
Якты, матур итеп күргәнсез,
Хыяллар бай булган...
Бу җәһәттән
Бәхетлерәк бугай бездән Сез.
Заман бүтән инде,

Казан бүтән...
И үзгәрде хәзер кешеләр.
Бигрәк азды Сезнең хатлардагы
Теге, бюрократ ишеләр.
Җәмгыятьне кабат үзгәртергә
Илдә олы көрәш башладык –
Яшәп булмый икән,
Югарыдан
Берәү төчкергәнгә баш кагып.
Киләчәккә ышанычны ләкин
Авыр кире кайтару гына:
Авызы бер пешкән – икенче кат
Өреп каба салкын суны да.
Ничә еллар чүбек чәйнәгәнне
Карап торып, кеше ялыкты.
Өметләрне тергезүе кыен –
Бер алдама икән халыкны!
...Ышанасы иде киләчәккә...
Хәтердә тик үткән яңара:
Алга барган саен, үткәндәге
Затлылыкны каян табарга?
Сезнең чорның асыл кешеләре
Бетеп бара.
Китте Туфан да.
Заманыма карыйм:
Туфаннарны
Алмаштырыр затлар юк анда!
Күрер күзгә болай бар да бөек...
Җаннары вак, зәгыйфь җаннары.
Җан тикшереп торыр дәвермени? –
Дәрәҗә бир, булсын даннары...
Кем төшерде әле мондый хәлгә,
Нишләдек без, кая барабыз?
Сездән якын кеше табалмадым,
Якын булмаса да арабыз.
Киңәш сорап, Сезгә язам бүген,

Белә торып язам үткәнгә –
Бармас, диләр...
Кая барсын ди ул,
Дөньясына өмет беткәндә?

...Хатларыгыз килеп җитте безгә.
Кирәк бугай ләкин үзегез:
Чөнки хәзер шигырь – үтмәс товар,
Җаен, бәлки, табар идегез.
Бик исләре китми түрәләрнең,
Әле автор үзе йөреп тә;
Артык йөккә саный «сәүдәгәрләр»
Шигырь китапларын кибеттә.
Алар өчен җан азыгы – акча,
Табыш дисәң, күзне кан баса.
Гаҗәпләндермәсен,
Хатларыгыз
Киләчәккә әгәр бармаса...
...Менә шундый хәлләр, Такташ абый,
Ничек итеп язмый каласың?
Яздым да бит...
Белми торам әле
Хатны Сезгә ничек саласын.
Кисәтмәделәр дә түгел, кисәттеләр,
Әллә кайчан инде яздылар:
«Киләчәккә хатлар барып җитә,
Ә үткәнгә хатлар бармыйлар...»
Белә торып яздым...
Мөмкин түгел:
Язмый калып булмый торган чак.
Юк, барырга тиеш! –
Бу бит үткәнгә дә
Бармый кала алмый торган хат...

*1983*

# ҮЗ КҮГЕҢДӘ

*Зөлфәткә*

Очты дөнья читлегеннән...
*Габдулла Тукай*

Бик очасы да бит! –
Канатларың
Ничә кабат әмма киселгән!
Тик шулай да күкләр иркенлеген
Чыгаралмыйсыңдыр исеңнән.
Балаларың йоклап беткәч, төнлә
Ут яндырып ялгыз кухняңда,
Биекләргә күтәреләсеңдер
Шигырьләрдә генә булса да.
Казан чаклы Казан аңламаса,
Кәгазь-каләм аңлар җаныңны –
Соңгы йөрәк тибешеңә кадәр
Үз күгеңдә калачагыңны.
Ничә кабат инде, ничә кабат,
Гасыр саен кисә килгәннәр! –
Канатыңның халык язмышында
Икәнлеген күптән белгәннәр...
Иртәгесен тагын имгәтерләр
Милләтеңә кагылып, телеңә.
Илнең җәрәхәте шагыйрьләрнең
Йөрәккәйләренә теленә...
Инде таң да ата...
Уянырлар.
Читлегеңә кире керәсе –
Кемнәрнеңдер әле сине һаман
Шул хәлеңдә килә күрәсе...

## КИТАП ТОТЫП КУЛГА...

Киштәсендә изге китап торган,
Китап тотып халык ант иткән.
Иманына тап төшермәс өчен
Борыннардан кайчак кан киткән...

Кулларыма китап тотып әйтәм,
Ялган сүзне китап күтәрмәс.
Китап күргән җәберләүләр аша
Аннан башка берни үталмас.

Өеп-өеп яктык китапларны,
Йөз чөердек – кемнән җирәндек?
Ә үзебез тузга язмаганны
Китапларга яза өйрәндек.

Милләтчелек-фәлән эзләгәндә,
Зиһен үткен, күңел сак безнең! –
Әмма бүген татар китапларын
Саклап алып калыр чак безнең...

Кат-кат имля алмаштырсалар да,
Чормаларда чорлар кичсә дә –
Исән калган китап,
Ачы язмыш
Шагыйрьләрнең башын киссә дә!

Кулларыма китап тотып әйтәм:
Теләсәгез генә нишләгез –
Беркайчан да иман керәсе юк,
Буш булганда күңел киштәгез!

Хаталана бүген –
Китаплардан
Табыш кына көткән, мал көткән.
...Киштәсендә изге китап торган,
Китап тотып халык ант иткән...

# ГАРМУН

*Гармунчы Гали Җәмлихановка*

Куен кесәсеннән чыгарды ул
Шырпы кабы кадәр гармунны,
Уйнарына беркем ышанмады –
Шаяртуга борды.
Бар моңны
Үзенә җыйган серле тартма сыман,
Кинәт чыңлап шунда гармуны
Телгә килде,
Шыгырым тулы залны
Бер тында ул телсез калдырды.
Гармун түгелдер лә!
Күкрәгеннән
Суырып алган, ахры, йөрәген –
Бәргәләнеп шул талпына бугай,
Кагыла бугай җанына ирләрнең.
Тиңсез хәбәр булып агыла көй
Үткәннәрдән, ерак чорлардан;
Шулкадәрле моңга нәни гармун
Ничек түзгән, ничек чыдаган?!
Талпына ул,
Залың-ниең белән
Китәр сыман сине күтәреп...
Шул давылны син йөрәгең аша,
Җаның аша кара үткәреп!
Кайтыр сыман илгә,
Күкрәгенә
Карурманнар сыйган егетләр,
Күптән сүнгән учак кабынып сыман...
Туктасаңчы, гармун, чү, җитәр!
...Уйнарына беркем ышанмады,
– Шаяртадыр, – диде бар халык, –
Шырпы кабы чаклы шул гармуны
Бәгырьләрне салды актарып.

## ЮКСЫНУ

*(«Моабит дәфтәре»н укыганда)*

...Ләкин кая язуым? –
Үзем белән бергә үләләр.
*Муса Җәлил*

Еллар кичеп, кайтып җиткән илгә,
Сүрелмичә йөрәк тибеше:
Тетрәндерә җанны – шагыйрьнең бу
Безнең көнгә кереп килеше.
Кайта Муса...
Тик һаман да әле
Җырлар җитми дәфтәр битенә,
Җитми җырлар... Мин сискәнеп китәм, –
Җырларның да башы киселгән!..
Тик үлмәгән алар,
Күккә үрләп,
Кушылганнар август таңына;
Тәрәзәләр ачык торсын әле,
Таң җилләре искән чагында!
Дәфтәрләрне кат-кат кулга алам,
Буш урын бар җанда – җыр җитми;
Бүген алар, илгә кайталмыйча,
Юксындырган ирләр кебектер.
Дәфтәр ачык, тәрәзәләр ачык,
Алсу шәүлә офык читендә, –
Язылалмый калган җырлар кайтып,
Таралыр күк дәфтәр битенә...

## ТУРЫ СҮЗГӘ

Туры әйткән – туганына ярамаган.
*Мәкаль*

Ярамаса ярамаган инде –
Барыбер әйткән, әйткән сине халык,
Күпме башлар ярамаган чорга...
Булмаган тик синнән качып калып.
Йөрәкләрне чукыр кара кошны
Куып җиткәнсең син, җитез уктай.
Хаксызлыктан зарыкканда еллар,
Калыккансың, булып туры Тукай.
Инде менә безгә килеп җиттең.
Беләм, күпләр шүрләп йөри синнән.
Шома гына үтеп китә белә
Үткен мәҗелесләр тирәсеннән.
Барысына да ярый белә алар –
Туганга да, туган түгелгә дә.
Иплэп-җайлап кына сөйләшәләр,
Китермиләр сине күңелгә дә.
Син бар, исән әле, үлмәгәнсең,
Әмма кая ташлар ярып көчең?
Йөрәгеңдә бикләп тота сине
Заманына күпләр ярар өчен.
Дөресен әйтим, әле мин үзем дә
Үзем теләгәнчә булалмадым.
Җитәр, чык дөньяга, инде вакыт –
Бизсә бизәр миннән туганнарым.
Нинди хәйлә эзләсәң дә, синнән
Булмый торгандыр ул качып калып.
Куркаклыкны гафу итә алмас,
Чыраеңа бәреп әйтер халык!..

* * *

Бер иңдәге ике фәрештә күк –
Бер тартмада Коръән, револьвер*.
Бер үк җанны икәү сагалаган...
Мәрхәмәт бир берүк, иман бир!
Револьверга кагылмаган шагыйрь...
Тик әле дә тора яңгырап:
Дошманнарга төбәп аткан сүзе
Кургаштан да булган саллырак.
Өметләре өзелеп калган чакта,
Ничә тапкыр кискен уй керде;
Тартма почмагында ятты шәүлә,
Бөгәрләнгән елан шикелле.
Кара еллар буган сулышыңны
Коръән генә ничек сакласын –
Ходаң үзе килеп тартса синең
Язмышыңның кара чакмасын?!
Бер үк җанны икәү сагалаган:
Йә сынасы, йә син чыдасы;
Кара нокта куясыдыр берсе,
Икенчесе ясин чыгасы.
...Очкан чакта дөнья читлегеннән
Искәрмәгән шагыйрь берсен дә.
Коръән белән бергә револьверы...
Калган алар читлек эчендә!

* Өстәл тартмасында – Тукайдан калган әйберләр арасында Коръән белән револьвер да булган. Бу факт Г.Тукайның 1914 елда чыккан китабына Җ.Вәлиди язган кереш сүздә, шулай ук К.Мостакаев истәлегендә телгә алына.

## ШАГЫЙРЬ ДУСКА

*М.Ә.*

Төнме яна шулай, йөрәгеңме,
Тәтен эчләрендә уралып? –
Идел төпләреннән моңнар алып,
Язасыңмы берәр догалык?

Идел төпләреннән моңнар алып,
Әйләндереп нәни очкынга,
Иртәгесе көннең бәгыренә
Төртәсеңме каләм очында?

Киләчәккә уйган тәрәзәдәй,
Ак кәгазьләр ята өстәлдә.
Ут эченә барып төшәрсең күк,
Тәрәзәдән сикереп төшсәң дә!..

Оныкларың табынасы сүзне
Коткаралырыңа инанып,
Гөнаһлы бер яңа пәйгамбәрдәй,
Язасыңдыр сыман догалык...

## ҖЫР ТАМЫРЫ

Көйдермәде нинди генә утлар,
Инде күпме кылыч чабылмады –
Аның саен тирәнгәрәк китеп
Тармакланды Җырның тамырлары.

Чишмәләрдән алып сулар сиптек,
Саклап калдык давыл купкан чакта –
Алсу гөлләр белән аралашып,
Җырлар үсә һаман безнең якта.

Әллә кая бара алмас иде
Күңелләре Җырдан өзелгәннәр –
Мәңгелеккә, башны горур тотып,
Җирдән җырлап китте без белгәннәр.

Җырлар үсә һаман безнең якта,
Әле дә җырлый халык, өзә генә –
Тамырлары барып тоташкандыр
Кешелекнең бәгырь үзәгенә...

## ОЗЫН ТӨННӘР УРТАСЫНДА...

Утлар сүнә кемнәрдәдер...
Кемнәрдәдер ут кабына:
Озын төннәр уртасында
Янмыйлардыр юкка гына.

Озын төннәр уртасында
Төннәрдән дә уйлар озын,
Сагышларың ягасыңмы,
Ут кабызып, берьялгызың?

Озын төннәр уртасында
Бәхетлеме, бәхетсезме –
Төшләреңә керәчәк ул,
Уятачак дәшеп сине...

Яктыралар... Билгесездер
Нинди утлар дөрләткәне:
Озын төннәр уртасында –
Кемнәрнеңдер йөрәкләре...

# МОКАМАЙ

...Ике ыштансыз малай дөнья белән
Танышып йөргән идек бергәләп...

*Һади Такташ*

Аерылмыйбыз гомер буйларына,
Калмый бездән, калмый...
Ник алай? –
Бергә уйнап үскән малайларның
Иң якыны кебек Мокамай!
Чабаталар бергә үрмәсәк тә,
Мәктәпләргә бергә йөрелгән.
Шигырь җене безгә аннан гына
Кагылгандыр, бәлки, кем белгән...
Бергә мендек каен башларына...
Кемнәр инде нишләп бетмәде!
Ә Мокамай исән.
Шагыйрь аны
Югалырлык кына итмәде.
Һәр малайга якын иптәш булды,
Ул басмаган җирләр юк бугай;
Дөнья белән таныштырып йөри
Әле безне һаман Мокамай.
Чәчрәп чыгып, яклашырга әзер,
Кыерсытса берәү телебезне.
Әллә ничек, үлем тырнагыннан
Йолып калыр сыман ул безне...
Бергә уйнап үскән малайларның
Иң якыны кебек...
Ник алай? –
Еракгагы каен башларыннан
Кулын болгый безгә Мокамай...

# КАЙТУ

Фатих Кәрим...
Ул һаман да әле
Ачылмыйча калган сер кебек.
Батып барган үлем баржасыннан
Бозлы суга төшә сикереп.

Йөзеп чыга.
Ярга сала башын:
Кар булса да, үлем түгел ич!
Баш очында – күгең,
Кара болыт
Басканда да – илең күге ич...

Адаштырган песи баласыдай,
Айлар буе кайта –
Кан... Яра...
Автомобиль покрышкасыннан
Галош ясап, җәяү кар яра.

Илдә кара буран...
Бик еракта
Нәни генә бер ут җемелди –
Өмет уты!.. Шуңа карап бара,
Ул сүнмәсә җанда, ир үлми...

Кайтып егылуга кабат төрмә...
Башларыннан ниләр үтмәгән!
Казанына карап кар ярадыр,
Ул әле дә кайтып җитмәгән...

# ИМАН ЯҢАРТУ

*(Шигырь бәйрәмендә)*

Тукай чорында да, аннан соң да
Буш булмады Тукай тирәсе...
Безгә дә бит ел да менә шулай
Иман яңартырга киләсе.

Дөньясында җылы калмаганда,
Бар өметләр бетте дигәндә,
Күбәләктәй терелер күк җаның,
Терелер күк... Шигырь белән дә!

Белеп җыелабыз: тик бер көнгә
Тукайларның монда күчәсен.
Иман яңарыр да, әгәр булса...
Имансызлар менә нишләсен?!

Башкайларын ташка орсыннармы? –
Казаннарда, куркам, таш җитмәс...
Бу мәхшәрдә изге кыйблаларың
Кайтаралсаң гына – баш бетмәс!

Булган иман – яңарасы бүген,
Бозылмаса Ходай кушканы:
Җыелабыз ел да,
Тукайларның
Кайткан чакта күңел кошлары...

## ШИГЪРИЯТ КИТАБЫ

*Татар поэзиясе антологиясе*
*басылып чыгу уңае белән*

Бисмилласын борынгылар әйткән...
Бу китапның әле Амины юк.
Ташка язган... Каен тузларына...
Исән калган тузы, каены – юк.

Үтеп чыгалмаган каеннары,
Чыгалмаган... Вакыт – янгын бит ул.
Кайгысын ил халык йөрәгенә
Юкка гына болай язмый бит ул.

Юкка гына егылгандырмыни
Кол Галиләр җирдә, Акмуллалар?
Беркайчан да алдамады халык:
Тузга язган сүзләр хак булалар.

Бисмилласын борынгылар әйткән.
Аминына әле шундый ерак...
Аңа хәтле бардыр янасылар –
Заманалар безнең шундыерак.

Ул көннәргә чаклы сыгыласы,
Егыласы бардыр каеннарның...
Әле дә шөкер, Ходай, – язмышларны
Шушы китабыннан аермадың!

Юкка гына болай язмас халык.
Ябылмаган китап, ачык кала.
Кулларыңда. Тик абына күрмә,
Күзләреңне, заман, ачып кара!

## КОЛ ГАЛИГӘ

Үткәннәрдән киләчәккә чаклы
Халкы белән болай кем барган? –
И Кол Гали, бөек замандашым,
Казаннарга күчтең Болгардан.

Күпме башлар юлда югалмады –
Милләтеңнең асыл ирләре?!
Заманнарга күчтең...
Авыл саен
Көтеп алды татар өйләре.

Боекларның илдә яшен сөрттең,
Телгәләнгән җанны сыйпадың.
Күктән иңгән дога урынына
Ятладылар «Йосыф китабы»н.

Китап белән бергә йөри икән
Гореф-гадәт, акыл, тел-сөйләм...
Илгә күчте Йосыф-Зөләйхалар –
Синең кебек болай кем сөйгән?!

И Кол Гали, бөек замандашым,
Салсалар да безне коега,
Калдырмассың кое төпләрендә –
Коткарырсың кебек тоела.

Өйдән өйгә йөреп хәл beләсең –
Халкы белән болай кем барган?
Афәтләрне күтәрешер өчен
Калыккансың икән чорлардан...

# ТАҢ ҖИЛЕ

*Фоат Садриевка*

Әнкәй кулы сыман сыйпап үтә
Мөслимнәрдән искән Таң җиле,
Өзгәләнәдер ул
Замананың
Сызлый икән, диеп, кай җире?

Агач саен, тирәк саен түгел, –
Йөрәк саен кагыласыдыр:
Сыйдыр, җилкәй,
Илдә искән чакта
Син үзеңә барын да сыйдыр!

Офыклардан офыкларга җиткер,
Бәндәләрнең моңын ал да син, –
Җирдәге бу җаннар сабырлыгы
Алсу таңнар булып аллансын...

...Таңнар саен юкка өзгәләнмәс,
Дөньяларның иңләп бар җирен:
Каерылып Мөслим якларына,
Юатасы килә Таң җилен...

# КӨЙ ЭЗЛӘҮ

*(Поэма)*

## 1

Кулларыма кабат гармун алдым
Көтмәгәндә-уйламаганда.
Ничек болай килеп чыкты әле –
Ничә еллар уйнамаганга?!
Яшьлектәге дәртле-ярсу көйләр
Ничек итеп әле онытылды?
Әллә нинди гамьсез тынлык баскан
Түгелме соң торган йортымны?!
Гармунсыз да яшәп булган, димәк,
Дөньясында,
Җырсыз-көйсез дә...
Ничек җан сакласаң булмыйдыр ул:
Яшиләр бит уйсыз-нисез дә.
Ничә еллар шуңа өйрәткәннәр...
Гармуннарның көе югалган.
«Җырның ертыгы юк» диләр дә бит,
Ертык җырлар күпме җырланган!
...Ничек итеп аерылдым сездән,
Исән микән әле, бармы сез? –
Онытылган көйләремне эзлим...
Гармун кирәк,
Булмый гармунсыз!..

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Әллә ничә төрле көй уйныйлар –
Тик берсе дә минем көй түгел...
Кушылып китә алмыйм көйләренә,
Ялгышыла,
Бетәм интегеп.
Көйгә килми аптырата сүзләр,
Кырган эшләр, кылган гамәлләр.
Утыртмакчы үзенең арбасына
Кыйбласыннан язган адәмнәр...

Иман нуры илдә калмаган чак...
Яшәмидер көй дә имансыз.
Кая китте җанны чайкар көйләр? –
Көй табалмыйм,
Нишлим мин ансыз?!
...Кулларыма кабат гармун алдым,
Әй уйныйсы иде гармунны,
Түгеләсе иде...
Нидер тота,
Юлларымда әллә ардыммы?
Ата-баба көе сагындыра,
Алар тоткан гореф-гадәтләр;
Юксындыра әткәй җырлаган җыр,
Моң яралган изге сәгатьләр...
Үз италмыйм бүтәннәрнең көен.
Кулларыма гармун буйсынмый...
...Бу җанымның әллә кай төшендә
Үкси-үкси бер көй сулкылдый...
Бер башласам, туктый алмам сыман,
Йә йөрәгем ярылыр, йә гармун.
Тик барыбер яши алмам ансыз –
Мин ул көйне эзләп табармын!..

## 2

Төймәләрдә йөри бармакларым –
Аваз арты аваз.
Искә төшә әнкәй догалары,
Ул укыган намаз.
Сабыр мәкам белән изге китап
Көен көйләр иде.
Аның күңелен дә аңламаган
Дөнья – юләр иде.
Кабул итми интектерде күпме
Теләкләрен аның.
Көйләр итеп уйнап булса икән
Бүген әнкәм җанын! –

Хәйран булып, аны урман-күлләр,
Таулар тыңлар иде;
Бер явызлык калмас иде җирдә,
Яулар тынар иде.
Иңәр иде рәхим-шәфкать бары
Кеше күңеленә...
Җир йөзенә шундый газиз бер көй
Җитми бүген менә.
Бер көй җитми.
Бөтен дөньясына
Бердәнбер көй бит ул –
Буыннардан буыннарга күчеп
Йөргән бер көй бит ул.
Кая китте әле,
Ник югалды
Безгә җиткәч кенә? –
Искә төшерәбез илдән-көннән
Рәт киткәч менә.
Искелек дипсеберәп ташлау барын
Булгандыр да уен –
Табулары югалтканны бер кат
Кыен икән, кыен.
Көй чыкмый шул әле, чыңласа да
Аваз арты аваз.
Искә төшә әнкәй догалары,
Ул укыган намаз.
Мин ул көйне эзли-эзли көн дә
Арып-алҗып бетәм –
Югалтканның барын көйләр итеп
Уйнап булса икән!..

## 3

Ничә еллар инде уйнамаган...
Тансыклаткан –
Күчәм көйдән көйгә.
Көйләрем тик ачылып киталмыйлар,

Ятсынгандай мине әллә нигә.
Исләремә төшерергә тырышам
Иң беренче откан көйләремне...
Әллә соң мин гомерем буйларына
Гел ят көйләр генә көйләдемме?
«Сахраларга чыгып бер сызгырдым,
Чапкан пакусларым кипсен дип;
Безгә кемнәр теләк теләде икән
Аерылышып гомер итсен дип?» –
Сизенгәндәй, үзәкләрне өзгән –
Сезнең җыр иде бит, авылдашлар!
Ул көйләрне сез җырлаган чакта
Күтәрелә иде авыр башлар.
Сезнең белән сахраларга чыгып
Сызгырганга күптән инде, күптән...
Бергәләшеп чапкан пакусларның
Печәннәре әллә кайчан кипкән.
Әллә кайчан...
Тик без печән түгел,
Күңелләр соң ник кибәргә тиеш?
Чәчләр генә агарадыр бары,
Яшәү бит ул һаман яшел килеш!
Төшләремә яшел килеш керә
Кызлар биеп йөргән чирәмнәре...
Исемнәрең атап җырладылар...
Ул җырларның безгә дигәннәре,
Инде менә ничә еллар уткәч,
Кочагыма керә гармун булып...
Уйнаганбыз-җырлаганбыз. – Ничек
Шуларның соң хәзер барсын оныт?!
Оныта язган – мин генәме дисәм,
Ул көйләрне хәзер кемнәр белә?
Кемнәр яман теләк теләде икән,
Ниләр булды безгә, ниләр генә?!
Үзебез болай әле исән кебек,
Беребез дә юкса авырмады.

Җырны гына бүтән көйгә җырлый,
Бүтән телдә... татар авыллары.
Кочагыма керә гармун булып,
Ятим көйләр...
Их, бер сыздырасы!
Әллә инде, авылдашлар кебек,
Сахраларга чыгып сызгырасы?!

**4**

Малай чактан бирле тынгы бирми
Өзгәләнә –
Нинди көйдер ул?
Җырлый гына алган юктыр үзен...
Көй генәме? – Белмим, нидер ул.
Алып китә, китә еракларга,
Кем чакыра,
Ниләр тарта соң?
Җаның гарык булган чынбарлыкка
Килмәстер шул кире кайтасың!
Кайтаралар...
Ничек кенә әле! –
Кешелегең салып таптыйлар;
Хак сүзеңне юкка чыгаралар,
Чеп-чи ялган – шуны хак диләр!..
Үзләренә баш идерү җитми –
Этләренә кадәр сәлам бир...
Шул этләрдән көең өзгәләтми
Алып кал да кошка әйләндер!
...Саклап алып килә́м ул көемне
Малай чактан бирле – ерактан.
Таласалар – шулдыр ардаклаган,
Күңел катса – шулдыр елаткан...
Җаны булган – җырламыйча тормас,
Һәркемнең дә көе буладыр;
Әллә кайчан бөгәр иде язмыш –
Баш имибез шуңа гынадыр.

Күкрәгеңдә көең исән булсын,
Халыклар да бетә, көй үлсә.
Эзлик әле, гармун,
Уйныйк әле –
Яшәү юктыр ул көй өзелсә!..

## 5

Яшәү юктыр җирдә җырлар үлсә...
Сихерләгән безне кай ара –
Төймәләргә кул тиюгә,
Гармун
«Туган тел»гә таба каера.
Ничә еллар дәшми торган иде –
«Туган тел»не уйнап терелә...
Көйне көйдән аералыр икән
Кеше түгел, гармун теле дә!
«И туган тел, и матур тел!» – дидек.
Матур иде, көйле иде дә...
Шул көенчә саклый алдыкмы соң?
Газиз көй бит – нигә өзелә?
«Әллә-бәлли...» – дип башлаган идек,
Ялгышылды кайсы төшендә?
Үз көеңне эзләү җитми икән, –
Эзлиседер улың өчен дә.
Тамагы тук, өсте бөтен, дисең,
Өе җылы – тагын ни кирәк?!
Балалар да кеше икән лә бит –
Аларга да моңлы көй кирәк!
Күпме җанны моңсыз калдырганбыз,
Өер-өер йөри моңсызлар,
Көпә-көндез кеше үтерәләр...
Өзелгән көй әле мең сызлар!
И туган тел, и матур тел! Синең
Бардыр тагын ниләр күрәсең? –
Ялалы кош сыман бәргәләнеп,
Көйләремә килеп керәсең...

## 6

Юкка гына интектермим микән:
Бер тартыла, бер кысыла күрек...
Табылыр да кинәт серле көем,
Бер сыздырып җибәрермен кебек.
Кайчагында шыбыр тиргә төшәм...
Түзәрсең лә әле моңа гына –
Тик нишләмәк кирәк,
Синең әгәр
Аю баскан булса колагыңа?!
Колак кына туры килсә – бер хәл,
Йөрәгеңә мөмкин басулары...
Табандагы йөрәк белән дә бит
Яши ала, хәер, кайсылары!
Түрәләре табаныннан гайре
Берни күрми алар, ишетми дә...
Ә син монда гармун җәфалыйсың,
Эзләнәсең, көйдән күчеп көйгә.
Юк ла!
Һич тә алар өчен түгел –
Басмасыннар өчен йөрәгемә!
Инанганга күрә «аю»ларны
Биетердәй көйләр кирәгенә...

## 7

Табулары көйне, һай, озактыр,
Югалтулар гына тиз аңа:
Бер бозык кыл көйне генә түгел,
Язмышларны, илне бозала!
Бер генә дә бозмадылар инде...
Уйнадылар бозык килеш тә:
Өләштеләр илне –
Түзә килдек,
Ни тисә дә безнең өлешкә.
Әйтеп булмый берни тимәде дип,
Тиде безгә, хәйран күп тиде!

Күпме гомер сөреп, бу чаклы ук
Гаҗизлектә калган юк иде!
Хәмер сатып, очын очка ялгар
Көнгә төштек...
Адәм ышанмас!
Ваемсызлар бардыр дөньясында –
Тик барыбер безгә җиталмас...
Уйнадылар...
Күпләр сизмәгәндер
Нинди ялгыш аваз сузганны.
...Мин бер гармун белән төзәтмәкче
Түгелме соң алар бозганны?
Афәт килсә, халык борынгыдан
Ил өстенә сала, тигезли.
Кемнең генә тыныч икән җаны –
Көйне бүген бөтен ил эзли!..

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Кулларыма кабат гармун алдым,
Уйнамыйча булмас бер алгач.
Әллә нинди көй сулкылдый канда...
Җаны булган – җырсыз торалмас.
Ничә еллар буе уйналмаган...
Түгелмичә калмас күңел бер.
Яшәмәскә, бәлки, мөмкиндер ул –
Көйсез яшәү мөмкин түгелдер!
Көйдән көйгә килеп кагылырсың,
Кирәклесен барыбер табарсың.
Өйдә, бәлки, бер гармун да җитәр –
Илгә көйне каян аласың?!
Кемнең генә тыныч икән җаны –
Ил кадәрле илгә көй кирәк!
Без бит хәзер – ничә еллар буе
Уйналмаган гармун төслерәк.
Уйнаулары инде кыендыр да,
Уйнамаска мөмкин түгелдер.
Илне ничек көйсез калдырасың? –
Уйныйк әле, уйныйк бүген бер!..

# V. Авыл җаны

...Әнкәйләрнең игез сыңарыдыр,
Ахрысы, син, туган авылым!..



* * *

Сулар булып актым туган яктан,
Моңнар булып кайттым яңадан.
Мин генәме яраланган җанын
Татлы сагыну белән ямаган?!
Сагынабыз туган туфракны без,
Болытлар һәм җилләр булып та,
Үсмер егет булып сагынабыз,
Сагынабыз ирләр булып та.
Илдән киткән кошлар сагынудан
Каурыйларын коя диңгезгә.
Соңгы сүзе итеп картлар әйтә:
– Күмегезче туган нигезгә!..
Мәңгелеккә чит җирләрдә ятып
Калганнарның каберләрендә
Тибрәнә гөл туган якка карап:
– Белмәгәнбез кадерләрен лә...

## ҖИЛ

Авылыма сары көз сузыла:
Тәрәзәгә сугып уза җил,
Каеннарның чәчен сибеп ташлый,
Хәтеремә кереп туза җил.

Бар көченә дулый-дулый да ул,
Киереп ача хәтер капкасын.
Әйдә, йөрәк, чыгыйк әле шуннан,
Юлыбызны җырлар капласын.

Чыксын тагын безнең белән бергә
Шул кыюсыз авыл малае,
Йөгереп чыккан шәпкә сагышларның
Бәреп ярсын әле маңгаен!..

Ә агачлар менә бүгенгедәй
Сары тәңкә сипсен юлына,
Һәм әнкәсе лампа яктысында
Чүпрәк сумка тексен улына.

Кабатласын тагын бөтен класс:
Я...яфраклар, к...көз, а...авыл...
Эх, йөгер син, хыял, малай чакка,
Тынмас шунсыз җанда бу давыл!

...Авылыма сары көз сузыла,
Капкаларны каерып уза җил,
Юлларыма алтын тәңкә сибә,
Хәтеремә кереп туза җил...

## АЛМА ИСЕ

Шыбырдашып алма коела җиргә,
Исләренә булмый түзмәле.
Сихерли дә куя бакчалары –
Кызык та соң шушы көз мәле.
Уйлама да, җибәрми ул сине,
Кызыктыра барыбер, алдалый.
Без гаеплемени инде аңа? –
Бакчачы карт шуны аңламый.
Колаклардан тартып үстермәсә,
Үсми калыр идек әле без.
Эх, бер колак җәлмени соң безгә, –
Алма гына булсын әҗере...
Шыбырдашып алма коела җиргә,
Әллә каян килә исләре...
Иярә дә китеп бара күңел,
Һич тыңламый мине, тискәре!
Алып кайта тагын шул авылга,
Көзләрнең шул алтын мәленә;
Шул бакчаның алмалары булып,
Сабый чагым җанга бәреләә...

## Ә БӘБКӘЛӘР ҺАМАН ЯШЕЛ...

Кире кайтты миңа бүген
Бала чакның яз көннәре:
Яшел чирәм өсләрендә –
Яшел йомгак тәркемнәре...

...Онытасың алар барын –
Бала чакның китми исе!
Саклый иде бәбкәләрне
Чирәмнәрнең яшел төсе.

Кайвакытта үзебезне
Кайгы-хәсрәт сагалады,
Сабый чакның яшел төсе
Бирми алып калгалады.

Таралыштык.
Еллар ятты
Ул чирәмнең өсләренә.
Вакыт узгач уңа микән
Әллә язның төсләре дә? –

Бәбкәләр бар, чирәмнәр юк...
Югалтырны кемнәр белгән!
Чирәмнәрне алып китәр
Тилгәннәр соң каян килгән?

...Ә бәбкәләр һаман яшел,
Күкләр һаман шулай биек –
Алданалар мескенкәйләр
Тилгәннәр күрми диеп.

Нинди төскә сыенырга,
Кайсы төштә чүгәләсе? –
Безне кемдер сагалый күк,
Җир өстендә күләгәсе...

## ИКМӘК

Кеше белән гел янәшә Икмәк –
Кырда, юлда, табын янында.
Иң беренче өйгә Икмәк керә,
Яңа йортка күчкән чагында.

Һәммәбездән өлкәнрәктер ул,
Яшәсәк тә җирдә нихәтле;
Шуңа хөрмәтледер исеме аның,
Шуңа газиз, шуңа хикмәтле.

Бардыр анда картлар олылыгы
Һәм ирләрнең сынмас ныклыгы,
Садәлеге бардыр сабыйларның,
Әниләрнең күңел аклыгы.

Ничә килсәң Икмәк үскән җиргә,
Шулкадәрле башны орырлык:
Ерак юлга чыккан бер дәвердер –
Туфракка төшкән бер орлык!

* * *

Иңнәрендә – сары толымнары,
Нинди уйга тарыган ак каен:
Яфракларын агызып, көзге җилдә
Чайкый-чайкый юа башкаен.

Һәр яфрагы саубуллашып уза,
Моңсулыкка чумган бу алан...
Йөрәк җирдә күпме яшәсә дә
Аерылмас кебек дөньядан.

Агачларның сары чәчен сыйпый,
Юата җил һәрбер тирәкне;
Давылына салып бу дөньяның
Тирбәтәсе иде йөрәкне!..

# КӨЗГЕ ТОРНАЛАР

Безнең җәйдән бугай бу торналар –
Таныш кебек канат кагышы,
Сагышлары шулай зур микәнни? –
Басуларга иңгән сарысы.

Тавышлары канат җиле белән
Киңлекләргә кала таралып,
Ул авазлар тиеп узган җанда,
Юк, тамчы да булмас каралык!

Ниләр икән:
Басу өсләреннән
Җилли-җилли узды сибәләп? –
Бу яңгырлар киткән торналарның
Күз яшьләре булса ни гаҗәп!..

Юл бирделәр көзләр,
Торналарны
Җил-яңгырлар аша үткәреп, –
Китеп барды алар,
Моңсу җанны
Болытларга кадәр күтәреп...

## ТАЛЛАРГА

Каз оялары талчыбык –
Кайсы тугай таллары?
Җилдә шаулый алмадык дип
Тиргәмәгез казларны.

Күктә очкан чакларында
Төшмәсен каргышыгыз,
Үкенечләргә калмасын
Аннан бу ялгышыгыз.

Очып калсыннар әле бер,
Болытка тиеп-тиеп,
Кавырсыннарын коярлар,
Булсыннар ядкарь, диеп.

Каз ояларын тал чыбык,
Үтенеч бар талларга:
Гомерләре бер генә җәй, –
Рәнҗемәгез казларга...

# КИБӘНЧЕ КАРТЛАР

Печән чапкан чаклар булды,
Кибән салган чаклар булды,
Кибән өсләрендә торган –
Ак сакаллы картлар булды.
Кире кайтып карап йөрим,
Барлап йөрим еллар үткәч:
Хәтердәге кибәннәргә
Яңгыр түгел, җил дә үтмәс! –
Уттай кызу печән өсте...
Һаман шул ук алан бугай;
Картлар кибән түбәсендә
Бөтенләйгә калган бугай.
Куймаганнар икән әле
Агач япьле сәнәкләрен;
Ага вакыт...
Төшми картлар –
Белми авыл сәбәпләрен.
Белми авыл...
Яшьләр сизми –
Кемнәрендер җуя йөрәк,
Сыкрый җилләр... Җанга никтер
Югалганнар кадерлерәк!
Киез эшләпәле картлар
Төшми кибән өсләреннән –
Безгә карап дәшәләр күк
Үткән гомер эчләреннән...

# ӨЯНКЕЛӘР

Авыл өсләрендә өянкеләр
Әллә нинди моңлы көй әйтәләр:
Ишетелеп китә чулпы чыңы,
Аваз сала чиләк-көянтәләр.
Көтүченең саллы чыбыркысы
Ярып уза Вакыт урамнарын;
Сизде микән авыл, һәр авазның
Өянкеләренә уралганын?
Кичке уенга чыккан егетләрнең
Дәртле җыры агач шаулавында;
Парлылардан күчкән йөрәк сере
Ак мамыклар булып ява монда.
Чит җирләрдә туфрак булганнарның
Сабый чактан калган тавышларын
Тын алмыйча тыңлап тора бүген,
Сизми авыл төннәр авышканын.
Өянкеләр шаулый...
Шаулый еллар –
Тереләләр көннәр кире кайтып;
Малайларның табан җылыларын
Яфраклар эзли җиргә ятып...
Тузгып китә, җил кагылган саен,
Ут-суларны кичеп килгән көйләр.
...Гомерләрнең шәҗәрәсе булып
Басып тора моңсу өянкеләр...

# АВЫЛ. КИЧКЕ ЗИРАТ

Җирдән китеп барган авылдашлар
Якын түгел, түгел ерак та...
Башым иеп басып торам менә,
Басу уртасында – зиратта.

Ник ичмасам берәр кош сайрасын,
Нигә, дөнья, сыңар утың юк?
Чигәләрне, тынны кысып тора,
Җаннарыңны изә бу тынлык.

Су астыннан килгән кебек кенә
Малайларның кичке чыр-чуы...
Чалгы чүки берәү:
Гигант сәгать йөри! –
Гаҗиз калып тыңлыйм мин шуны.

Ымсындырып тора кебек авыл –
Ерак түгел, түгел якын да:
Этләр өрә... Ярсып тайлар кешни...
Гармун чыңлый еллар артында...

Шул елларны күкрәк белән ярып,
Мин авылга чыгам зираттан!
Манма суга төште күлмәкләрем –
Арышларны чыклар чылаткан...

## КӨЗ

Ал кульяулык агач башларында...
Яшеренеп болыт асларына
Елый бүген кояш берьялгызы...
Ничек түзсен кошлар башка монда!

Урманнарда – яфрак бураннары,
Һаваларда – каурый тузаннары,
Тимерчыбыкларга бәреләсугыла,
Урам буйлап очты йорт казлары.

Китәлмичә безнең аралардан,
Карап тора соңгы алмалардан
Сары чәчле моңсу кызы җирнең...
Җырым белән шуны озата барам...

* * *

Назларыңда – әнкәй мәхәббәте
Язларыңда – әнкәй җылысы,
Исләреңдә гел без генә бугай,
Кичләреңнең юктыр тынычы.

Искән җилләр, аккан сулар булып
Сузылалар миңа кулларың,
Салкыннарда өреп җылытыр идең,
Килеп җитсә әгәр тыннарың.

Гомерләргә мәңге сүрелмәслек
Изге көйләр булып кагылдың,
Әнкәйләрнең игез сыңарыдыр,
Ахрысы, син, туган авылым!..

# ЧИШМӘНЕ САГЫНУ

Авыл башындагы чишмәләрдән
Башландык без, чишмә төбеннән, –
Аның берчак сагыну диңгезенә
Илтеп чыгарасын кем белгән?!

И беркатлы авыл малайлары!
Чишмә түгел, сөю булган ул;
Эчеп туймас булыр идек аны –
Ник әйтмәгән безгә бу авыл?

Моң булган ул, яшәү моңы булган,
Сизмәгәнбез ничек ул чакта?
Ага җанда, инде чишмәләрдән
Бик еракка киткән булсак та.

Шунда булган башы изгелекнең,
Шуннан килә сафлык, ышаныч!
Хыялларда – чишмә зәңгәрлеге,
Шул чишмәдән безнең бу тавыш.

Чуерташлар түгел, балачакны
Җыйганбыз шул чишмә төбеннән.
...Бу дөньяга чишмә төпләреннән
Агып чыгарыңны кем белгән?!

* * *

Безнең якка таба яңгыр узды,
Бәхетледер, ахры, бу яңгыр.
Тәрәзәгә чиртсә, газиз әнкәм
Улым кайткан диеп куаныр.

Яңгыр узды...
Күпме көтәсе бар
Ул хәбәрләр алып килгәнче.
Туган якка үрелеп карар идем,
Болытларга башым тигәнче...

## БАЛАЧАК ИЛЕ

Урамнары – яшел чирәм,
Һавалары – ак болыт.
Җилләр – канатлары икән,
Хыяллары – яктылык.

Алдау-мәкерләрне белми
Гомерләрнең бу иле;
Үтеп кералмый хыянәт,
Кайгылар китә кире.

Законнары – эчкерсезлек,
Буйсыну шуңа бары;
Диннәре – сафлык динедер,
Әкият – догалары.

Бөтен халкы бертигездер:
Патша да юк, кол да юк.
Бу илдән бер чыгып китсәң,
Кире кайтыр юл да юк...

# НУР БУЛЫП КАЛЫККАНСЫҢ...

*Туган авылымда, безнең өй урынында*
*үсеп чыккан яшь каенга*

Талпынасың, тартыласың –
Җилме бер, каенмы син?
Кабатланмас шатлыгыммы,
Әллә бер кайгыммы син?

Безнең гөнаһсыз чакларны
Күтәреп алдыңмыни?
Тирәннән алып чыктың да,
Уйларга талдыңмыни?

Яктырып басып торасың, –
Карлар сарылдымы әллә?
Әбием-бабамнар җаны
Шулай ак идеме әллә?

Без монда кичергәннәрне
Син генә беләсеңдер,
Шуларны бөтен дөньяга
Күрсәтим дигәнсеңдер...

Туфрак-дымнан гына түгел,
Еллардан, халыктан син! –
И каен! Чорлар төбеннән
Нур булып калыккансың...

* * *

Тәлгәш-тәлгәш аклык иңә күктән,
Урамнарны тагын кар басты.
Чыгыйк әле,
Ерак кышларыма
Карлар кабат алып бармасмы?

Балачакның ап-ак үрләренә
Илтмәс микән гомер чанабыз?
Үрләр генә иде...
Тик белмәдек
Меналмасны беркөн аңа без.

Бар дөньяны тагын карлар басты,
Чыгалмыйча йөрим көртләрдән.
Кайсы кыштан күчкән аклыктыр бу –
Таралышып төшә күкләрдән.

Ни буласын белмәгәнбез ул чак –
Тик уйнадык кына кар атып...
Балачакны очырганбыз бугай
Киләчәккә таба каратып...

# КЕСӘДӘГЕ ҖИЛ

*(Шаян хәтерләү)*

Малай чакларда ук безнең
Кесәләргә җил кергән –
Ни салсаң да, салган берсен
Илгә чыгып җилпегән.

Һич мантымады кесәләр,
Тулып тормады бер дә;
Шунда кереп уйнамаса,
Урын беткәндер җилгә!

Өләште чикләвеген дә,
Таратты борчакны да;
Өлешсез калдырмады ул
Дусларны бер чакны да.

Хәзер инде аптырамыйм:
Байлыгым – бөтен илдә.
Рәхмәт инде малай чакта
Кесәмә кергән җилгә!..

* * *

Яктыдан да якты – нәрсә якты,
Уткайлары шулай яп-якты? –
Күзем бәйләп адаштырсалар да,
Әллә каян күрәм ул якны.

Бер киттем дә чыгып, күшеккәндә
Җаннарымны кайтып мең куйдым:
Җылыдан да җылы – нәрсә җылы? –
Айлар-еллар аша мин тойдым.

Йомшактан да йомшак – нәрсә йомшак? –
Кочагына алды ни кылсак;
Инде бүтән берни кирәкмидер,
Туфрагына кайтып егылсак...

## АВЫЛЫМДА ШУНДЫЙ ШАГЫЙРЬЛӘР БАР...

Авылымда шундый шагыйрьләр бар –
Алар бер дә язып карамаган.
Еллар буе бары иген иккән,
Чана ясаганнар карамадан.

Азапланып йөрмәгәннәр һичбер
Усал наширләрдән сыздыргалап –
Үз эшләрен көйгә китергәннәр
Кагып-сугып һаман, сызгыргалап.

Беркайчан да алар тапкыр сүзгә
Кермәгәннәр кеше кесәсенә,
Онытылмаслык итеп әйтә белгән,
Исәп тотмый телгә күчәсенә.

Төче сүзләр сайлап маташмаслар,
Тупас кебек бераз читтән алар,
Ә үзләре печән чапкан чакта
Болыннарга чигү чиккән алар.

Дөнья матурлыгы, яшәү гаме
Шулар йөрәгендә – сөенсәнә!
Бер тапкыр да шигырь язмаганнар –
Шагыйрь алар шушы көенчә дә...

* * *

Күргән-кичергәннең бик күбесе
Әллә кайчан инде онытылды.
Тик үземнән бер дә калдырмыймын,
Кая барсам, туган йортымны.

Кыен чакларымда мин һаман да
Сыенамын килеп шул өйгә;
Күңел түремдәге ул җылыны
Алыштырмас инде берни дә!

Кош оясы кебек кенә өйгә
Туганнарым җыям, дусларым;
Кагылырга кыймый тора аңа
Кышлар булып салкын кышларың.

Эчләренә сеңеп калган моңны
Инде ничә кереп тыңлады –
Балачакта сине юаткан өй
Юаталыр икән дөньяны!

Туган өйле килеш яшим һаман,
Сүтелсә дә күптән ул нигез.
Түрегез бар –
Әгәр күңелегездә
Булса гына туган өегез...

* * *

Җәйге бакча.
Түтәлләрдә гөлләр.
Куакларда җимеш өлгерә.
Янәшәдә урман – кошлар тулган,
Бу чакта ул күпме тел белә!
Шау табигать.
Авыл баласына
Шуннан ары тагын ни кирәк?!
Нидер җитми...
Никтер монда да мин
Читлектәге бер кош төслерәк.
Монда да мин ятим.
Үрсәләнәм,
Аңлый алмыйм нәрсә булганны.
Урман артындагы басуларга
Алып чыгып китәм бу җанны.
Басуларда печән эскертләре,
Тигез итеп, тарап өйгәннәр.
Яшел бөдрә кибән төсле булып
Утыралар ялгыз имәннәр.
Арыш арасында зәңгәр чәчәк,
Шулар бит бу – авыл кызлары! –
Зәңгәр күзләр арыш арасында,
Күренмиләр никтер үзләре?
Үр артында авыл.
Ымсындырып,
Түбәләре әнә өйләрнең
Хәтер булып калкып күренеп тора...
Шашмам микән, димен, берәр мин?!
...Җилтерәтеп алып чыгып китә,
Яз-көз дими, иртә таң дими,
Алып кайталмыймын –
Бакчаларга
Ябып кына асрар җанмыни?!

## САЛАВАТ КҮПЕРЕ

Бер адым калмый артымнан
Йөгерә малай чагым:
– Салават күпере төшкән,
Кил, барып карыйк тагын!..

Уйларым малай чак булып,
Сызганып балакларын,
Йөгерә юеш чирәмнән,
Төсләрнең сайлый алын.

Җил килеп, көтүче сыман,
Болытларны куа да,
Янына барып җиткәнче,
Күпер инде югала...

Еракта калган малай чак –
Бары тик хыял гына,
Хыял – салават күпере –
Туа да юкка чыга.

– Салават күпере чыккан,
Кил, барып карыйк тагын! –
Хәтернең ал офыгында
Йөгерә балачагым...

## АРЫШ КЫРЫ

Урамнарга шаулап килеп керде,
Җилләп керде июнь басудан...
Колач җәйгән басу капкалары –
Төбенә чаклы киереп ачылган.
Ызаннарга килеп егыла-егыла
Йөгерешә яшел дулкыннар.
Басу өсләрендә ап-ак томан –
Арыш кыры серкә очыра.
Җилкендерә җанны шушы мизгел,
Сикерәсе килә дулкынга, –
Ничек түзмәк кирәк, офыклардан
Офыккача диңгез булсын да!
Диңгезләргә диеп, без тормышка
Ташланганбыз икән шушыннан, –
Арыш кыры, серкәләрен түгел,
Ул җәйләрдә безне очырган.
Дулкыннарга салып, кай якларга
Алып чыгып киттең син безне,
Кайсы ярга илтеп чыгарырсың,
Бала чакның яшел диңгезе?!
...Узып бара җәйләр, капкаларны
Япмый киткән кемдер, онытткан...
Гомерләрнең арыш кыры шаулый,
Офыклардан сугылып офыкка...

# АВЫЛ КАРТЛАРЫ

Алсулыкмы, әллә моңсулыкмы? –
Офыкларның янган чаклары...
Капка төпләрендә сабыр гына
Нидер тыңлый авыл картлары.
Пар толымга таккан чулпыларның
Чыңгылдавы, ахры, җаннарда, –
Сөю шулай сарылып калган бугай,
Гомерләрдән узып барганда.
Дугаларга таккан кыңгыраулар
Шулай моңлы булды микәнни?
Кая чапты алар? –
Артларыннан
Йөгереп карый хыял, җитәлми!
Чалгы кайрый кемдер,
Покос-покос
Сузылып калган еллар эченнән
Тараладыр ул чалгының тавышы –
Таныш моңы кичләр өстендә...
Тыңлый картлар,
Үткән гомерләре
Кайта гүя капка төбенә...
Ямансудыр инде икенче кат
Яшәүләре бер үк гомердә.
...Картлар гына ишетә ала торган
Моңнары бар, ахры, кичләрнең,
Гомер дигән төш күргәннәр бугай,
Бүлдермәдек микән төшләрен?..

# ӘЛЛИ-БӘЛЛИ...

Матчаларга элгән бишек –
Әлли-бәлли, әлли-бәлли...
Сабый җанга ни кирәген
Син кайлардан сиздең әле?

Әлли-бәлли...
Газиз бишек!
Авылымдагы ерак кичтән
Синең һәрбер тирбәлешең
Әйтерсең лә миңа күчкән.

Ага алар миндә бүген,
Тамырларда тибеп-тибеп,
Талпынасың гомердәге
Арымас бер йөрәк кебек.

Очкан коштай тирбәләм мин,
Син – гомерләр агышында;
Еллар аша көең саркый
Һәм кушыла тавышыма.

Юатырга җырың әзер,
Булса җанның җирсәү мәле:
– Әлли-бәлли...
Син кайлардан
Сизәсеңдер минем хәлне!..

* * *

Төркем-төркем кошлар күтәрелде,
Очып узды гомер өсләреннән, –
Таралдылар...
Кайдан эзлим инде,
Бу дөньяның кайсы төшләреннән?
Төркем-төркем китеп югалдылар,
Бик аз гына миндә булып бары да.
Бала чакның моңсу торналары!
Тавышыгыз кайсы болытларда?
Безнең өйнең түбә кыегына
Оялаган җитез карлыгачлар!
Сезнең кебек без дә бишәү идек...
Ниләр күрде икән сезнең башлар?
Әллә кайда, ерак-еракларда
Ачыргаланалар акчарлаклар, –
Тик аларга мәгълүм иде безнең
Мәхәббәттән күккә ашар чаклар.
Тел китергән серле сыерчыклар,
Аккошларым, тургай-былбылларым!
Бармы тагын берәр белүчесе
Ниндилеген безнең бу юлларның?
Төркем-төркем:
Көннәр... айлар... еллар...
Җил дә давыл гомер өсләрендә.
Кошкайларым!
Без кайларда икән,
Шул давылның кайсы төшләрендә?!

* * *

Бала чакта бары да ерак була:
Ерак иде басу капкасы,
Әллә кайда иде күрше авыл,
Ничек кенә урап кайтасы!

Үсеп җитеп булмас кебек иде...
Интекмәдек озак баш ватып.
Без түш белән шуып чыгып киттек
Бала чактан... капка аслатып.

Тик бер генә карамакчы идек
Офыкларны авыл читеннән,
Түбәләр дә инде күренмиләр...
Ераккарак, ахры, кителгән.

Хәтердәге җепнең бер башыннан
Шул бала чак һаман тарткалар,
Йөгереп кире кайтыр идек тә бит –
Эчтән бикле калды капкалар!

* * *

Авырлыктан түгел, сабырлыктан
Көрсенделәр илнең ирләре.
Бүген авыл, йөрәгеннән суырып,
Туксан яшьлек моңын җирләде.

Бик биектән кыйбла якларына
Кыр казлары үтте каңгылдап,
Туксан җәйдән җыелып килгән җылы
Чыгып китте бүген авылдан.

Иярделәр аңа урман-кырлар...
Сыймадылар ләкин зиратка;
Урманнарга килгән туксан көздән
Нидер күчте бүген ир-атка.

Бураннары узды туксан кышның,
Туксан язның акты сулары.
Ирләренең иңнәренә салып,
Илтте авыл бүген шуларны.

Йөрәгеннән суырып алса алды,
Газраилгә ләкин бирмәде –
Бүген авыл туксан яшьлек моңын
Ирләр бәгыренә җирләде.

## БУСАГА

Киткәннәрнең җылы аяк эзен
Саклап тора сыман бусага,
Кеше кайта,
Кайта туган өйгә,
Бик күп сулар аккач булса да.

Исән булса, үзе кайтып төшә,
Хат-хәбәре килә, соңласа,
Җилләр булып газиз җаны кайта,
Даны кайта, исән булмаса.

Тәүге эзгә бер басарга тиеш,
Кеше кайтып ничек булса да;
Намусыңа кара таплар кунса,
Юк, уздырмый эчкә бусага.

Үтәлмәсәң әгәр аның аша,
Урын табылмаса түреңдә, –
Каһәрләнеп куылган эт кебек,
Син елларның ишек төбендә.

Нинди хәлдә кайтып баш орырбыз
Туган өйгә – изге тупсага?
Без узарга тиеш түргә кадәр,
Урыныннан йөрәк купса да!..

# ИСКЕ НИГЕЗ ӨСТЕНДӘ УЙЛАНУ

Күптән янып көл булгандыр
Утынга дип сүтелгән өй...
Инде менә үземне дә
Сүрелмәс бер көй телгәли.
Шәфәкъ алсулыгы төшкән
Кычытканнар арасыннан,
Әйтер сүзен әйтәлмичә,
Кемдер карап кала сыман.
Игәүлиләр чикерткәләр
Узып барган гомерләрне.
Иңри сыман иске нигез:
«Килерләрме... Килерләрме?..»
Җылысының иң соңгысын
Кемгә диеп саклый болай?
Өй урыны...
Монда Вакыт
Бер таба да акмый бугай!
Шул көенчә торып калыр
Икән бездән бөтенесе:
Кайгылары, шатлыклары,
Уфтануы, үкенече...
Тынгы бирми буш нигезләр...
Беркөн берәү, минем кебек,
Бушап калган Җир шарына
Башын иеп килер кебек...

## ЧАКЫРУ

Әллә сагыш, әллә язмыш булды –
Сизмәдем дә кемнәр дәшкәнен...
Шушы җырда бер күрешик әле,
Урамдашлар, чирәмдәшләрем!

Еракларадан килгән шушы җилдә
Яланаяк калыйк, яланбаш;
Бергә чакта төрле-төрле идек,
Бер моң булдык менә, таралгач.

Ишетәсезме икән, югалтышкан
Казлар кебек кыйгылдашканын –
Җаннар бергә сарылсыннар әле,
Шатлыкташлар, кайгылдашларым!

Бу сезнең дә сагыш көнеме әллә –
Таңнан бирле яңгыр сибәли?
Бер җылыныйк бүген, җырдашларым,
Җыйналышып Сагыну тирәли.

...Үсмер чакта бер җырлаган идек,
Җырлыйк әле чәчләр чаларгач;
Еракларадан моңлы бер җил килә –
Яланаяк калыйк, яланбаш!..

## АЛМА ӘБИ

Бакча тулы яшелчәсе булды,
Тәрәз төбе тулы – гөлләре;
Җәйләр җитсә, алъяпкычын киде –
Урманнардан кайтып кермәде.
Үләннәрнең «телен» белгәндер ул,
Табиб иде бөтен авылга;
Елга бер булса да, Алма әбинең
Чәен эч син, авыр-авырма.
Хасталаса, аннан гына алды
Бөтен авыл кирәк дәваны,
Кыш әйтерсең килми иде безгә –
Җәйләрнең ул булды дәвамы.
Ничә барсаң, булды мәтрүшкәсе,
Кипкән җиләк, бөтнек, җир мае,
Гөлҗимеше...
Барыннан да элек –
Тәмле сүзе, ачык чырае.
Авыз итми кала күрмә аның
Бакчасында үскән алмасын.
Юкса халыктагы юмартлыкның
Исен-тәмен тоймый каласың.
Яше дә юк иде,
Ил анасы
Яшь исәбен белә димени...
Кирәкми дә –
Халык исән чакта
Алма әбиләр үлә димени!
...Үткәннәрнең моңсу урамыннан
Исеп үтәм кайчак җил булып –
Тәрәзәдән Алма әбиләр карый,
Ал чәчәкләр аткан гөл булып...

## ӨЙ ӨМӘСЕ

Җәйләр җитсә, авыл өмә әйтә,
Шау-гөр килеп өйләр күтәрә;
Нигезләргә тәңкә сала картлар:
Бәхет бирсен гомер итәргә!..
Бөтен авыл кереп биесә дә,
Бирешмәслек имән өрлекләр;
Өйне түгел – илне күтәрерләр, –
Ир-егетләр өрлек кебекләр.
Җеге җеккә килеп кенә тора,
Ятып бара нирггә ниргәгә;
Кул да тими кала бүрәнәгә, –
Нидер булган бүген ирләргә.
Мүге белән бергә ниргә саен
Шаян сүзне түши мул итеп,
Яктылыгын сала күңелләрнең, –
Гомер буе торсын җылытып!
Җайлап кына тезә түшәмнәрне,
Ипле итеп сала матчасын.
Елларына-чорларына түзәр, –
Кайгы-хәсрәт кенә ятмасын!
Почмакларның тигезлеген карый,
Балталарын асып осталар,
Бәхетне дә тигезлисе алар,
Тиң итәсе, әгәр кушсалар.
Өмә белән өй күтәрә авыл:
Кыз төшәсе, туйлар буласы...
Гомер кичерәсе... картаясы...
Бәрәкәте җитсен шуңарчы!

## КАПКА АЧУ

*Рафаил абыйга*

Малай чакта ачкан капкаларның
Яктылары, ахры, килер мәңге:
Авылыбыз килен төшергәндә
Ачып керттек күпме киленнәрне!

Гомерлеккә бүләкләгән язмыш
Капка төпләрендә чакта безне:
И абыйлар!
Үзебез дә белми
Ачканбыз ла бәхет капкагызны!..

Киереп ачып куйгач, ул капкалар
Шул көннән соң бер дә ябылмады;
Урап узды (без ачканга күрә!) –
Кайгы-фәлән килеп кагылмады.

Кунак өзелмәде бәйрәмнәрдә,
Йортка дәүләт керде, муллык инде.
Уңган килен белән килгән бәхет
Кире китәр өчен түгел инде!

Гореф-гадәт саклап, абыйларга
Капка ачып керттек бәхетне без.
Гомерлеккә бүләкләгән язмыш:
Үзебез дә бетмәс бәхетле без...

## АВЫЛЫМ ЮКӘЛӘРЕНӘ

Гөжләп тора, көйләр көйләп тора –
Бал исенә чумган юкәлек.
Шунда кемдер килеп чыгар төсле,
Чабаталык юкә күтәреп!

Ничек ясап өлгерткәннәр диген
Әбелфатих, Әхмәт, Гаделхак?* –
Үз киемен салып биргән безгә,
Киендергән урман... Юксыл чак!

Бөтенесе юкәлектән иде:
Кабык бишек, чыпта, мунчала;
Аркан булып тартты авылны ул
Якты көнгә... Юкә булса да...

Чабатаны күптән оныттык без,
Коляскага күчте бәбиләр;
Чыпта урынына идәннәргә
Затлы палас алып җәйделәр.

Әбелфатих, Әхмәт, Габделхаклар –
Гүр иясе инде күптәннән.
Тик нигәдер менә җырга керә, –
Күтәрелеп алар үткәннән.

Авылым юкәләре!
Сискәнмәгез, –
Каезламас инде беркем дә:
Чакырырга гына килдем сезне
Җырларыма – моңлы төркемгә...

* Әбелфатих, Әхмәт, Габделхак – авылның оста чабатачы картлары иде.

...Хозурыма бүген үткәннәрдән
Авылымны килә күтәреп,
Хәтер кебек гөжли,
Бал исенә –
Моң эченә чумып юкәлек...

## МИНЕМ ТУГАН ЯКЛАРЫМДА

Чыгып тирбәлим бер дисәң,
Җил мондагы ишеме?! –
Минем туган якларымда
Җилләр – җанның бишеге...

Чиртәдер Сөю тын гына,
Уйныйдыр зәңгәр кичтә:
Минем туган якларымда
Ай нуры – алтын гөслә.

Җирсегәндә яшь сөртерлек,
Аерылганда болгарлык:
Минем туган якларымда
Ак болытлар – кулъяулык!..

# Ә-ә-әү!..

*Улы яу кырында үлеп калган авылдашым*
*Нүрдидә түти истәлегенә*

Җиләк өсте.
Урман тулы
Бала-чага, карт-коры;
Кычкыра берәү... Бу хәлен
Аңлый алмый аптырыйм:
– Ә-ә-әү! – дип эндәшә, туктый да
Җиләк җыйган җиреннән,
Өзелеп чыга тавышы, –
Чыга бәгырь түреннән.
Кычкыра урманда бәгырь...
Бәгырьгә улы дәшә.
Ядрәдән тишелгән еллар,
Ут капкан сулу аша.
– Ән-кә-ә-әй! – ди бит мескен бала...
Кай төшендә ярасы?
Кайсы яфрак астында син, –
Ничек табып аласы?!
Кара урман уртасында
Җиләклек алан-алан, –
Аланнарга җиләк булып
Кайтыр икән бу балаң!
Кычкыра урманда бәгырь,
Чакыра, улын дәшә.
Хәсрәткә әйләнгән еллар,
Ут капкан сулу аша...
– Ә-ә-әү! – ди дә көрсенә урман...
И урман, туктасана!
Җиләк өсте –
Аланнарда
Карт-коры, бала-чага...

* * *

Басар өчен сагыну-җирсүләрне
Булса икән җирдә, һай, чара! –
Туган Ил ул көзен китеп барган
Кошларны да тартып кайтара.

Читтә яшәгәннең бар догасы –
Туган җирен сагынып әйткән сүз;
Илен җуйган кеше – ярты кеше,
Камил түгел беркем Ватансыз.

Кояшы да булыр, җилләре дә, –
Ил яктысы җитмәс, Ил исе;
Илләреннән мәхрүм булганнарга
И, Җир шарын кочып елыйсы!

Еллар аша, океаннар аша,
Тик бик азга гына булса да,
Кеше җаны, очар кошлар сыман,
Туган оясына юл саба.

Кемгә дәва Ватан, кемгә – яра...
Төзәтәлмәс вакыт арасы –
Илдән киткәннәрнең йөрәгендә
Иле кадәр була ярасы!..

## ДӨНЬЯ ЯРАТЫЛУ

Кайберәүләр Ходай яраткан ди, –
Яралгандыр дөнья белмим нидән?
Тик нигәдер миңа бу тереклек
Башлангандыр сыман безнең өйдән.

Бик күптәннән, әйе, җилләр искән,
Сулар аккан, гомер бара торган.
Минем өчен әмма иң беренче
Әнкәемнең йөзе яратылган.

Яралгандыр аннан бер-бер артлы
Әткәй әрчеп биргән бәрәңгеләр...
Уенчыклар... идән... ишегалды...
Яшел хәтфә урам... аннан өйләр...

Шул өйләрдә елый-елый, миңа
Иптәш булыр уллар-кызлар туган.
Күңелләрне моңга көйләр өчен,
Бакчаларга сайрар кошлар тулган.

Дөнья китек булып калыр иде,
Яратмаса усал маэмайларын;
Без дә кирәк әле дигән сыман,
Чабып килеп чыккан бахбайларым.

Яратыла-яратыла дөнья
Басуларга, урманнарга җиткән,
Күрше авылны бар итәргә җирдә
Авылымның шәп атларын җиккән...

Барып кергән ерак шәһәрләргә –
Еллар узган, гомер бара торган.
Ходайныкын белмим, әмма миндә
Дөнья әнә шулай яратылган.

Яралудан туктамаган дөнья:
Чиге кая хәсрәт-газапларның,
Кеше кайчан кеше булып җитә? –
Табалмыйча йөрим җавапларын.

Учларына башын кыскан кеше –
Дөнья китеклеге яман икән!
Ходай эшләп бетермәгән эшне
Төгәлләргә безгә калган икән...

## КӨЗГЕ ЧАКЫРУ

Урманнарда көзге яфрак исе –
Хушлаша көз... Соңгы хушбуйлары;
Һавалардан безгә чакыру бар:
Күчмә туйлар йөри – кош туйлары.

Сызгырынып сөрән салып уза,
Авылларга кереп, шәһәрләргә –
Һәр күңелнең чиртә тәрәзәсен,
Әйдәкләп җил ерак сәфәрләргә.

Сузылып килә җир өстенә кичләр,
Әллә кая тарта, ашкындыра;
Кыялардан ташланырга әзер –
Яшь кызларның күңеле ташкын гына...

Ышандырмый-нитми генә җирдә
Башларының исән каласына,
Чакыру бар –
Кай тарафка карап
Йөгерәсе адәм баласына?..

# АВЫЛ

Кырык эшең кырылып ятсын,
Тәгәрәшсен кырык балаң –
Кырыгын да эшле иткән,
Авыл берсен онытмаган.

Кирпеч суктык:
Бер-бер артлы
Төшә торды калыплардан –
Безнең ише малайларны
Авыл шулай калыплаган.

Чалгы янап печән чаптык,
Калышсак та күп ирләрдән –
Безнең ише малайларны
Авыл шулай үткерләгән.

Йөгән тоттык, ат өйрәттек,
Сере булган без белмәгән –
Безнең ише малайларны
Авыл шулай тезгенләгән.

Бер мәртәбә күрсәтер дә
Халыктагы бар булганны,
Илгә сөйләп йөрмәс авыл
Ирләр ничек ир булганны...

## АВЫЛ КАРЧЫКЛАРЫ

Карашларың моңсу-моңсу, чәчләрең ак,
Картлык көнең – гомер сөргән җирдән ерак,
Зарыгасың кордашларың хәл-әхвәлен
Авыл якларыннан искән җилдән сорап.

Офыклардан яшь чакларың эзлисеңме,
Урак урган җирләреңдә йөрисеңме?
Иртә таңда ак намазлык өсләрендә
Оеп кына изге теләк телисеңме?

Сабырлыкны Ходаеңнан сорап алдың,
Сабыр савытларың тулса, елап алдың.
Җырларың да сабырлыкка дога сыман –
Җырлый-җырлый эчтән генә сыза бардың.

Өзгәләнсә өзгәләнде – җан чыкмады,
Челтерәп аккан чишмә суын тансыклады.
Таш улакта мөлдерәгән чишмә төсле –
Шәһәр өйләрендә авыл карчыклары...

## АВЫЛЫМ КӨЗЕ

Бүтән инде –
Бакчаларга кояш
Караса да әле җәйгечә.
Студентлар киткән.
Аналары
Ямансулап ялгыз чәй эчә.
Укучылар – мәктәп юлларында.
Этләре дә өрми – урам тын;
Моңсулыкны төтен әллә кая
Алып менеп китә югартын.
Көзнең башы монда – шушы көннән...
Чәй урынын каплап куяр да,
Әнкәң тизрәк бакчасына чыгар,
Яшелчәсен керешер җыярга.
Аннан кырау төшәр.
Су буенда
Оча-куна казлар кычкырыр;
Салкыннардан түгел,
Сагышлардан
Агачларга сары төс керер...
Көрсенер җил,
Чыгар яланнарга,
Кошларыңны тезәр төркемләп.
Сибәр яңгыр,
Юар тәрәзләрне, –
Бер бушаныр дөнья иркенләп.
Җиткән инде көзләр,
Бакчаларга
Караса да кояш җәйгечә:
Балаларын озаткач, аналары
Яшен сөртә-сөртә чәй эчә...

# АВЫЛ ҖАНЫ

*(Поэма)*

Гел башкада иде юкса ният,
Тел чишелгән заман, ниләр язмам! –
Калыкты да ачы төер булып,
Кемдер алды кебек бугазымнан.
Әйтерсең ул көтеп кенә торган
Каләм белән ялгыз калган чагым.
Кемнәргә соң бирәсем бар икән,
Кайсы сорап килгән алачагын?
Танымыйча буламы соң аны:
Тамактагы төер – авыл иде...
Кайтып күреп килгән булгалады –
Карап торулары авыр иде:
Сирәкләнгән өйләр... Өнсез кичләр...
Бала-чага да юк урамында...
Килеп күрешкәне – карт-корыдыр...
Без югында ниләр булган монда?!
Авыл диеп сөйләнгәнбез генә,
Чынында бит аны оныттык без!
Язмышларны кем каргады әле,
Нинди каргышларга юлыктык без?
Тамагымда ачы төер тора –
Танымыйча буламы соң аны?
...Шәһәрдәге таш фатирдан мине
Эзләп тапты авылымның җаны.
Хәтергә бер күз салырга кушты,
Бушатты да тынны аз гына ул;
Элек әнкәй хат яздырган төсле,
Васыятен әйтеп яздыра ул...

Гаҗәп түгел көтмәгәндә болай
Бәреп кереп миңа ду килүе.
Без китсәк тә, онытмады бит ул,
Беренче кат түгел бу килүе.

Җанга шифа өстәп, ераклардан
Кипкән мәтрүшкәләр булып килде;
Әнкәйләрнең безгә бәйләп салган
Оекбашларына тулып килде.
Көнгә ничә тапкыр кесәләрдән
Яшереп кенә алып карый идек:
Авылыбызның җаны кызлар язган
Хатлар эчендә дә бар иде бит!..
...Хәлне белә торды.
Ә без инде
Тар балаклы чалбар киеп алдык;
Кызлар белән – мини юбкалылар! –
Бераз гына «твист» биеп алдык,
Кереп-кереп чыктык ресторанга...
«Шәһәрләшеп» киттек бик тиз шулай.
Килә торды авыл.
Тик кайчакта
Безне инде танымады бугай.
Авыл малайлары булган өчен
Оялганны сизә иде микән?
Әллә инде горурлыкларына
Тимим диеп түзә иде микән?
Йөзебезгә бәреп әйтмәсә дә,
Сыкрангандыр авылымның җаны.
Без, өч көнлек «шәһәр бөекләре»
Ул чагында төшенмәдек аны.

Кайсы мода белән киенсәк тә,
Ташламады безне авыл җаны.
Безнең сыман китеп барганнарның
Яшел чирәм булды авырганы.
Шул көенчә күрермен дип кайтам,
Ничәнче кат инде алданам мин.
Имәнепләр китәм, күрәмен дә
Авылымның җаны калмаганын.
Авыл җаны...

Каян белик ди без
Гади авылның да җаны барын?
Ул турыда кемнәр уйлап торсын
Ташлап киткән чакта авылларын?
Үзебезнең җан кайгысы иде...
Качып китте паспорт булмаганнар.
Бәхетсезлеген дә таба бугай
Читкә китеп бәхет юллаганнар.
Шәһәрнеке булып беталмадык,
Түгел инде авылныкы да син;
Үзеннән һич өстен булмый кеше,
Кая гына кереп укымасын!
Авыл җаны һәрчак безнең белән,
Үзе һаман анда – еракладыр.
Зарыктырмый алып кайтыгыз бер,
Аулыгызның җанын елатмагыз.
Никадәрле генә юатсаң да,
Үзенекен итә, ярсулана,
Зиннәтләнгән сарайларга сыймый –
Шәһәр урамнары тар шул аңа.

Тормыш ямаулыгы табалмыйча,
Аптыраштa калган чакларында
Әйтә иде әнкәй: «Карыйсым юк,
Китсәм әгәр авыл якларына...»
«Олы сүзем көфер китермәсен», –
Дия торган иде бүтән чакта,
Ачыргаланудан исләреннән
Чыгаргандыр инде ул бу хакта:
Тик бер генә түгел, мең карады,
Шул яклардан күзен алалмады;
Шәһәр өйләрендә яшәсә дә,
Күңел белән анда калалмады.
Яше тамды тәрәз төпләренә...
Юатырдай сүзләр дәшәлмәдем.
Белмәдем шул әнкәй кыяфәтле

Авыл җаны монда яшәгәнен...
Ничә еллар авылымның җаны
Безнең тәрәзәдән карап торган! –
Йокыдагы шәһәр өсләренә
Җан яктысын сирпеп, таң аттырган.
Андый сүзләр әйтмәс иде әнкәй,
Белгән булса ни хәлләргә тарысын...
...Җаны шәһәрләрдә тилмергәндә
Авылларның нинди яме калсын?!

Күпме өй урыны...
Елый торгач,
Сукырайган күзләр сыман алар.
Өе исән чакта никадәрле
Күңел нуры, җылы сыйган аңар?!
Нигез саен туктап, һәрбер өйне
Хәтеремдә бүген барлап йөрим;
Үзебезнең монда нинди яра
Салганлыкны хәзер аңлап йөрим.
Ялгыз гына киткән идек тә бит
Туган өйдән чыгып киткән көздә –
Авылыбызны килер буыннардан
Бөтенләйгә мәхрүм иткәнбез лә!
Игелексез ата баласыдай,
Әллә кая китеп олакканбыз;
Сукырайган ана төсле булган –
Авылның бит җанын елатканбыз.
Үзебезнең гаепләрне ялгыш
Бүтәннәргә япсартмагыз тагын.
Синнән-миннән башка кемнәр булсын –
Алучысы бездер авыл җанын!..

Авыл туфрагында ничә гасыр
Үскән гөлебезне алып киттек.
Чит җирләрдә ни көткәнен белми,
Туган телебезне алып киттек.

Алып киткән идек китүен дә...
Саклый алдыкмы соң ул гөлне без? –
Тукай шигырен балаларыбызга
Ничек өйрәтергә юл белмибез.
Мәктәпләрнең тәрәз төпләрендә
Аңа да бит җитәр иде якты! –
Үзебезне-үзебез кимсеткәндә,
Сагына ул гөл авылдагы чакны.
Ата-бабаларның йөрәгендә
Генә йөргән нәфис гөл иде бит...
Авыл кичләрендә сандугачны
Көнләштерә язган тел иде бит!
Алып киттек...
Шундый гөлне хәзер
Бу тирәдә күпләр кирәксенми;
Телен сатып түрә булган –
Аны
Яклап сүз әйтергә йөрәксенми.
Бер гасырлык гыйбрәт алырлык бар
Безнең җыелышларның мизгеленнән.
Башкаларның бер гөле дә хәзер
Өстенрәк синең йөз гөлеңнән...
Гөлебезне күпме саклап булыр
Кыерсыткан чакта этә-төртә?
Күптән корып беткән булыр иде –
Аны да шул авыл җаны йөртә...

Авылларның, хәер, төрлесе бар,
Безнекедәй бары да таралмаган.
Тик алар да инде таланудан
Үз җаннарын саклап калалмаган.
Кемнәр килеп, ничек булдыралса,
Авылларны шулай таладылар.
Кайчагында басу өсләрендә
Бер тыңларлык тургай табалмыйлар.
Без илтифат итмәсәк тә, әллә

Күреп тормый димсез барысын алар.
Берән-сәрән калган чикерткәләр
Сайрамыйлар инде – чаң сугалар...
Табигатьне сөйләп торам тагын,
Кемгә хаҗәте бар, харап булса?!
Хәтәррәкне дә күрер идең,
Күңелләрне ачып карап булса.
Элек болыннарга сыймаган җан
Кысан ихатадан артмый хәзер;
Күршесендә энә артык икән –
Көнләшүдән көеп, шартлый хәзер.
Ут күршеләр...
Ата-аналары
Бер-беренә элек утка кергән.
Инде хәзер черт та кире чыкмас
Урыс капкалардан, юкка йөрмә!
Кунак-төшем, килем-китем бетте,
Бәйрәмнәрне күпләр онытып бара.
Исән микән әле, тибә микән! –
Йөрәгеңне, авыл, тотып кара...

Авылында ул бердәнбер иде,
Калмагандыр гармун кермәгән өй;
Өйләр генә микән? –
Аның тавышы
Кемнәрнең соң җанын телгәләми?!
Кыз-кыркынның йөрәгендә булды,
Сугылып китә иде картларга да;
Бер бәйрәм дә ансыз узмагандыр,
Тынмады ул авыр чакларда да.
Туйлар булса, затлы кунакларның
Гармун иде башлап дәшелгәне.
Ул белмәгән серләр калмагандыр –
Бернәрсәсен авыл яшермәде.
Яшермәде...
Инде кемгә сөйләр

Күңелендә булган моңын-зарын?
Күрсенергә генә калды хәзер –
Яшьләр белән китеп барды гармун.
Сандугачсыз тал шикелле, авыл
Тып-тын гына керә кичләренә.
Күпне күрде.
Әмма бу хәлләрне
Китермәгәндер ул исләренә.
Гармуныннан башка – авыл бүтән,
Төннәр шомлы кебек, өйләр ятим;
Телсез калды җаннар: йөрәк серен
Гармун кебек итеп кемнәр әйтсен?
Бәйрәмнәренең дә яме бетте,
Күңелләрне ачкан – гармун икән;
Авылны син ятим итим дисәң,
Моңнарыннан гына яздыр икән!
Чит җирләрдә йөреп, гармунны да
Инде хәзер телдән калган, диләр.
Тырышса да чыкмый икән аннан
Авылдагы җанга якын көйләр...

Салкыннар да тотып калалмады,
Киртә булалмады явымнар да –
Кирәк-ярагыңа йөгерергә
Базар иде элек авылларда.
Иртә таңнан арба-чана тартып,
Әнкәй белән күпме барган булды.
Оныталмыйсың –
Борының белән бозлар,
Карының белән карлар ярган юлны...
Әллә нәрсә алыр чамабыз юк,
Безгә бары ярты пот он кирәк.
Озак тормый кире борылабыз,
Унбиш көнлек яшәү хакын түләп.
Тормыш кысканына ватылырга ярамаган,
Инде таш идек без;

Арба тартып, ерак базарлардан
Алты җанга гомер ташыдык без.
Атна ялын күпләр көтеп алды –
Базар тулы халык була иде;
Ул чагында иртәгесе көнең
Базарлардан алып була иде...
...Авылларда хәзер базарлар юк.
Белә торып, һаман шунда барам.
Онга түгел инде – ансы җитә,
Ялгыз җирси-җирси, моңга барам.
Алам әле арбам булмаса да,
Төйим әле җанга сыйган кадәр –
Бүген илдә моңсыз калганнарга
Алып кайтып өлгералсам әгәр...

Ак бәхетләр эзләп чыгып киттек...
Алдалаган хыял, аны беләм.
Кереп чумдык шәһәр сөременә
Авылымның ап-ак җаны белән
Заманасы корымланган чакта,
Үзең генә ничек ак каласың –
Керсез җанны кара ялалардан
Ничек итеп саклап апкаласың?
Казлар әнә канатлылар да бит,
Ап-ак булсалар да каралдылар.
Гаеплеләр генә ак көенчә –
Көчлеләргә кара ягалмыйлар...

Кайда гына юктыр авыл җаны,
Төрле якка инде таралган ул.
Авылдашлар һаман китә тора –
Сабый сыман, калмый алардан ул.
Киткән чакта каерылып карый,
Вокзалларда йөри ямансылап;
Урманнарга барып чыкса көзен –
Урман булып урман яна сымак –

Ярдәм сорап безгә кычкыра ул,
Һаваларга менеп сөрән сала;
Гөнаһыбыз шулай зур микәнни? –
Кыр казларын кемдер корбан чала...
Тыпырчына миһербансыз кулда,
Бәргәләнә җаны авылымның;
Син бит аның канатлары идең,
Нигә әле болай каерылдың?!

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Талпынасың һаман, тартыласың,
Авылыңның җаны күккә тарта.
Башларыңа төшкәч, аңлыйсың шул:
Кошлар юлы нигә туган якка?
Кактырмыйча-суктырмыйча гына
Саклап йөртүләре авыр аны...
...Үз-үземә урын табалмыймын –
Кая куйыйм сине, авыл җаны?!

## КУШ ЧИШМӘ

Печән чапты халык, урак урды,
Ашлык сукты ел да шул төштә –
Куш Чишмәдән эчтек.
Нидер кушкан
Кебек иде безгә Куш Чишмә.
Нидер кушкан – колак салмаганбыз.
Бу малайлар нигә тискәре?
Инде минә бер үкенеч йөри
Күңелемдә минем, эчкәре.
Тыңламадык чишмә кушканны без,
Әллә кая китеп олактык;
Әйткәннәрен искә-санга сукмый,
Әнкәйләрне күпме елаттык!
Аптырыйдыр чишмә, аптырыйдыр:
«Ә үзләре миннән эчтеләр...»
Болганып ла беттек бу дөньяда –
Безгә дә бит балчык иштеләр...
Чишмәләрнең рәнҗеше микән –
Ни хәлләргә инде төшмәдек!
Чишмә суы гына эчмәдек шул...
Бигрәкләр дә әллә нишләдек.
Томаланып калган чишмәм елый
Җаннарымда минем, тирәндә.
Нигә тискәредер бу малайлар?! –
Тазартасы минә ирләргә.
Алай сансыз булмас идем сиңа
Урак урган җирдә – шул төштә,
Җаннан беркән бәреп чыгарыңны
Белгән булсам әгәр, Куш Чишмә...

## ЯЗГЫ ХАТИРӘ

...Авыл ачлы-туклы.
Кырда – ачы кукы.
Агач башларында – күкеләр.
Алар ничә кабат
Гомерләрне санап,
Очын очка ялгап үттеләр...

Өзелмәде өмет.
Ачынмаган идек,
Ул кукылар ачы булса да.
Язлар белән килеп,
Сөрән салыр кебек
Яшьтәшләрнең кайсы булса да.

Заманнардан барлап,
Язмышларны ялгап
Йөри микән – күке кычкыра...
– Сиңа күпме, күке,
Кемнәр болай итте? –
Чыгалырсың микән очына!

Чорлар – кара-каршы:
Кычкырадыр кайсы,
Бармы агач моңнар кунмаган?
Искә төшә барсы:
Ачы, бигрәк ачы...
Ә кукылар...
Ә кукылар ачы булмаган!

# ӨСТӘН БИКЛӘНГӘН...

*Әлфиягә*

Өстән бикләп әнкәй эшкә китә.
Синең белән өйдә калабыз.
Бәрәннәр бар тагын –
Яшь ягыннан
Ерак түгел кебек арабыз...

Алар бары сөйләшмиләр генә,
Кимен куймый уен дигәндә:
Ишекле дә түрле чабышабыз...
Ныклык кына бирсен идәнгә!

Ул чак безнең колак яфраклары –
Бәрәннәргә булды имезлек.
Үзебезнең юклык имезлеген
Аларга да байтак имездек.

Тышта берәр тавыш ишетелсә,
Йөгерәләр дәррәү ишеккә,
Сикерәләр,
Бәреп чыкмакчылар
Ишекләрне алар ничек тә...

Эштән кайткач чыгаргандыр әнкәй,
Аналары белән кушкандыр...
Ник соң әле һаман кычкыралар –
Тавышлары ничә кыштандыр?!

Үсеп җитеп таралмадыкмыни?
Кычкыралар нигә иртән үк –
Без бәрәннәр белән гомерлеккә
Калдык мәллә шулай бикләнеп?

Башларыңны орып кычкырсаң да
Чыгып булмас: өстән бикләнгән.
Бәлки, ачар иде –
Әнкәй дә бит
Кире кайтыр җиргә китмәгән...

Сукыр күздән яшь чыгасы, диләр,
Чынлап торып әгәр еласа.
Юк, еламыйк, сеңлем,
Юл тапмасмы –
Җырлап карыйм әле булмаса...

## АРЫШ БАСУЫНДА

Кыштыр-кыштыр арыш башаклары...
Күзгә яшьләр килә кайчакларны,
Басуларга чыксаң ялгызың.
Уraклары тынган әнкәйләрнең...
Шул малайга бер сүз әйталмадым,
Сослан төпләрендә калдырдым.

Арыш арасында – зәңгәр чәчәк.
Дәшәлмичә тора җилдә чәчәп,
Төсмерләдем шундук, таныдым:
Юк, кермәгән иде искә бер дә
Басу уртасында чәчкәләргә
Әйләнәсе сабый чагымның.

Арыш башаклары пышылдаша...
Искән җилгә алар кушылмаса,
Бу чәчкәне кемнәр юатыр?
Башлар чайкап, хәлләреңә кереп,
Синең өчен саргаядыр кебек:
Басуларга чыксаң, уй артыр...

## ПЕЧӘН ЧАБУ

Чалгы тотып яланнарга чыктым...
Үлән өсләренә чыклар яткан.
Печән чабу – теле авылымның,
Сагындырган икән, тансыклаткан.

Бер тамчы да онытылмаган ул,
Җиңел аңлашыла, сүзләр нигә?
Изүемне чишеп, чалгымны бер
Элеккечә янап җибәрим дә,

Сөйлә миңа, авыл, моң-зарыңны,
Читкә китеп беткән кызларыңны.
Селтәним дә, ялан түрләреннән
Каерып алыйм әле узганыңны!

...Әткәй печән чапкан җирләр бит бу,
Яланаяк йөргән яланнарым...
Үлән өсләрендә чыклар җем-җем –
Энҗе булып калган заманнарың.

Печән чабу – теле авылымның:
Ала кыеп, җиргә егып сала.
Мин үзем дә беләм гаебемне,
Чыраема берүк бәрмәсәнә!

Алдымдагы пакусымны чыгып,
Чалгымны бер янап җибәрим дә,
Уйларымны селтәп ташлыйм әле
Кендек каным тамган җирләремә.

Бу туфракта без бит җиләк идек,
Тансык идек аңа, кирәк идек.
Суырып алып киткәннәр шул инде –
Туган җирдә без бит йөрәк идек!..

Үлән өсләрендә чыклар җем-җем...
Элек белмәгәнбез – хәзер белдем:
Үткәннәргә чумып алалмыйсың,
Төпләренә төшеп киткәч энҗең.

...Чалгымны бер янап җибәрим дә,
Хәсрәтләрем минем монда сеңсен.
Гаҗизлектән иза чиккән җаннар
Туган туфрагының телен белсен!

## ШУНДА, АГАЙ!..

*Татарстанның халык артисты –*
*авылдашым Наил Әюпкә*

Гомер буе яңгырарлык итеп,
Бер җырладың Түреш урманында.
Үзәк өзеп ишетелер икән
Урманнары киселгәннән соң да!

Күптән билгеледер:
Бу халыкта
Балта уйнамаган җирләр сирәк.
Алтыдагы көйне алтмышкача
Саклап илтә алыр ирләр кирәк!

Шунда, агай, милләт урманында
Замананың ботарланган төше.
Бөтенләйгә шунда кала икән
Ул урманда бер җырлаган кеше...

## «МИЧ» ЯНЫНДА

Бер биюче булган:
Биеп китә
Алган, имеш, мич яныннан гына...
Каләм тәртелгәндә мин дә кайтып
Егыламын туган туфрагыма.

Яшел чирәменә егыламын...
Үзем кайталмасам, җаным кайта:
Тып-тын гына керә урманнарга...
Сизә йөрәк...
Бар илһамым кайта!

Елга ничә урый торганмындыр –
Исәпләре генә исемдә юк.
«Биеп» китәм шулай...
Ә бит юкса
Ул авылда инде мичем дә юк!

Миче булмаса да, уты яна...
Үзәкләргә үтеп яна уты!
Судан алып, утка сала икән,
Сала икән беркөн анаң йорты...

## МӨСЛИМ КӨЗЕ

Офыклардан офыкларга кабынып,
Ык буена керә Мөслим көзе.
Шушы якның кешеләре сыман
Колачы киң аның, ачык йөзе.

Алларыңа синең тып-тын гына
Хәтфә паласларын җәеп сала.
Дәвер төпләреннән бәреп чыккан
Чишмәләрен авыз итми кара!

Әрәмәдә балан каршы ала,
Бүген монда киләсеңне белеп.
Сине чакыргандай, җил сызгыра,
Әби чәчле тауларына менеп.

Күренеп тора: җаннардагы җылы
Кибән-кибән икән, эскерт-эскерт.
Бер яктырыйм дисәң, Мөслимгә кил:
Күптән белә моны күрше-күкерт.

Каеннарга килеп сарыладыр
Өрфиядәй җиңел Мөслим көзе.
Шушы якның кешеләре сыман
Колачы киң аның, ачык йөзе...

## САБЫЙ ЧАКТАН БЕР КҮРЕНЕШ

...Усак яфраклары лепердәшә.
Кечке кояш нуры. Кемдер дәшә...
Онтылган да булыр иде инде,
Сабый хәтер шулай сеңдермәсә.
Иң беренче истә калган мизгел...
Күптән төтен инде усаклары,
Әллә кайчан таралгандыр җилдә...
Һай, бу гомерләрнең шул чаклары!
Усак яфраклары лепердәшә –
Ишетелә төтен арасыннан.
Сабыр гына карап ята дөнья
Без янганны,
Сабый бала сыман.
Кечке кояш нуры...
Иртәнгесен,
Карап тормый-нитми, илгә чәчтек.
Илгә түгел бугай, җилгә китте, –
Әллә исәрлек булды, әллә яшьлек.
Кемдер дәшә...
Газиз башкайларның
Кайда яшәгәнен белә бит ул!
Эндәш аңа,
Кыл өстендә чакта
Яннарына тизрәк кайтып котыл...
Иң беренче истә калган мизгел.
Яндыралмадылар бу рәсемне!
...Бишегемдә чактук күрсәткәннәр
Гомер буйларына күрәсемне...

## КАЙСЫГЫЗ?

...Кәккүк, чыпчык,
Тәрәзәдән очып чык...
*Бала уйнату*

Тәрәзәдән очып чыкмады ул.
Белалмадым каян килгәнен:
Пыялага бәрелде дә чыпчык,
Егылып төште...
Тагын кемнәрнең
Хәбәрләрен алып килүедер...
Илдә чыпчык үлми иде дә,
Нинди гөнаһ шомлыклары икән,
Ни булды соң әле иленә?!
Илдә чыпчык үлми иде дә бит,
Кырылса да асыл ир-аты.
Башкайларын юкка ташка ормас –
Шул кошларда мәллә чираты?!
Пыяланы ваталмады мескен:
Чыпчык кына бит ул димәгез,
Кемнәр өчен шушы чыпчыклардан
Кадерлерәк әле илдә без?
– Кәккүк, чыпчык, – диеп, кулларында
Сикертерләр инде ул кемне дә.
Каян белсен сабый болай да бер
Калачагын чыпчык көненә!
Тәрәзәдән очып чыгасы юк,
Алданмагыз, кире кайтыгыз!
...Танымыйча калдым:
Пыяланы
Ваталмады бүген кайсыгыз?!

## КИЛӘ ДӘ КАРЫЙ БЕР МАЛАЙ...

Кышкы кич җирне учына
Йомарга әзерләнгән.
Килә дә карый бер малай
Бәс сарган тәрәзәмнән.

Күзенә төшкән бүреген
Күтәреп куйган була.
Яныма чакырыйм дисәм,
Тышта тик – буран гына...

Юк, тышта гына түгелдер,
Җанда да буран икән,
Теге малайны сизми дә
Җитәкләп торам икән!

Саламга барган җиреннән
Елларга уралгандыр.
Салам түгелдер,
Ул чакта
Гомерләр урлангандыр.

Мәңге эзлисе икән бит
Югалган малайларны! –
Кышкы кичтә әллә шулар
Тәрәзәң кагалармы?

Таныла алар барыбер,
Таныла, чамалана.
Килә дә карый бер малай, –
Керт аны заманага!..

## ҖИЛ ДӘ БАР

Замананың тыны кысылганда,
Сабый чакларымнан җил бәрә,
Нарасый җил...
Авыл хатыннары
Анда һаман ашлык җилгәрә:

Агач көрәк белән бер-бер артлы
Һаваларга бодай сибәләр,
Моңланалар...
Минем җырда гына
Калганнарын, ахры, сизәләр.

Шыбыр-шыбыр ашлык ява күктән,
Чәчләремә тула бодайлар,
Дәфтәремә тула...
Шөкер, димен,
Теләк теләгәнгә – Ходай бар!

Нарасый җил...
Бәндәләргә карап,
Җилләр әле нигә картайсын?!
Без дә картаймабыз:
Дәверләрнең
Игелеген кире кайтарсын...

...Анда һаман ашлык җилгәрәләр,
Белмиләрме – монда зир-зәбәр.
Бөтенесе үзебезнең башка!
Җилгәрмибез –
Юкса җил дә бар...

# КЫРЫНТАУ

Алмагачлар безне аңламаслар...
Юатмакчы булып, Сентябрь
Ятим калган алмаларның яшен
Сары кульяулыкка сөртәдер.

Бу заманда шигырь нигә кирәк,
Язма, диләр...
Ничек язмыйсың? –
Таулар кырын түгел икән лә бит,
Түгел икән... Кырын – язмышың!

Быел монда сабантуйлар узган,
Авылы юк... Туе... туе бар!
Бер авылның гына язмышымы?
Халкы исән икән – уе бар...

Алмаларга ничек аңлатасың,
Кешеләрне, илне, дөньяны?!
Алдадылар...
Алар берсе дә бит
Алмалардай ихлас булмады.

Хуш, Кырынтау!
Моңсу кульяулыгым –
Язганымны биреп калдырам:
Баш очында бер болгарсың, бәлки,
Сабантуйлар булыр алдыннан...

# ЙӨРӘК АТЫМ

*(Поэма)*

Ирләр йөрәгендә иярләнгән
Атлар ятыр...
Әй ул атларны! –
Ир-егетнең газиз башкайларын
Кая гына алып чапмады?!
Бәйгеләрдә, юлда, көрәшләрдә
Ирләр белән бергә ат булды,
Уттан-судан алып чыкты атлар...
Халык әйткән икән – хак булды.
Гасырларны бергә кичкән чакта
Йөрәкләргә күчкән атлардыр;
Атсыз калмасыннар –
Ул атларга
Улларыңны инде атландыр,
Ялларына ныграк ябышсыннар –
Ир намусы табыла иярдә...
...Атлы йөрәк белән яшәр өчен
Ныклык бирә күрсен ирләргә!..

Тик кайдадыр бер ат ярсып кешни...
Чабып йөри дөнья буйлатып,
Үткәннәрне айкый, киләчәкне,
Уйларыңа керә уятып,
Тынгы бирми... –
Кайсыгызны аты,
Кемнәр әле атын югалтты?
Арлы-бирле тояк тавышлары...
Йөгәнлисе ничек шул атны,
Иясенә ничек кайтарасы? –
Ир йөрәге атсыз торалмас;
Аттан башка нинди ир-ат булсын,
Нишләсен ул аты югалгач?
Кемнең аты шулай кешни икән? –
Тукталып бер колак салыгыз:

Сезнең ат түгелме? –
Танысагыз,
Җырларымнан килеп алыгыз...

Их, кайчакта җилдерәсе килә...
Тик... атым бар диеп алданма.
Исемебез генә ир-ат безнең,
Күптән инде атсыз калганга.
Атсыз гына гомер кичерәбез,
Каян килсен безгә ул атлар? –
Аты барын, хәллерәген ирнең
Сөргәннәр ич бер кат еракка...
Ә колхозга аты белән бергә
Ярты җанын биргән бабаңнар;
Бу җансызлык каян килә димә –
Шул чакта ук тартып алганнар...
Ирләр шулай атларыннан язды.
Үги хәлдә инде атлар да.
Ирләр җанын юксынадыр төсле
Нәселләрен җуйган чаптарлар.
Илдән язуың да ерак йөрмәс,
Башың иеп һаман тик торсаң –
Ат күрмәгән адәм актыгының
Кулларына тезген тоттырсаң...

...Әүвәл җигү атың...
Ә аннан соң,
«Дошман» ясап сине халкыңа,
Үрелгәннәр
Суырып алыр өчен
Йөрәктәге соңгы атыңа.
Соңгы атың...
Йөрәк – абзар түгел...
(Андыйлар да, хәер, табылган!)
Төрмәләрдә сыгып чыгарганнар
Атларыңны синең каныңнан...
Кайбер ирләр кайтты,

Ә атлары...
Ә атлары инде кайтмады.
Кай якларда калды икән алар? –
Их, атларның кирәк чаклары!..

Атларның ла кирәк чаккайлары –
Атсыз яшәп, бигрәк вакландык.
Утырдык соң кемнәр чанасына,
Ишәгенә кемнең атландык?!
Ничә еллар кеше җырын җырлап,
Үз җырыбыз оныта язганбыз;
Телне тешләп, дәшми яши торгач,
Телсез калмаганбыз аздан без...
Ирләрдә соң ат хәстәремени? –
Урындыгы булсын, «Волга»сы;
Йөрәкләрне... кесә алмаштырды –
Ник аларга дөнья кайгысы?!
Илең, телең ник чәнчелми шунда –
Калынайсын бары кесәләр;
Өстән фәрман булса, урманың да,
Иманың да тотып кисәләр...
Болыннарсыз, чишмәләрсез калдык,
Шундыйларга тезген тоттырып;
Теләгәнчә типтерделәр алар,
Хакыйкатькә хәмер йоттырып...

Ничек итеп атсыз калдык соң без –
Кемнәр аны ябып тоталар?
Кайчан гына әле әткәйләрнең
Йөрәгендә иде бит алар!
Йөрәкләре ат кадәрле булган,
Сугышларга кергән чакларны.
Күпләр кайталмады...
Әткәйләрнең
Җиккән килеш калды атлары...
Тик ул атлар якын җибәрмиләр
Үзләренә, хакың булмаса;

Ир-ат исемен ничек йөртмәк кирәк,
Йөрәгеңдә атың булмаса?!
Булыр-булмас иргә атлар нигә? –
Яши бирә алар атсыз да:
Эткә сөяк бетеп торамыни,
Җай табыла һәрчак оятсызга.
Түбәнлеккә төшәр өчен атлар
Кирәк түгел, ансын беләбез.
Ата-бабаларның йөрәк атын
Югалттык соң әле нигә без?
Канат булыр атлар кирәк бүген,
Кичәр сулар, менәр үр кирәк,
Ир-ат исмен йөртеп,
Йөрәгенә
Атлар сыйдыралыр ир сирәк...

Ат эзләгән булды үсмер чакта:
Югалсалар, табылдылар да.
Ә боларын каян эзлисеңдер –
Таралганнар алар елларга.
Ишетелә кешнәүләре генә,
Аерылганнардыр кемнәрдән?
Мин шуларны эзләп таң аттырам –
Табылырлар сыман төннәрдән.
Берәм-берәм барсын күрәм кебек:
Ятим атлар... мескен... кызганыч...
Ни үкенеч – кайчан гына алар
Ирләр йөрәгендә булган ич!
Әнә Сибайныкы... –
Тик хуҗасы
Яла ягып илдә көн күрде.
Шул йөрәктә атлар ничек торсын:
Ил битенә аның төкерде!
Гатаныкы... –
Башта әсирлектә
Кешелеген аның ектылар;
Илгә кайткач, торалмаслык итеп,

Яңагына кабат суктылар... –
Әнә Сабир аты... –
Туры ярды,
Түрәләргә ярый алмады,
Сындырдылар... Инде ахыр чиктә
Эчкечегә башын салганы...
Атлар, атлар...
Алардан да бигрәк
Миңа бүген ирләр кызганыч.
Кайчан гына әле бу ирләрнең
Йөрәгендә атлар булган ич!
Аягүрә калу җиңел түгел,
Дүрт аяклы ат та абына;
Абынса да, аягына баса,
Эзләгәнгә терәк табыла.
Намуслары тапталганнар күпме:
Әмирҗаннар, Нәҗип, Булатлар!
Атлар исән булса,
Йөрәкләргә
Бер кайтырлар кебек ул атлар...

«...Кара да гына урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә...»
Карурманнар аша алып чыккан
Җыр-атлардан башка нишләргә?!
Илендә бер аты калмаганда
Алмаштырды җырлар бар атны.
Ат тарталмас кайгы-хәсрәтләрне
Җыр күтәрде, җырлар таратты.
Авыр чакта гына кирәкме җыр? –
Сирәгрәк һаман җырлыйбыз.
Сылтауларга сынык табылыр ла ул:
Сәбәпчесе – заман, чор дибез.
«Рок»лар да булыр... өрәкләр дә –
Бирә килсәң әгәр йөрәкне;
Хәмер генә җырлатканмы бары
Моңа кадәр әллә ир-атны?

Җыр-шигырьне санга сукмасак та,
Исерткечнең базар югары.
Ата-бабаларның бу хәтле үк
Түбән төшкән чагы булмады...
Ничек болай юлдан язганбыздыр –
Адашып ла беткән чакларым,
Чыгар өчен мондый «урман»нардан
Яхшырагы кирәк атларның!

Канатланып сөйгәненә очты
Ир-егетнең атка менгәне;
Мәхәббәтнең сизгер ак атлары
Кавыштырмагандыр кемнәрне?!
Очты атлар...
Далаларны кичте...
Айлар-еллар аша сикерде –
Тик сөюне җиргә төшермәде,
Йөрәкләргә илтеп җиткерде;
Еракларда карашлары белән
Тартып алды зарыгып гашыйк күз.
Мәхәббәтнең сизгер атларына
Атланалмый калган – бәхетсез...
Беркем аңа йөгән кидералмый,
Билләренә ияр салалмый;
Бу атларны инде бер югалткан –
Кабат мәңге эзләп табалмый.
И... алар бит сөя белгәннәрдән
Сәлам генә алып бармаган:
Туфаннарның җанын Луизалар
Үз каннары белән ялгаган...
Гомер буе бер-беренә илтә
Ул бары тик сөю хакына –
Маташмагыз камыт кидерергә
Мәхәббәтнең сизгер атына!..

Аттан башка кыен яшәүләре,
Кирәк икән бит ул кемгә дә.

Кайчагында була икән атлар
Хатын-кызның йөрәгендә дә...
Өелешеп ятим калганнарны
Өметсезлек, кайгы-моң баса –
Ничек итеп алып чыксын әнкәй
Ул чаклардан, аты булмаса?!
Колхоз эшен тартты... Хуҗалыгын...
Киндер сукты... –
Ат та чыдамас!
Аңа нәрсә кала –
Авырлыктан
Авылында ирләр елагач?..
Исләреңә төшсә – искитәрлек,
Өскә килсә – сынсыз калырлык;
Бераз гына бездә булса икән
Әнкәйләрдә булган сабырлык!
Алардагы тезген безгә калды,
Йөртеләбез күптән ирләр дип.
Тик каян соң, чебен тимәс борын,
Чер итәргә болай өйрәндек?
Җае килгән саен зарланабыз,
Авыр, дибез... Чорны сүгәбез...
Чынлап торып күтәргән юк әле –
Авырлыгын каян беләбез?!
...Ирләр арасында йөрим бүген,
Ирләр табалмыйча аптырап.
Яман икән атсыз яшәүләре –
Ирләр йөрәгенә ат кирәк!
Әнкәйләрдән генә алып кайтыр
Идем дә бит, әгәр юл белсәм...
...Йөрәккә тик атлар кирәк микән,
Хатын өчен генә ир булсаң?!

Бездә ирләр ат өйрәтә иде,
Җәй көнендә җигеп чанага.
Кара җирдән чана өстерәгән
Тайның хәлен үзең чамала...

Нинди хөрлек калсын ул атларда,
Телләре юк – ничек сөйләсен?
Каян белсен ирләр шундый хәлнең
Үз башына беркөн киләсен.
Ни таксалар, шуны өстерәргә
Атлар түгел, без дә өйрәндек;
Тышаулап та җибәргәләделәр –
Ис китмәде, булса чирәмлек.
Ашатсалар әгәр, эчертсәләр,
Бу дөньяда тагын ни кирәк? –
Тибүләрең, җиргә килүләрең
Шуңа идемени, их, Йөрәк!
Синең мескенлектән бабаңнарның
Изге рухы сыкрап яткандыр...
...Тышау чишәр ирләр калган икән –
Атларыңа сикереп атлан бер,
Ыргыл бәйгеләргә,
Ирексезләп,
Җәй көнендә чана җиккәнче!
Туктый күрмә, халкың көтеп торган
Мәйданнарга барып җиткәнче...
...Атымны мин еллар буе эзлим,
Нинди ир ул – аты булмаган?!
Атсыз-нисез, исе китми генә
Яши алыр – ояты булмаган.
Йөрәкләргә кереп ятар чакта,
Колын гына иде ул атлар;
Югалтканың инде – аргамактыр,
Кем кичерер сине, кем аклар?
Ир-ат исмен йөрткәннәргә бүген
Атларының җанын тояр чак.
Атың синең ат шикелле икән –
Киртәләрен бәреп чыгачак!
...Ирләр йөрәгендә иярләнгән
Атлар ятыр... – Кая атыгыз?
Йөрәктән дә кирәклерәк чагы –
Атыгызны алып кайтыгыз!..

# VI. Әнкәйгә кайту

...Әнкәйләрнең бәгырьләре
Тулы кош балалары...



* * *

Озак үстек микән бу яшькәчә,
Безне назлап күпме җыр көйләнгән? –
Керфек какмый бишек тирбәтүче
Әниләрдән сора, әниләрдән.
Авыр микән озатучыларга
Без киткәндә юлга бу өйләрдән? –
Кинәт кенә кечерәеп калган
Әниләрдән сора, әниләрдән.
Кешегә күпме өмет багланадыр,
Нинди ышаныч аңа күңелләрдә? –
Ил язмышын сиңа тапшыручы
Әниләрдән сора, әниләрдән!..

* * *

Күзеңнән моңсулык сирпелә
Чәчеңдә – кыраулар, ахрысы.
Синдә дә салкын көзмени соң?
Йөзеңдә яфраклар сарысы!

Үстереп озаттың кошларны, –
Туган як шикелле син, әни!
Көн буе агыла болытлар,
Синдә дә яңгырлар сибәли...

Алтынсу яфраклар ияртеп,
Урманнар аркылы җил килә:
Әйтерсең ашыгып бу якка
Синдәге сагынуны китерә.

...Озаткан кошларны көтәсең, –
Туган як шикелле син, әни!
Синдә дә көзге җил тузына,
Көн буе яңгырлар сибәли...

* * *

Тын белән җылыталармы,
Куенга салалармы –
Әнкәйләрнең бәгырьләре
Тулы кош балалары!

Очыралар еллар буе,
Озаталар берәм-берәм,
Мең төрле бәла-казадан
Йолачак дога белән.

Кала беркөнне ялгызы
Буш оя, ятим оя;
Килә дә көзге болытлар,
Сагышын, яшен коя.

Сулкылдый ана йөрәге:
– Күшекмәделәр микән?.. –
Җилләргә биреп җибәрә
Актык җылысын бу җан...

...Елларга тараларлармы,
Егылып калалармы? –
Әнкәйләрнең бәгырьләре
Тулы кош балалары...

# КАЗЛАР ЭЗЛӘҮ

*(Бәет)*

Әнкәем бит бер дә болай
Булыр димәгән иде,
Кичен казлар эзләргә дип
Кенә җибәргән иде:

Төштем дә су буйларына,
Югалдым үзем дә мин.
Кибеп беткәнмендер инде
Әнкәйнең күзендә мин.

Кайталмыйча йөрим өйгә,
Казлар эзләп мин һаман:
Кычкыралар еллар аша –
Бер югалтам, бер табам.

Очып китәләр җыр булып,
Тыңламый казлар мине –
Әнкәемә, зинһар, укып
Бирерсез язганымны!..

* * *

Син бит, әнкәй, мәңгелектә
Күпме генә кунак булдың?!
Кунак түгел – җир йөзенә
Бераз күз һәм колак булдың.

Без белми дә калдык бугай –
Ни ишеттең, ниләр күрдең:
Бөтенесен йөрәгеңә
Төйнәдең дә – гүргә кердең.

Инде менә минем нәүбәт:
Җирнең күзе, колагы мин;
Синең сыман эчкә йотам
Күз яшемне, еламыймын.

Әле ниләр күрмәссең дә,
Ишетмәссең ниләр генә!
Җир күзләре булу кыен
Икән кеше йөрәгенә...

Кош тоткандай сөенеп йөрдем ул чак
Бүрек белән каеш калганга.
Әткәй үлгән көнне язмыш мине
Иске каеш биреп алдаган.

– Итеген дә мин киярмен инде,
Чикмәне дә ярар көзләрен... –
Ничек, әнкәй, шул сүзләрем өчен
Телемне син тартып өзмәдең?!

– Улым, улым!
Әткәң исән булса,
Каеш кына тапмас идеме? –
Каһәрләдең шунда язмышны син,
Ләгънәтләдең әрсез үлемне.

Бүрек белән нужа кидем башка,
Каеш белән будым кайгысын –
Алары да миңа калган икән,
Минем гомер, минем җан өчен...

# КӨЙ

Яргаланып беткән кулларыңда
Таныш орчык таныш көй суза;
Агып барам мин дә шул көй белән, –
Моңда эреп, тагын кич уза.

Малай чакның һәрбер сөенече
Шул көй белән тыгыз бәйләнгән;
Ничә тапкыр аның аша безгә
Көлмәк булып килде бәйрәмнәр...

Ничә тапкыр салкын кышлар чыктык –
Шул көй белән йөрәк җылынды;
Үткәрдең син гади орчык аша
Безгә дигән бөтен җылыңны.

Бөтер әле, әнкәй, орчыгыңны –
Борчуларын җанның урласын;
Җебең белән бергә суза-суза,
Җырларымны үзенә урасын.

Яргаланып беткән кулларыңнан
Йөрәгемә изге көй тама:
Бөтерелә, уйный таныш орчык –
Бәйрәм булыр кебек иртәгә...

# ШЕЛТӘ

Инде күпме шелтәләде язмыш.
Ә күпмесен әле татыйсы!
Җуелмыйча хәтеремдә йөри
Шелтәләрнең иң-иң катысы.

Әйтерсең лә җанга уеп язган
Һәр хәрефен аның, һәр юлын,
Ялгыштыммы – ул сызлана башлый,
Каный башлый кинәт:
– Их, улым!

Үтәлмәслек упкын пәйда була,
Мин бутасам әгәр уң-сулым;
Сискәндерә ачынулы тавыш,
Сыкранулы тавыш:
– И-их, улым!

Хыянәткә барсам, тау ишелер,
Нәкъ урталай ярылыр бу болын,
Имәннәрне давыл йолкып ташлар,
Барысы бергә дәшәр:
– И-и-их, улым!..

# КАЗ КЫЧКЫРА

*(Әнкәм сүзләре)*

Шәһәргә дә күнегелде бугай,
Авыл хәзер – бары истәлек.
Тик җанымда менә каз кычкыра,
Кычкыра каз... Куям сискәнеп.
Гомер иткән ала казым калды,
Сизгәндерме минем китәсен:
И кычкырды җан ачысы белән
Шул язны ул кичен-иртәсен.
Ничә оя бәбкә үстергәндер –
Авылда бер үрчем каз иде;
Каңгылдашыр-куанырлар иде,
Ишегалды тулы наз иде.
Һәм... өй тулы нарасыйлар иде –
Сыңар канат ничек күтәргән?
Казлар белән бергә очып үттек
Кара болыт баскан күкләрдән...
Каз кычкыра...
Мескен ала казым,
Әллә оча, әллә куна ул, –
Казаннарга кадәр ишетелә...
Ничек түзә икән бу авыл?!
Казлар булып чыгып кычкырсаң да,
Бетмәс, ахры, җанда гаҗизлек:
Һаваларны ярып очып килә
Авыл якларыннан газизлек.
Без киткәнгә унбиш еллап инде,
Хәзер авыл – бары истәлек.
Тик җанымда менә каз кычкыра...
Кычкыра каз нидер искәреп.

# ӘНКӘЙ ҖЫРЛЫЙ

Бәнем хәлем кеше белмәй,
Яна бәгърем – уты сүнмәй;
Йөри чак сөлдәрем* генә
Сарыга саташып үлмәй...

*Әнкәй җырыннан*

Әнкәй җырлый, җитмеш яшьлек әнкәй...
Җитмеш җилне бергә кузгата,
Еллар арасыннан күтәрелә
Очар кошлар...
Җиргә моң ята.
Җитмеш яктан атлар чабып килә,
Җитмеш язда – җитмеш сандугач;
Җитмеш җирдә җитмеш учак яна –
Җанга ничек утлар кабынмас!
Әнкәй җырлый, җитмеш яшьлек әнкәй...
Яфрак ява җитмеш агачтан;
И бу җанның бетмәс сагышлары! –
Урманнарга кереп адашкан...
Җитмеш яшьлек әнкәй...
Бәгырь җыры
Җитмәс җиргә җитеп юата;
Әнкәй җырлый, ап-ак чәчле әнкәй, –
Моң тарала дөнья буйлата...

---

* Сөлдәр – җаны чыга алмыйча йөргән мескен гәүдә мәгънәсендә.

* * *

Кайгырдың син, әнкәй, авырсак та,
Сызланасың – безгә авыр чакта.
Эчтән сызарыңны белеп торам,
Без ялгышып, беркөн абынсак та.

Керфек какмый чыккан төннәрең бар,
Ут йотып ла узган көннәрең бар;
Саргаясың тәрәзәдән карап –
Кай җирләрдә тагын кемнәрең бар?

Көенәсең җирдә хәсрәт барга, –
Агыласың гүя болытларда.
Тамасыңдыр көйгән иреннәргә,
Инде сулып барган минутларда...

Гаҗиз идем газап чиккәнеңә –
Чит кайгыдан яшьләр түккәнеңә.
Төшендем мин: безгә генә түгел,
Бар дөньяга ана икәнеңә!..

# ЧӘЧӘК АНАСЫ

Сары чәчәк – чәчәкләрнең анасы,
Бар икән бәгырьләремнең янасы!..

*Әнкәй җырыннан*

Янды...
Янды...
Янды гомер буе!
Сизгәндерме бала чәчәкләр?!
Барысын утка, утка сала барды,
Килгән чакта кайгы-хәсрәтләр.
Бозлар яуды – ул каплады иелеп,
Имгәнсә, тик үзе имгәнде;
Кояш булды –
Бала чәчәкләргә
Белдермәде Кояш сүнгәнне...
Янды...
Янды...
Кайчак көлгә калды:
Әй, язмышлар – сабыр чәчәкле!
...Дөнья тулы чәчәк балалары –
Өзмәгез лә сары чәчәкне!..

* * *

Менә син дә дөнья куйдың, әнкәй –
Бала түгел инде мин бүтән...
Кулларыма алдым, иңнәремә,
Уйларымда сине тирбәтәм.

Кайгы-хәсрәтләрең белән бергә
Алып киттем сине күтәреп,
Гомерем буйларына йөртер өчен...
Рәхмәт, әнкәй, көчем җитәрлек:

Бөтенесен синнән алдым бит мин,
Сабыр булсам – синең сабырлык;
Синнән килгән моңнар бар дөньяның
Сагышларын сыйдыралырлык.

Алып барам, әнкәй, алып барам,
Иңнәремә салып, җаныма:
Куйсам сине, куялырмын бары
Үзем дөнья куйган чагында...

## ӘНКӘЙНЕҢ АК САМАВЫРЫ

Без үскән чаклардагыча,
Үзгәрмәде һаман җыры:
Бакчамдагы өйнең яме –
Әнкәйнең ак самавыры.
Тирәсенә тезелешеп,
Күпме чәйләр эчелмәде!
Ишек ачык булды һәрчак,
Нинди кунак төшермәде...
Балкып каршы ала иде
Әнкәйнең ул үзе кебек:
Кешегә йөз итим диде,
Авызлардан өзсә өзеп.
Ачык чырай булды аның
Хәзинәдән иң зур сые;
Ашка җыйды бәйрәмнәрдә –
Авыл түгел, еллар сыйды...
Көнгә ничә куелгандыр –
Санамадык, исемдә юк.
Әнкәйнең ак самавыры
Үзе балкый – эчендә ут...
Әнкәйләр бер китә икән,
Безгә кала самавырлар;
Эчләрендә ут булмаса,
Алар ничек яңарырлар?!
Бакчамдагы өйнең яме
Ак самавыр – әнкәй төсе:
Тирәсенә җыя безне
Әле дә ул аның төсле...

# КАПКА БАГАНАСЫ ТУРЫНДА БАЛЛАДА

*Әнием – Бибидөррия Әхмәтвәли кызы истәлегенә*

**1**

...Ишегалды, урам тула иде
Язын сыерчыклар тавышына.
Ел да килеп оялады алар
Капка баганасы куышына.
Язгы сыерчыклар сайравында
Нинди моңнар иде без белмәгән?
Дәшми иде капка баганасы,
Аңа сөйләр хокук бирелмәгән.
Күпне күргән имән баганалар...
Сыерчыклар нигә сайлагандыр?
Бәлки, алар ул капкаданниләр
Кичкәнлеген чыгып сайрагандыр...

**2**

...Хәзрәтнең хуҗалыгы янды.
Билгеледер уттан ни каласы:
Күмерләнде, янып беталмады
Капкасының ике баганасы.
Указ алган елны утыртылган
Таза имән баганалар иде.
Янды дөнья...
Барып сөялергә
Шулар гына бары калган иде...
Эче-тышы ялкын хәзрәтнең,
Янды һаман, янды – сүнмәде ут:
Синдәйләргә илдә көн беткән чак,
Егыласы икән кемгә барып?
Яна икән, ахыргача яна,
Хәсрәтләр капкач чал башыңа!

...Ташламады халык, кулын сузды,
Хөрмәт күрсәттеләр чалмасына.
Күченәсе итте Яңавылга.
Гаиләсе...
Тагын ни аласың? –
Казып алып китте капкасының
Күмерләнгән ике баганасын...

## 3

Иске багана да ярап тора,
Аягыңнан сине нужа екса:
Агарып ук беталмасалар да,
Терәк булды алар хуҗалыкка.
Ары чапты хәзрәт, бире чапты,
Бөтенесе кирәк яңабаштан;
Ат та юнәт, сыер-сарыгын да,
Кем карасын, үзең карамасаң?
Дин юлынмы, яңа нигезнеме –
Кайсын берсен генә кайгыртасың?
Намазы да калгалады кайчак,
Бер Ходаең үзе ярлыкасын!
Билен бөкте бөтен гаиләсе,
Баганалар барсын күреп торды:
Капка аша һич кермәде хәрәм,
Хәләл тапкан гына йөреп торды.

## 4

Барсын күреп торды баганалар...
Язмыш тагын шул капканы какты,
Авылның бар ярлы-ябагае
«Кулак» дигән кара исем такты.
Куып чыгардылар үз өеннән
Хәзрәтне.
Бер ялкавы күчте.

Атын җикте эштән чыгарганчы,
Сыерын да шулар савып эчте.
Күпне күргән баганалар иде...
Кызыллар да булды, аклары да.
Тик берсе дә болай кул сузмады
Хәләл көче белән тапканына.
Теге хөрәсәннең кысан өе
Хәзрәтнең кешелеген кысты:
«Нишләдең син, Ходай,
Безне болай
Кимсетергә илдә кемнәр кушты?!»
Ялваруын ишеттеме күкләр –
Кире кайтардылар нигезенә.
Кара яккан килеш калды һаман,
Агармады менә исем генә...

## 5

...Уттан калган капка баганасы...
Нигә генә янып бетмәгәндер?! –
Күрмәс иде...
Имән баганаың
Үзәгенәниләр үтмәгәндер!
Инде менә күпме сулар аккач,
Чыгып өзгәләнә сыерчыклар:
Капка баганасы куышында
Телгә киләме әллә кыен чаклар?
...Җиту кызларына хәзрәтнең
Урамнарга чыгар көн булмады;
Гел нахакка кимсетелгәннәрен
Халык арасында кем белмәде!
«Кулак балалары» дигән исем
Юылмады хәзрәт үлгәчтен дә,
Хокуксызлар булып саналдылар
Авылдагы власть кул астында.
Алмадылар –

Кулак сыйныф өчен
Түгел, имеш, колхоз дигәннәре.
Нинди «сыйныф» булсын:
Чабата да,
Киндер күлмәк иде кигәннәре!..
Уеннарга катнаштырмадылар,
Җиту кызлар илгә чыгалмады;
Яныл беталмаган баганалар
Бер генә кат яшькә чыланмады...

## 6

Күмерләнсәләр дә тышкы яктан,
Баганалар эчтән таза иде...
Капкадан да еллар авыррак –
Бергә күтәрергә язган иде.
Адәм баласына кайчангача,
Кайчангача хәрәм булсын кояш?!
Колхозына алмый нишләсеннәр,
Бушка эшләүчеләр кирәк булгач?
Берсе көтү көтте.
Икенчесе
Карулашмый йөрде кара эшкә.
Мулла нәселеннән булуларын
Төшергәләделәр һаман искә.
Жәлләп тормадылар колхозчыны.
Чапты алар шулай көнен-төнен
Тамаклары ачлы-туклы көе,
Ашап булмый иде хезмәт көнен...

## 7

Әллә каян узмагандыр гомер,
Шушы капка аша йөри биргән.
Икенчесе мулла кызларының
Төп нигезгә кайтты ире белән.

Икәүләшеп атлар карадылар
(Якты булып истә калган ансы).
Күпме еллар узгач, ат бәйләргә
Кирәк булды капка баганасы.
Күпне күргән имән баганалар...
Аларга да кайчак терәк кирәк.
Тормыш баганасы аумас өчен,
Кая гына барма, ир-ат кирәк.
Тәгәрәшеп балалары үсте
Капка төбендәге чирәмлектә;
Ачыргалана ник сыерчыклар? –
Оясына һичкем тигән юк ла!
Капка баганасы эчләреннән
Киләме әллә хәсрәт авазлары? –
Баганалар күреп тордылар шул
Адәм башларына ни язганны.
Ирен кертеп салгач (сугыш җиле!),
Чишендереп алды чабатасын.
Кайгы күргәне бар...
Ятим калган
Биш баланы ничек юатасың?
...Капкасына килеп сугылганны
Баганалар эчкә җыя барды.
Үкенмәде микән сыерчыклар –
Әй тынычсыз булды оялары!..

## 8

Моңнар тынмагандыр куышында –
Барсын күреп торды баганалар...
Егылган да булыр иде кеше,
Эчтә иман дигән багана бар.
Инде аудым, дигән чагында да
Җибәрми ул, эчтән тотып тора.
Күз яшеңне тышка чыгармыйча,
Хәсрәт-җәберләрне йотып тора.

Килүчеләр булмадылар түгел,
Ирсез хатынга соң тынгы бармы! –
Күңелдәге иман-баганага
Узгынчылар башын бәреп ярды...
Курыкканы – кеше хакы иде.
Беркайчан да гайбәт сөйләмәде,
Истә хатын-кызның:
– Түтекәем,
Рәхәт синең белән! – дигәннәре.
Өнәмәүчеләр дә табылгандыр:
– Харап икән, мулла кызы, имеш!
Бәрелгәләделәр.
Баганалар...
Баганалар калды туры килеш...

## 9

Чыга иде капка төпләренә,
Сөялмәде никтер баганага...
Озата торды,
Нәрсә дисен инде
«Китәм, әнкәй» дигән балаларга?!
Син генәме –
Сыерчыклар да бит
Ел да әнә бала очыралар?
Очып китәләр шул...
Сыерчыклар
Нигә болай чыр-чыр кычкыралар?
Синең җаныңдагы хафалар да
Бармы әллә алар тавышында?
Чыккан бугай бергә чүкердәшкән
Көннәр канатланып –
Барсы шунда!
Китә торды кошлар.
И кошкайлар!..
Баганалар ничә бушап калды,

...Капка төбендә ул –
Моңнан торган
Ялгыз баганага охшап калды.

## 10

Күпне күргән имән баганалар...
Алар күрәсене кемнәр күрсен? –
Шәһәрдәге балалары кайтып,
Аналарын алып китте беркөн.
Ярты авыл килде озатырга...
Алай иткән булды, болай итте;
Ниләр генә кичерелмәгән шул! –
Бөтенесен төяп алып китте.
Төяп алып китте авыл ямен,
Моңсу бушлык калды күңелләрдә.
Хәзрәттән калган баганалар –
Юк, багана гына түгелләр лә!
Утта янды, ачлыкларын күрде,
Кимсетелүләрне, сугыш җилен...
Капка баганасы!
Ул чакларда
Син болай ук ятим түгел идең.
Терәк идең авыр елларына,
Нинди җилләр сиңа кагылмады!
Ак көенчә калды ләкин нигез,
Бу капкага кара ягылмады...
...Инде кергән бала-чага гына
Чирәменнән нидер табып алды;
Озак торды әле баганалар:
Үткәннәргә капка ябык калды...

## 11

...Сыерчыклар килә торды һаман,
Бу нигездә алар – дәвам иде;

Ләкин бер яз нәүмиз калды кошлар:
Баганалар инде ауган иде...
Оча-куна эзләп йөрде алар
Ничә еллык газиз ояларын;
Каян белсен кошлар, узган җәйдә
Түтиләрен җирләп куйганнарын?!
Бичаралар озак эзләделәр:
Оя кирәк, оя – баганалар!
Кая гына барып сыенсыннар –
Ауганнар шул инде, ауган алар.
Бу нигездә үскәннәрне эзләп
Очсыннармы,
Каян табаласың?
Шәһәрләрдә алар торган өйнең
Юк шул инде капка баганасы!
Китеп барганнарның җанымы әллә
Сыерчыклар? –
Айкый җирне-күкне;
Эзләр әле, эзләр, мескенкәйләр:
Ауган баганалар илдә күпме?!
Арта бара баганасыз җаннар...
Кая барып, кемгә таянасы?
Белми эзләмидер сыерчыклар –
Кирәктер ул капка баганасы!..

## АНДА НИ БАР?

«Языйм микән, җитәр микән, диеп,
Бетәр микән, диеп, бу кайгулар?»* –
Җырлый идең әнкәй...
Көйләреңнән
Сабый җаннар күпме ут алдылар!

Җырларыңның кая тоташканын
Төшендем мин менә әле генә:
Шагыйрьләрнең сүзе бик күптәннән
Оялаган булган калебеңә.

Җырлый идең,
Ике күздә яшең...
Күңел төпкелендә – анда ни бар? –
Җаннарыңны ямаштырган ул чак
Акмуллалар синең, Кандалыйлар...

Өсләреңә килгән кайгылардан
Сыгылыплар төшәр көннәреңдә
Сыенгансың икән, таянгансың
Халыкның син әнә кемнәренә!

...Тулган чакта сабыр савытларым,
Җырларыңны җырлыйм – анда ни бар?
Каннарыма сеңеп,
Юатырга
Калган икән мине Кандалыйлар!..

* Габделҗаббар Кандалый шигыреннән.

## КАЙТЫП БАРГАН ЧАКТА МӨСЛИМГӘ...

Газиз әнкәй!
Кош тоткандай булып,
Китеп барган чакта Мөслимнән,
Китеп барган чакта Мөслимнәрдән,
Алъяпкычың салып өстеңнән,
Җиргә җәеп намаз укыгансың,
Теләк теләгәнсең син безгә:
Эзкәйләре берүк суынмасын,
Кайтарсын, дип, туган нигезгә.

Газиз әнкәй!
Ут йотардай булып,
Кайтып барган чакта Мөслимгә,
Кайтып барган чакта Мөслимнәргә,
Үзәк өзеп искә төштең дә
Бала чактагыча син җитәкләп
Алып киттең...
Инде адашмам:
Кыйбламны мин – туган туфрагымны
Бүтән кыйблаларга алмашмам!

Газиз әнкәй!
Күңелләрем җирсеп
Йөргән чакта бүген Мөслимдә,
Йөргән чакта бүген Мөслимнәрдә –
Иман сеңгән туфрак өстендә,
Синең җылың, назларыңны тойдым,
Сөенечләреңне, кайгыңны –
Җирдән киткән чакта урыныңа
Калдыргансың туган ягымны...

# КАРАВЫЛДА

...Батып бара шәфәкъ.
Күзге күккә
Йолдызларны җыям –
Аларга бит бүген дөнья мине
Каравылга куйган.

Югалмаска тиеш бер йолдыз да...
И балачак күге!
Ул чакта бит әнкәй белән идек,
Болай ялгыз түгел.

Ашлык көшелләрен саклый әнкәй,
Ә мин – йолдызларны:
– Урыныңдамы син, Казык Йолдыз,
Җидегән, син бармы?!

Кызган мәкинәгә күзге төндә
Аякларны тыгып,
Бу дөньяның барлык йолдызларын
Саклап яту – кызык!

Берүземә әнә никадәрле
Йолдыз көшелләре!
Бернәрсә дә булмас – мин йолдызсыз
Итмәм кешеләрне...

Шәфәкъ бата...
Күкләремә тагын
Җыям йолдызларны:
– Урыныңдамы син, Казык Йолдыз,
Җидегән, син бармы?!

Бер йолдыз да югалмаган, исән.
Менә... әнкәй генә...

Балачак та әллә кая киткән –
Сакламадым нигә?

Дөнья мине, ахры, гел ялгышып
Каравылга куйган –
Көзге күктә әнкәм эндәшәме:
– Кайтыйк, улым, уян!
Уя-а-ан!..

## ӘРӘМӘ БАР...

Ул якларда искән хәтер җиле
Әрәм икән сиңа, әрәм әле:
Оныткансың, бик тиз оныткансың
Ындыр артындагы әрәмәне.

Үзең менә заман уртасына
Килеп җиткәнсең дә исән-имин,
Үтмәс балта белән утын кисеп.
Әрәмәдә калган әнкәң синең...

Еллар буе
Агач башларында
Кычкыручы – кәккүк түгел бит ул! –
Каян эндәшсен соң,
Синең өчен
Мәңге өзгәләнгән күңел бит ул...

Бар гаепне бүген заманага
Аударасың, беләм, тотасың да.
Бер колак сал:
Утын кисә әнкәң...
Әрәмә бар заман уртасында!

## ӘНКӘЙГӘ КАЙТУ

Инде юлга төштем бугай, дисәм,
Тагын ялгыш... Тагын буталдым! –
Гомерем буе сиңа кайтам, әнкәй,
Тик һаман да кайтып җиталмыйм.

Сабый җаннар каян аералсын:
Хакыйкать бар җирдә, ялган бар, –
Күзебез дә ачылмаган килеш
Безне синнән тартып алганнар.

Без синеке булмаганбыз, әнкәй,
Җылынсак та канат астыңда.
Яратылганбыздыр гомерлек бер
Хәсрәт итеп газиз башыңа.

Калдырмадың намаз-ниязыңны –
Гамәлләрең безгә ят иде;
Өйрәткәнең, имеш, хата синең,
«Аларныкы» гына хак иде.

Балаларың берүк ятка бирмә,
Туры юлга күндер, инандыр!
Ходай гына белә – ике иман
Бер куышка ничек сыйгандыр?!

Агачыннан ерак төшми, диләр
Иде дә бит болай алманы,
Безне ерак, ерак ыргытканнар...
Кайта-кайта хәлләр калмады.

Күпме аналарның, минем кебек,
Балалары бүген юлдадыр.
Кайталардыр...
Каршы чык ла, әнкәй,
Юл башына, яулык болга бер!

Бүтән беркем коткаралмаячак,
Халкым җирдән мордар китәчәк –
Табалмасак әгәр тамырларны,
Әнкәйләргә кайтып җитмәсәк...

* * *

Ишетәм көзге җилләрдә:
«И улым... балакаем!..» –
Ул каен – зират өстендә...
Син кайда, Бала Каен?!

Кайда син, кайсы якларда?
Кайда да җилдер инде...
Каенга – каен язмышы:
Җилбер дә җилбер инде!

Кайларда тамырлансаң да,
Каеннар усак булмас.
Каенда – каен башлары:
Кайгыдан бушап булмас...

Ишетәм, әнкәй, ишетәм –
Җил генә кебек ара.
Илдәге Бала Каеннар
Давылга кереп бара.
Давылга кереп бара...

## ӘНКӘЕМНЕҢ БИШ БӨРТЕГЕ

Без биш кенә бөртек идек.
Әллә кая сипте җилләр...
Сулар кипте, ауды урман,
Бездән башка бетте өйләр.

Килеп төште бу якларга
Әнкәемнең бер бөртеге.
Ничек итеп тамырланыр? –
Су сибәргә юк беркеме.

Таш өстенә килеп төште –
Яра алса гына ташны!
Туфрак кирәк икән, туфрак –
Күтәрәлер өчен башны...

Без биш кенә бөртек идек,
Сибелештек биш тарафка.
Кемнәр кемнең бөртегедер –
Тарата ла җил, тарата.

Калаларда, далаларда –
Берәм-берәм, бөртек-бөртек.
Кемдер эзләп табар төсле:
Анда бер төп, монда бер төп.

Илдә җилләр исеп калды,
Бәрәкәтләр күчеп калды, –
Әнкәемнең бәгыреннән
Биш бөртеге төшеп калды...

## ДИСБЕ

Кич утырып дисбе тездең
Мәрьям-ана күз яшеннән* –

...Барсын белеп тора бит ул,
Тәңредән кем яшергән:
Тама күздән,
Бөтенесен
Булмый икән эчкә йотып! –
Аларны да син ул кичтә
Тезгәнсеңдер дисбе итеп...

Туксан тугыз яшь бөртеге...
Өтә сыман кулларымны,
Челтер-челтер сөйли дисбе
Бу дөньяда булганыңны.

Челтер-челтер...
Көзге җилләр
Тәрәзәмә яңгыр сылый.
Тик син генә беләсеңдер:
Заманалар нигә елый?

Туксан тугыз яшь бөртеге
Дәверләрнең арасында, –
Шул дисбене тартасыдыр
Җирдә адәм баласына...

* Дисбе итеп тезгән җимеш төшен «Мәрьям-ана күз яше» ди торган иде әнкәй.

* * *

«Әнкәй!» – диеп башлап кителгәннәр...
Уйламадым шулай сакларың:
Синнән калган китап эчләреннән
Килеп чыга язган хатларым.
Вакыт эчләреннән килеп чыга
Әйталганым, әйтми калганым.
Без кайлардан белик
Гомерләрне
Шушы хатлар белән ялгарың?!
Әллә нигә кыска язылган шул,
Малайларча саран дәшелгән.
Хәзер язам да бит...
Нигә тәкъдир
Җаннарымны синнән яшергән?!
– Әнкәй!.. – диеп кычкырасы килә,
Абынсаң да, утлар йотсаң да.
Безгә һаман ана бит әле син,
Чирәм генә булып шытсаң да...
Бүтәннәргә белгертмәгәнсеңдер,
Инде хәзер язмый калалмыйм:
Син анда да тыныч түгелсеңдер –
Җир өстендә калган яраң мин.
Бәреләләр...
Кычкырмаска иде,
Әрнетмәскә иде яраңны.
Хатлар итеп язып карыйм димен,
Яндырмаса кәгазь-карамны.
Вакыт эчләренә салып китәм
Назларыңны синең, төсеңне.
Мин бисмилла урынына әйтәм
Әнкәй дигән газиз исемне...

## КӨЗГЕ

*(Поэма)*

Затлыдан да затлыбыздыр сыман:
Бар дөньябыз хәзер көзгеле.
Үзебезне әллә күрми торсак,
Бер минут та җаннар түзмиме? –
Стенада көзге, ишекләрдә...
Түшәмнәргә көзге тезделәр.
Кая барсаң, шунда каршылыйлар –
Эзәрлекли безне көзгеләр.
Үзебезне көзгеләргә шулай
Булдыралган чаклы төрдек без.
Көзгеләр күп,
Тик нигәдер менә
Кем икәнебезне күрмибез...
Сынабрак бер карыйсы иде –
Үзебез дә әле бардыр ла!
Ничек булсак, шулай күрсәт, көзге,
Мир алдында оятка калдырма...

Катламнарны актар: тәңкә чыгар,
Чулпы булыр, көзге – табылган.
Байлыктан да бигрәк, борынгыдан
Матурлыкка кеше табынган.
Хәйран калгандыр ул су өстендә
Үз шәүләсен күреп, үз төсен.
Үз-үзенә карап гыйбрәт алган –
Уйлап тапкан шулай көзгесен.
Матурлыкны ныграк таныр өчен
Кирәк булган көзге, хаклыкны;
Тирә-ягы кара чакта кеше
Көзгеләрдә тапкан аклыкны.
Төннәрен дә кояш күрә алган...

Күңел көзгеләрең сау булсын!
Безгә бүген байлыктан да бигрәк,
Матурлыклар күбрәк табылсын.
Борынгыдан кирәк булган көзге.
Кирәк бит ул әле безгә дә:
Дөреслекне һаман әйталмыйбыз
Туры гына карап күзләргә.
Кояш нурын капламыймы бүген,
Җирне буямыймы карагыз? –
Кара җаннарга да хәрәм түгел,
Көзгеләргә ешрак карагыз!..

Минем дә бар көзгем: изге мирас –
Туган өйнең иске көзгесе.
Киләмен дә шул көзгегә карыйм...
Әллә каян юктыр эзлисе:
Кайта миңа туган өй җылысы,
Сагышлары килә, шатлыгы –
Актарылам...
Беренчесе түгел
Мондый хәлнең, түгел актыгы.
Үткәннәргә бер тәрәзә сыман:
Күз төшүгә якты сирпелә,
Сабый чаклар карап тора аннан,
Бер моңая сыман, бер көлә...
Әкиятләрдә була иде бары
Тылсымланган мондый көзгеләр.
Өебездә андый байлык барын
Ничек белми калдык без генә?!
Җитәр иде микән тылсымнары
Ул көзгенең, белгән булсак та –
Алдыбызда тормыш үзе иде,
Әкият кенә түгел ул чаклар...

Кемдер әйтте: «Сез бәхетле!» – диде.
Кире какты көзге: «Юк!» – диде.
Очын очка көчкә ялгый идек...
Әнкәйләрнең бәгыре ут иде,
Кирәк иде бәхет...
Тик ул гына
Бик эндәшми икән, син дәшеп:
Көлү итеп күрсәтмәде көзге
Беркайчан да безгә күз яшен.
Әткәй исән булса, табар иде,
Кызганмаслар иде атын да.
Безнең белән санлашмады бәхет,
Сан бармыни ирсез хатынга?!
«Сез бәхетле!» – диде безгә кемдер –
Ул идеме, чормы беркатлы:
Бәхетне без кышкы кара төндә
Салам белән урлап апкайттык,
Иңсәләргә салып, әрәмәдән
Зирек белән бергә ташыдык...
Мин бүген дә көзгеләрдән эзлим –
Әкиятләремнең башы юк.
Ул чакта ук яшермәде көзге:
«Бар!» – димәде юкны. – «Юк!» – диде.
...Очын-очка көчкә ялгый идек,
Әнкәйләрнең бәгыре ут иде...
Караганым – гади көзге түгел:
Мин – тылсымлы көзге хуҗасы,
Кылган гамәлемне дөреслимен,
Аңа карап.
Әле моңарчы
Булмагандыр мине алдаганы,
Ак димәде йөздә тап барда.
Беркайчан да ирек бирмәде ул
Аклыкларны салып таптарга.

Сөртеп кенә тота иде әнкәй –
Җаны кебек күрде көзгене.
Көзгеләрдәй булган икән җаны...
Соң төшендек ләкин без моны:
Безнең күңелләрне сөрткән бит ул
Тыны белән өреп, сак кына.
И тирән дә көзге...
Хәзер инде
Көзгеләрдә очрашсак кына!..

Кояш булып кояш яктысына –
Булган чорлар – кара якканнар.
Дөреслекне күреп торган өчен,
Көзгеләрне бәреп ватканнар.
Ил көзгесез калган...
Алданган ул
Күгендәге ялган кояшка;
Ачылмаган күзләр,
Меңәрләгән
Асыл затның җанын кыйгач та!..
Өйдә көзге ватылса да кыен –
Югалгандай була күз явың;
Ил кадәрле илдә – яман икән,
Хәтәр икән – көзге булмавы...
Бар тылсымы үзебездәдер лә,
Юктыр безгә читтән эзлисе:
Ил көзгесе – Ирек! –
Ни булса да
Тапланмасын илнең көзгесе!

Авызың чалыш булса, көзгеләргә
Үпкәләмә... – Күптән билгеле!
Үзебездән гаеп эзләмәдек,
Сүгеп килдек һаман көзгене.

Кемгә мал җитмәде, кемгәдер – дан, –
Катлы-катлы «Герой» булса да;
Яшералмый көзге,
Йөртсәң әгәр
Йөрәк урынында... мунчала!
Ялган шөһрәт-даннан оештырып
Көзге ясаттылар...
Андыйлар
Чын хәленә кире кайталмыйча,
«Көлке бүлмәсе»ндә калдылар!..
«Абзый»ларның кубызына кушылып,
Купшы сүзләр күпме кычкырдык –
Искерделәр бик тиз...
Ул вәгъдәләр
Булып чыкты бары өч көнлек.
Качтык көзгеләрдән.
Ямьсез чакта
Үз-үзеңне килми күрәсең.
Көзгеләрдән карамасаң, йөзең
Ниндилеген каян беләсең?!
Хатаны да хуплый өйрәнгәнбез...
Чиге бардыр шәүлә булуның –
Ялгышканда төзәтерлек кенә
Бер-береңә көзге бул идең!

Көзгесезләр җирдә күп булдылар,
Кыйбласызлар...
Җаны гарипләр...
Үз карасын бүтәннәргә ягар
Ул бәндәләр, сине гаепләр.
Көчсезләргә өрер,
Көчлеләрнең
Аягына килеп елышыр.
Шул көе дә илнең бер матуры

Булып күренергә тырышыр.
Андыйларга көзге буласы бар,
Ачып күрсәтәсе чын йөзен –
Бу чаклы ук кералмаслар иде
Ил күзенә кичен-көндезен.
Үзебезне таный алыр чакта,
Гореф-гадәт барда, тел барда
Ешрак карыйк әле көзгеләргә –
Төсмерләнә бүген кем анда?
Туры карыйк:
Кемнәр икән соң без,
Ни кылабыз, ничек хәлебез?
Ата-бабаларның изге исемен
Онытмадык микән әле без?
Замананың яман чүп-чарына
Бетмәдеме җаннар буялып?
Йөрмибезме туган телебездә
Сөйләшергә кайчак оялып?
Йөзе дә юк, әйтер сүзе дә юк –
Кемнәр үстерәбез алмашка?
Күп нәрсәгә инде күз йомабыз –
Күңелләрне нинди ләм баскан?
Хәтерләрдә ни бар?
Маңкортларга
Әйләндекме әллә инде без? –
Төбәбрәк бер карагыз әле
Көзгеләргә,
Булса көзгегез!..

Әйләнеп бер артка карыйм дисәң,
Яндырылган тарих, ягылган.
Күңел көзгеләре – җырлар гына
Килә безгә
Хәрабәле чорлар ягыннан.

Нәсел-нәсәбеңә, милләтеңә
Карасалар әгәр җирәнеп,
Бабайларның йөрәгеннән чыккан
Шул моңнарны сузып җибәрдек.
Җаны кара булган – җырлый алмый,
Якты җаннар – җырсыз торалмый;
Тамырында «Әллүки»ләр аккан –
Беркайчан да вәхши булалмый!
Илсез-җирсез калган чагында да,
Юк, имансыз булып калмадык.
Без бит изге кабер ташларының
Өсләренә храм салмадык...
Хөкемдарлар булып дан чыкмады,
Якласак та – бары хак эшне.
Башкисәрләр түгел нәселебез:
Җырлый халык –
Җырлар баш кисми!
Яндырылган тарих, туздырылган...
Җыр янмаган. Безгә җыр калган.
Таный алыр бабалары җанын
Бу көзгегә килеп күз салган.

И тирән дә көзге...
Бер-бер артлы
Әллә нинди йөзләр ачыла;
Күпме карасаң да, уйларыңның
Чыгалмассың кебек очына.
Алларында гади көзге түгел –
Ил-халкыңның намусыдыр ул.
Күз карадай саклап,
Каның белән
Юа-юа карыйсыдыр ул.
Йөзгә таплар куна-нитә калса,
Шул көзгегә карап сөртәсе;

Юкка уйлап тапмагандыр кеше –
Күңелебездә көзге йөртәсе.
Югалтканнар бардыр көзгеләрен,
Адашканнар еллар эчендә. –
Көзгесезләр!
Бер карагыз килеп:
Бу җыр-көзгем – сезнең өчен дә...

# VII. Кичке тәрәзәләр

...Үтеп чыга алмас ут икәнсең, —
Үземне мин утка ягып китәм.



* * *

Ышанып та бетмим кешеләргә:
Сукыр, диләр сине, мәхәббәт! –
Ә соң ничек бөтен гомерем буе
Син йөртәсең мине җитәкләп?!

## БЕЗ ЯЗГАН ХАТЛАР

*Кызларга*

Яшереп кенә хатлар яздык сезгә, –
Вакламасын сөюне ятлар.
Яшьлек тургайлары булып килер
Гомерегезгә
без язган хатлар.

Еракларга китеп барырбыз без,
Җиталмаслар аргамак атлар.
Бәхет тамчылары булып тамар
Җаныгызга
без язган хатлар.

Чаларырсыз, бәгыренгезне телеп,
Искә төшәр ваемсыз чаклар.
Сандыклардан чыгып юатырлар,
Сагынганда,
без язган хатлар.

Каләм манчып язган сөю утын
Сүрелдерми гел шулай саклар;
Гомер буе барыр, сез көтегез:
Араларда –
без язган хатлар...

* * *

Үзең белмисеңдер әле
Йөргәнеңне кайларда:
Үзем белән бергә сине
Алып менәм тауларга,
Болыннарга алып чыгам,
Йөртәм су буйларында;
Син – эчәсе суларымда,
Алган сулуларымда.
Һич назлап туялмыйм сине,
Аралыйм чәчләреңне,
Син үзең дә ишетмисең
Иркәләп дәшкәнемне.
Сине гомер кыры аша
Күтәреп үтәр идем...
Белмисең шул...
Әгәр белсәң,
Тетрәнеп китәр идең!

# АЙ

Әйтерсең күтеп тора ай
Без сызгырганны гына,
Яңгыратып гармуннарда
Бер сыздырганны гына.
        Сак кына килеп чыгар ул,
        Оялчан кызлар сыман,
        Сакланган шикелле генә
        Картларны уятудан.
Сөйләрсең төннәр буена –
Серең тыңлар тын гына,
Карарсың нурлы йөзенә –
Йөзәр югартын гына.
        Офыкка кадәр озатып
        Куярсың айны аннан.
        ...Ерактагы көмеш кичем!
        Бу җырың миндә калган;
Тик шуны гына җырладым, –
Егетләр көнләмәсен,
Белсеннәр әле шул айның
Бер җанны телгәлисен...

* * *

Бер үк җырның ике яртысы без,
Бер тургайның ике канаты, –
Пар аккошлар шуны әйтеп узды,
Шул хәбәрне җилләр таратты.

Иреннәрдә янган ул сөюне
Йөрәкләргә салдык икебез,
Шул хис белән ялкыннарда яндык,
Яңгырларда калдык икебез.

Сүрелү белмәс кайнар йөрәклеләр
Һәм җирдәге сөю хакына
Ай нурыннан һәйкәл куяр идем
Без очрашкан юллар чатына...

## СИНДЕР УЛ БАРЫ

Күкләргә ашып талпынса йөрәк,
Җилләрне узып җилкенсә күңел –
Синдер ул бары еррактан дәшкән,
Бүтән беркем дә,
Беркем дә түгел...

Кайчак онытылып бер җырлыйм дисәм,
Җанымда бүтән бер көй дә түгел –
Синдер ул бары мәңгелек моңым,
Бүтән беркем дә,
Беркем дә түгел...

Ераклашсалар аралар әгәр,
Сагыштан-моңнан сызланса күңел –
Синдер ул бары гомерлек юлым,
Бүтән беркем дә,
Беркем дә түгел...

# ӘЙТЕГЕЗЧЕ!

И тартыла зыңлап җанда бер кыл,
Ераклашкан саен яшьлектән,
И сызыла күкрәгемдә бер көй –
Синме, йөрәк, шулай яшь түккән?
Синме, минем сөю карлыгачым,
Кагыласың һаман шул кылга?
И сызыла бәгырь! Туктасынчы,
Әйтегезче, зинһар, шул кызга...
Әйтегезче, тик бер генә мәлгә
Туктамасмы ул көй агыштан, –
Түзмәс кебек җанымдагы ул кыл,
Өзелер сыман беркөн сагыштан.
Өзелер дә кинәт арабызда
Бушлык калыр, җанны өшетеп,
Сыкраныр яшьлек, соңгы тапкыр
Зыңлап тынган көйне ишетеп...
Моңлансын ла, әйдә, гомер буе, –
Ни булса да булыр ул кылга,
Сызылсын ла бәгырь! – Туктамасын,
Әйтегезче берүк шул кызга!..

* * *

Шомыртларга инде ак шәл кирәк,
Язгы яңгыр ява – гел ләйсән.
Җаннарыма шифа булыр кебек,
Яңгырларга чыгып әйләнсәм.

Синең гомер – язгы яңгыр миңа,
Толымнарың – кара гөрләвек:
Иңнәреңнән агып төшә дә ул,
Җырларыма керә юл ярып.

Яланнарга чыгып бер әйләним,
Юк, теләмим яңгыр узганны:
Елатыр да, юатыр да кебек,
Яңгырларга куйсаң бу җанны...

## БЕР СЫЛУГА

Күз карашың таң нурлары булып
Сирпеләдер язгы болыннарга;
Иреңеңнән аерылган сүзләр
Әйләнәләр шундук былбылларга.

Тик бер үпкән идем – мин сандугач хәзер...
Булдыралмыйм инде сайрамыйча, –
Гаҗиз калып тыңлап тора таллар,
Тыңлап тора яфрак яралмыйча.

Нишләттең соң мине, и сылукай,
Нинди сихер, кайсы тылсым белән? –
Һич белалмыйм...
Тик үзеңнән башка
Кеше булалмамын – шунысын беләм!

* * *

Нәрсә югалттың, сылукай,
Син гөлләр арасында,
Синең сагышларыңмы әллә
Былбыллар ярасында?

Шулкадәр йөгердеңмени,
Капты ник сылуларың? –
Җилләргә әйләнгән бугай
Синең юксынуларың.

Һаман кул изи тирәкләр,
Синнән күрептер инде,
Ничек түзеп тормак кирәк –
Нинди егеттер инде!

...Ияреп килә сөюең
Бер сабый бала сыман,
Күтәреп аласы иде
Елларым арасыннан...

## КӨЗГЕ ЯҢГЫР

Төне буе яңгыр сибәләде,
Хәтерләргә тамды тып та тып, –
Бәгырьләрне тишеп чыга язды...
Булмады ла инде туктатып!

Яңгыр түгел, үкенечләр тамды,
Безнең ялгышулар тамдылар;
Шул беркатлы яшьлек килеп тамды:
– Китә күрмә миннән, кал, юләр!..

Хәйран калып сызгырдылар җилләр:
– Бу яңгырлар – инде сезме соң?..
Яфрак-яфрак сагышларың белән
Телгәләде бүген көз мине.

Шыбырдашып сибелделәр җилдә
Сагынулар безнең арага;
И сөюләр! Бүген бар дөньяга
Көзге яңгыр булып тарала...

* * *

Акрын гына китеп барам синнән –
Сәгать белән китәм, көн белән...
Мәңгелеккә аерылу ич бу! –
Туктатыйм соң ләкин ни белән?

Ераклашкан саен яктырасың,
Күләгәләр бетә синдәге;
Син бер йолдыз инде...
Ә җылыңны...
Ә җылыңны тоям мин әле!

Мәңгелеккә китеп барам синнән,
Тамга итеп җанга күркеңне;
Тик бер сине күздән югалтырмын...
Дөнья бетәр ләкин ул көнне!..

* * *

Матурлык алдында телсез
Калмаган кемнәр генә! –
Батырлыклар ачкыч булган
Сылулар йөрәгенә.

Башым исәм, көчсезлектә
Гаепләмә, и сылу! –
Батырга да язык түгел
Матурлыкка буйсыну...

* * *

Һаваларга җырлар язам,
Ераклардан син күрсен дип;
Төне буе җемелдәшеп,
Серләремне белдерсен дип.
Сибеләмен... күкләр тула...
Мескен йөрәк чыдасын ла! –
Син шуларны сүндерәсең
Кояш булып чыгасың да...

## КЫЙБЛА

Кая таба карарга да белмим,
Син очрарсың сыман тоела.
Тиләләргә сабышырлык итеп,
Ут салмасаң җанга ни була?..

Яланнарга чыксам, сагышымны
Бүлешергә гөлләр җыела;
Гөлләрдә дә синең төсең генә,
Бер карасам, җаным кыела.

Урманнарга барсам, алларыма
Йөрәк-йөрәк яфрак сибелә.
Кай тарафтан исмәсеннәр җилләр, –
Барысында да синең көй була.

Кая таба карап табыныйм соң? –
Дүрт ягым да минем кыйбла.
Кыйблаларның кыйбласы булып
Чыгып бассаң шунда ни була...

## КИЧКЕ ТӘРӘЗӘЛӘР

Тик бер генә карыйлар да,
Үзәкне өзәләр дә –
Нур булып кабына кызлар
Кичке тәрәзәләрдә.
        Тылсымлыдыр төсле,
        Һич сүнмидер төсле
        Кичке тәрәзәләр.
        Их, бу тәрәзәләр!..
Ачылса әгәр каршыңа
Яшерен вәгъдәләрдән,
Иртәгә чыгасы кояш –
Шушы тәрәзәләрдән.
        Җырлап уза төсле,
        Чәчәк суза төсле
        Кичке тәрәзәләр.
        Их, бу тәрәзәләр!
Сирпелә әллә кайларга,
Күтәрә пәрдәләрен –
Елларга төшә яктысы
Кичке тәрәзәләрнең...
        Нидер дәшә төсле,
        Бәхет чәчә төсле
        Кичке тәрәзәләр.
        Их, бу тәрәзәләр!

## ОНЫТТЫР

Күңелем күгендә гомерлек
Айларым, кояшым булып тор, –
Оныттыр,
Оныттыр син миңа,
Болыттай кайгымны оныттыр.

Адашып егылыр чагымда
Ерактан кулларың сузып тор, –
Оныттыр,
Оныттыр син миңа,
Ялгызлык газабын оныттыр.

Зарыгып, сагынып килгәндә,
Сөюнең каршына чыгып тор,
Дөньямны оныттыр, –
Син мине
Мәңгелек бәхеткә юлыктыр...

## БЕР КАРАСАМ...

*Сиңа*

Бер карасам – балам сыман,
Бер карасам – анам сыман,
Бер карасам – гомер буе
Әрнеп торган ярам сыман.

Жаның – җәйге ялан кебек –
Яланаяк барам кереп;
Узмас гомер: шул яланда
Мәңге торып калам кебек...

## ЯЛГЫШЫНА КАДӘР...

Яшьлегемдә мин берәүне сөйдем.
Ә ул качты, ташлап язларым.
Хатлар булып яудым авылына –
Нигә, яшьлек, җавап язмадың?!
Шул чакларны,
Шул хатларны сагынам...
Язмауларын сагынам мин аның;
Үзе түгел, күзе түгел – киткән
Эзләренә кадәр моң аның.
Мәхәббәттән качкан кем бәхетле? –
Үкенәдер...
Мин дә үкенәм:
Саклап алып калалмадым аны
Үкенечле юлга китүдән.
Үпкәлидер миңа...
Яшьлекнең шул
Үпкәләргә безгә хакы бар:
Толымнарын тешләп, чит мендәрдә
Яшен түгә азмы хатыннар?!
Барам-барам – барып җиталмыймын
Соңгы тапкыр күргән көннәргә –
Яшен булып кисәр иде яшем
Китәр юлын әллә кемнәргә.
Шул чакларны,
Шул чатларны сагынам...
Чыкмауларын сагынам мин аның;
Тавышы түгел, сагышлары түгел –
Ялгышына кадәр моң аның...

## КИЧЛӘРЕМ

Кич утырып сиңа җырлар яздым,
Җырларыма тулды кичләрем –
Утка сала бардым кичләремне,
Кичерсәнә, әллә нишләдем.

Төшләреңә синең кучмәдеме,
Дәшмәдеме зәңгәр кичләрем?
Кичектеңме әллә кичләремә? –
Көмеш нурлар булып төшмәдең.

Кичке җилләр булып син исмәдең,
Янәшәмдә еллар кичмәдең.
Кичерсәнә минем кичләремне,
Исләреңә төшсә кичләрен...

* * *

Яңа ярлар табак белән аш китерә,
Иске ярлар ике күздән яшь китерә...
*Халык җыры*

Икесе дә – ашың да бар, яшең дә бар:
Аш өстенә тамчы-тамчы яшең тамар;
Ашың йотып, яшең сөртеп өлгергәнче,
Аяз көндә йөрәгеңне яшен табар...

## КАЙДА СИН, ГАРМУН?

Чыңлады гармун, моңланды гармун,
Айлы кичләрдә тынмады гармун.
Үз итеп кенә сөйләде безгә
Шул моңга кушып шатлыгын, зарын.

Сер итеп кенә әйткән иде ул
Бу җирдә кайнар сөюнең барын, –
Таралды ул сер авыл буенча,
Әйтче, әйтче син, нишләдең, гармун?

Әйтергә безгә онытты бугай
Бу җирдә тагын кавышу барын...
Сер итеп кенә сөйләр иде бер,
Кайда соң гармун?
Кайда син, гармун?!

* * *

Берәүдән дә җылы сүзем кызганмадым,
Кара төндә кабыздым мин ялкынсызны;
Бетмәгәндер җир йөзендә мохтаҗ җаннар –
Көтәләрдер, әйтер бу дип, алтын сүзне.

Каршыгызда ни кылырга белми торам,
Юктыр хәзер юатырга хакым сезне:
Бер гүзәле акылымны алды бүген,
Ялгышырсыз – тыңламагыз акылсызны!..

## СИҢА ГЫНА ЯЗГАН ХАТЛАР

Әгәр еракларга китеп барсам,
Сагынудан синдә янса утлар –
Бәхет тамчылары булып тамар
Сиңа гына язган назлы хатлар,
Сиңа гына язган назлы хатлар.

Чәчләреңә инде чал керсә дә,
Искә төшәр бергә булган чаклар.
Яшьлек тургайлары булып килер
Сиңа гына язган назлы хатлар,
Сиңа гына язган назлы хатлар.

Йөрәкләрдә янган сөю утын
Сүрелдерми мәңге шулай саклар –
Син көт кенә, килер сагынганда
Сиңа гына язган назлы хатлар,
Сиңа гына язган назлы хатлар...

* * *

Чәчәк җыеп йөри кызлар...
Күңелләрен кем аңлар? –
Тавышсыз гына чыңлыйлар
Зәп-зәңгәр кыңгыраулар.

Кызлар кулында кыңгырау
Ни хәбәр итә икән? –
Бер чыңлавы гомерлеккә
Тыңларга җитә икән...

* * *

Минекеме әллә түгелме син? –
Төшенә алмыйм һаман мин шуңар.
Әйтерсең без вакытлыча гына
Очрашкан бер гади юлчылар.

Төрле яктан килеп кердек икәү
Сөю дигән уртак юлга без;
Бер үк ярлар арасыннан ташый,
Бер үк язда гомер елгабыз.

Елмаясың – вакытлыча гына,
Мин иркәлим – чордан бер тузан.
Гомерләрдә – мизгел озынлыгы;
Үтеп китәр, аны кем узган!

Алып китәр юллар икебезне,
Ике якка таба каратып,
Үкси-үкси торып калыр сыман
Юл чатында безнең Ярату...

* * *

Таш бәгырьле, дисең мине,
Бәгыремдәге шул ташка
Исемеңне уеп яздым,
Үлгәндә дә җуймаска...

* * *

Сиңа гына дигән бер җырым бар,
Кыймый торам әле җырларга.
Йөрәк түрендәге шул җырымнан
Очкын төшәр сыман елларга.

Без янарбыз,
Ә син пәрдәләрең
Күтәрерсең, тышта таң диеп,
Офыкларга карап сокланырсың,
Бу шәфәкъләр бигрәк ал диеп,

Юк, җырламыйм әле бу җырымны,
Калган – калсын, әйдә, сер булып.
...Йөзләреңә төшкән алсулыгы –
Офыкларда яна бер болыт...

## СӨЮ

Илләр беткән җирдә, телләр беткән,
Халык булып беткән халыклар,
Ул бетмәгән: Вакыт төпкеленнән
Һаман өскә, өскә калыккан.

Без йөзәбез синең белән икәү,
Тотынышып кулны кулларга;
Юк, батмыйбыз нинди җил бәрсә дә,
Йөрәкләрдә безнең Ул барда.

Илләр беткән җирдә, телләр беткән, –
Вакытларга бар шул буйсыну!
Йөзеп йөри Вакыт өсләрендә
Пар аккошлар булып бу Сөю...

# ЯКТЫ КӨННӘР ҖИРДӘ

*Люзиягә*

Җәен-кышын юлда безнең гомер,
Кичләр килсә җиргә, көн-таң атса.
Якты көннәр балкып тора алда, –
И очабыз икәү шул тарафка!

Әгәр анда барып җитәлмәсәм,
Еллар күмеп китсә тавышымны –
Агачларның моңлы шавын тыңла,
Язгы мәлдә тыңла агымсуны...

Берьялгызым торып калсам әгәр,
Син югалсаң барыр юлларымнан –
Тоярмын мин якты карашыңны
Җир өстенә иңгән таң нурыннан.

Якты көннәр җирдә...
И очабыз –
Җиттек инде юлның яртысына.
Ялгыз калсак та без, бергә килеш
Барып керик еллар яктысына!..

# МАТУРЛАРГА

Бу табигать сезнең бер карашка
Никадәрле кодрәт яшергән! –
Күпме йөрәк сезнең коллыктадыр...
Сезнең алда шаһлар баш игән.

Гомерегез – безгә бер бүләктер:
Сезнең белән көннәр нурлырак,
Яшәү мәгънәлерәк сезнең белән,
Сезнең белән җырлар моңлырак.

Карашларың ничек тартылмасын:
Кешелекнең сездер чәчәге;
Күпме куллар сузыла үзегезгә, –
Кыенрактыр сезгә яшәве.

Әллә сезгә сынау өчен генә
Бирелдеме икән матурлык:
Гүзәлләргә җанын матур килеш
Саклап йөртә алу – батырлык!

## МИЛӘШ

Өй түрендә – миләш,
Иелә җилләр тигәч,
Тәрәзәгә карап кызара;
Өзгәләнмә, миләш, –
Булчы якын сердәш
Мәхәббәтен көткән кызларга!

Язың-көзең димә,
Башкаеңны и дә
Йөрәкләрен тыңла көн дә син:
Әйтмә таң җиленә,
Бел тик үзең генә, –
Ятлар берүк сизә күрмәсен.

Өй түрендә – миләш...
Авыл берни белмәс:
Ник кызарган болай, димәсләр;
Яшерен яна-яна
Кулын болгап кала, –
Әллә кызлар, әллә миләшләр...

* * *

Сөюне сөюдән аерсак,
Без ялгыз китәсе юлларны
Тоташтан ал мәкләр каплар күк...
Таптарбыз микәнни шуларны?!

Җил эзләп каңгырыр, –
Кайларга
Барма да, кайларга карама;
Язын да, көзен дә кошларның
Кәрваны сузылыр арага.

Кичермәс, берни дә кичермәс
Син миннән, мин синнән китүне;
Аерылсак, йөрәктән йөрәккә
Сузылыр салават күпере!..

* * *

Ташка язганнар сөюне,
Ташлар да җимерелгән...
Без дә язабыз: йөрәкне
Сайладык синең белән.

Әрнү-газаплар язылган,
Сөюдә янган йөрәк
Кояштан кайнарррактыр,
Ташлардан гомерлерәк...

## СӨЮ ФАСЫЛЫ

Күрсәнә бизәнүләрен:
Каеннарның кыз чагы;
Наз гына егет-җилләрнең
Киереп ачкан кочагы.

Сикерә дулкын,
Талларны
Сандугачтан көнлидер;
Бу мизгелдә кемнең кемгә
Гашыйклыгын кем белер?

Яңгыр тамчылары үбә
Күзләреннән гөлләрнең;
Өйрәтә икән күкеләр
Сөю-сагыну телләрен.

Тургай дисәм, күккә менгән –
Канатлы йөрәк бугай,
Бу мәлдә канат ярмаган
Йөрәкләр сирәк бугай.

Ачылган бөтен иркенә,
Дөнья бүген, һай, сылу!
سездә нинди айлар икән? –
Бездә – Сөю фасылы...

* * *

Хатлар килә, хатлар китә...
Язмый торыр чаклармыни! –
Чигү чиккән энә кебек,
Ике арада хатлар йөри.

Яза кызлар: кич утырып
Энҗе тезгән кебек кенә,
Ул сихри сүзләренә
Түзәр нинди егет кенә!

Яза егет: хатлар итеп
Күкрәгеннән кош җибәрә –
Йөрәктәген барып сайрый
Авылдагы бер чибәргә.

Аерыламыни күңел,
Ерагая диеп ара? –
Араларны якынайтып,
Хатлар бергә тегеп бара.

Тегеп бара, чигеп бара,
Беленми дә кала җөе:
Энҗе сыман бу яшьлекнең
Энәсендә – сөю җебе...

## ЯЗГАН ИДЕМ ИСЕМЕҢНЕ

Язган идем исемеңне
Яңа яуган карларга,
Карлар эреп агып китте
Инде әллә кайларга,
Инде әллә кайларга.

Исемеңне нурлар белән
Күлләргә язган идем,
Күлләр кибеп, камышларны
Кайгыга салган иде,
Кайгыга салган иде.

Исемеңне үргән идем
Кырда үскән гөлләрдән,
Гөлләр кибеп таралдылар,
Сибелделәр җилләргә,
Сибелделәр җилләргә.

Калса калыр миннән бары
Күмер генә, көл генә,
Исемеңне язып куйдым
Йөрәгемнең түренә,
Йөрәгемнең түренә.

* * *

Малай чакта матур апаларны
Мин бер генә күреп сокланмадым,
Булгалады: «Нигә мин иртәрәк
Тумаганмын?» – диеп уфтанганым...

Очратам да чибәр сеңелләрне,
Карашларым белән сөеп куям:
«Нигә бераз гына соңга калып
Туылмаган икән?» – диеп куям...

Никадәрле гүзәлләр бар җирдә...
Бәхетемне күреп куандым мин:
Юк, иртә дә түгел, соң да түгел –
Нәкъ вакытын белеп туганмын мин!..

* * *

Җилләргә кушылып җырлама,
Көй эзләп интекмә гыйшкыма.
Әнә бит, кошларга колак сал –
Быел да күкеләр кычкыра.

Яшәрә дөньялар быел да,
Инде бу ничәнче кабаттыр!
Искәртә шикелле табигать:
Яратты...
Ярата...
Яратыр...

Быел да кычкыра күкеләр,
Әле без киткәч тә кычкырыр.
Танырлар,
Танырлар сөюне –
Җирдә ул иң моңлы кош булыр...

* * *

Сине әле беркем яратмаган,
Син беркемне әле сөймәгән.
Мәхәббәтне сиңа кичләр әле
Әкият итеп кенә сөйләгән.

«Әкият кенә бит ул!» – диясеңдер.
Әкияттер дә...
Ләкин нигә соң
Зөһрә кызга әвереләсең дә,
Таһирларны төштә күрәсең?

Беребез дә җавап биралмабыз.
Гомер буе шулай әллә без
Әкиятне – чынга,
Чынбарлыкны
Әкиятләргә әйләндерәбез...

Син – гомерлек әкиятем минем,
Беркемгә дә ләкин сөйләмәм!
...Сине әле беркем яратмаган,
Син беркемне әле сөймәгән...

* * *

Юлга чыгып, җитми калганым юк.
Тик аптыраш менә монысына:
Әллә нинди зәхмәтле юл булды –
Гомерем буе барам мин сиңа...

Әллә нинди зәхмәтле юл булды...
(Бик ерак та түгел идең бит!)
Адаштырып алып кереп китте,
Кайларда соң калдың түгелеп?

Адаштырып алып кереп китте:
Йөгерәмен... Шуам түш белән...
Утка керәм... Зилзиләләр кичәм –
Әле янам, әле күшегәм.

Тагын күпме бардыр барасылар –
Яшерелгән миннән монсы да.
...Барам сиңа, гомерләрем булса,
Булмаса да барам мин сиңа!..

## ЙӨГЕРӘМЕН ДӘ ЧЫГАМЫН...

Йөгерәмен дә чыгамын,
Чыгамын юлларыңа –
Шөкерләр итеп, сөенеп
Дөньяда булганыңа.

Гомернең каршы җилләре
Капланса тыннарыма,
Башкайларымны куямын
Шәфкатьле кулларыңа.

Беләм бит синең җаныңа
Кайгылар чыдамасын –
Кояшны җиргә көн саен
Син генә чыгарасың.

Килмидер әле башына,
Килмидер берәүнең дә:
Бәхетнең алтын ачкычы –
Ул синең йөрәгеңдә.

Йөгерәмен дә чыгамын,
Чыгамын юлларыңа –
Шөкерләр итеп, сөенеп
Дөньяда булганыңа...

## АЙ НУРЫНДА

Бар серләрен Айга сөйләгәннәр:
Гашыйкларның бүтән юлы юк.
Катлам-катлам сөю икән лә Ай –
Заманнардан килгән җыелып.

...Әй тирән дә иде Ай ул төнне,
Төпләрендә аның син идең –
Якты идең...
Мөлдерәмә тулы
Сөю аша җиргә түгелдең.

Син белдең бит җирдә мин икәнне,
Белдең бит син Айга карасым.
Тик белмәдең бугай карашымның
Мәңгелеккә анда каласын.

Гашыйклары килер дәверләрнең
Ай дип белер... Сөйләр серләрен...
Безнең сөюләр дә яктыртачак
Җирнең әле әллә кемнәрен...

* * *

Бер – яшьлектә, бер – картлыкта, диләр...
Калды берәү, калды яшьлектә:
Йөгереп тә баралмыйсың икән,
Алалмыйсың икән дәшеп тә.

Бер – картлыкта...
Тик нигәдер монсы
Картайганны көтеп тормады:
Чыңлап килеп керде җаннарыма,
Әйләндереп салды дөньямны.

Исәрләнгән саен исләремдә,
Картлар сүзен тыңла икән ул!
Бер – яшьлектә, бер – картлыкта түгел,
Кайчан сөйсәң – шунда икән ул...

* * *

Алым түгел, гөлем түгел,
Беркемем дә түгелсең.
Тутырыплар карап калыйм –
Үзәкләрем өзелсен!

Телгәләнсен бәгырьләрем –
Шушыдыр минем өлеш.
Китәсе булганмын ла мин
Бу җирдән ялгыз килеш,

Күрми калсам әгәр сине.
Өзгәлә – түзәр йөрәк.
Алым түгел, гөлем түгел –
Син гөлдән гүзәлрәк.

* * *

Исемә генә төшмәдең –
Син бит әллә нишләдең:
Болындагы чәчкәләрдә –
Синең күлмәк ишләрең...

Карашларың – тулган айда,
Толымнарың – талларда.
Таңнарда – алсу йөзләрең...
Карыйм тагын кайларга?

Гомеремнең буйларына
Болай булсаң нишләрмен?! –
Болындагы чәчкәләрдә –
Синең күлмәк ишләрең...

* * *

Күпме эшең эшләнмичә кала:
Бетми гомер, бетми яшәлеп.
Безнең өлешләргә тигән көмеш –
Тик бер генә сөеп дәшәрлек.

Мин бит әле таптым гына сине,
Бу дөньялар кая ашыга? –
Бүтән гамәл беткәнмени җирдә,
Ашкынмаса сөю башына?!

Сиңа гына әйтеләсе бит ул,
Синнән башка аны кем аңлар? –
Үткәннәрдән кем кагыла диеп,
Сәерсенер кебек урманнар.

Бу дөньялар кая ашыга соң? –
Бетми сөю, бетми сөелеп.
Сәхрәләрдә моңлы җил булырмын,
Чәчәкләргә әйлән син элек...

* * *

Бу буран – минеке:
Дуласын,
Еласын капланып. Аны мин
Сорадым Ходайдан. Түзәрлек
Хәлләре калмагач җанымның.

Минеке бу буран, минеке...
Кермә син, чыгалмас башкаең,
Кермә син – сөюем кабынган
Елларны буранга ташладым.

Дуласын, еласын капланып,
Янсын бер кар баскан болында.
Бу буран – минеке... Ачынып
Сызгыра, сызгыра: ул монда-а-а!..

Елларга чәчләрең көярлек...
Яланбаш чыгам да йөгерәм:
Бары тик минеке бу сөю,
Минеке, минеке бу буран...

# АЛМАЛАР

Алмалар белән сөйләшәм,
Сорыйсы сүзем калган.
Шунсыз мин алма битләрнең
Серләрен аңлый алмам.

Алланып чыгалар икән,
Эндәшсәң алмаларга:
Бары алсу җил генә бит,
Җил генә араларда.

Җырга әйләнергә тора
Исеңә алган саен, –
Сандугач моңы тамгандыр
Бу якта алма саен.

Яшермә алмаларыңны,
Алдала, гомер, алда!
...Таңнарга төшә алсулык –
Алмалар бардыр алда...

# ФӘРМАН

*Айдар белән Рузиләгә*

Яратырга, бары яратырга!.. –
Ходайның бу изге фәрманы.
Аны үтәмәгән бәндәләрнең
Бәхетләре була алмады.

Гомер җиле җилфердәгән җайга,
Тугры калып бөек фәрманга,
Мәхәббәттән йөрәк кенә түгел,
Алсуланып гөлләр янганда

Кавышалар адәм балалары.
Мәңгелектер безнең бу бәйрәм.
Аннан беркем читтә калалмыйча,
Гөлгә яки көлгә әйләнгән.

Мәңгелектер...
Урта бер җирендә,
Казан дигән шушы төбәктә
Сүрелмичә килеп җиткән фәрман,
Үтеп кергән ике йөрәккә.

Сулышларга инде әйләнгәндер,
Үтәмичә кара син аны:
Яратырга, мәңге яратырга, –
Дөнья итәр өчен дөньяны...

## ГӨНАҺ

Хаталардан хали түгел бәндә,
Сезнең алда мин дә гөнаһлы:
Ходай миңа сөю биргән иде,
Фәкыйрегез шуны югалтты.

Адәм белән Хава булмасак та,
Бер-беребезгә Ходай яраткан.
Ул яраткан.
Менә тик без генә...
Үкенмәде микән азактан?

И гөнаһлы җаннар! –
Ничә еллар
Җир йөзендә мин дә,
Ул да бар.
Барын бар да,
Тик Ходайча түгел.
Шуңа бозык мәллә дөньялар?!

Афәтләрнең башы шундадыр күк...
Сезнең алда олы гаебем.
Яши алмам болай,
Гаебемне
Төзәтермен кебек әле мин!

* * *

Еламыйм сине,
Җирдә син
Гел аның өчен түгел...
Тыгылма күзгә,
Иртә-кич
Дәфтәрләремә түгел!

Син бит соң миңа Ходайдан
Җыр итеп җибәрелгән! –
Язылмый гына йөрисең
Адашып җилләр белән.

Каләмгә ураласың да,
Чыгыплар югаласың.
Дивана итәр микәнни
Тәңрем бу баласын?!

Нигә укытадыр сине
Догалар урынына?!
Югыйсә үзең дә аның
Газиз бер колы гына.

Гомер хәтле бер гомерлек –
Артык та түгел, ким дә:
Җырлансаң-җырланмасаң да
Миндә син, мәңге миндә!..

* * *

Күпме гомерләр үтмәде,
Ничәмә-ничә еллар...
Ул беркая да китмәде,
Шушында бит ул, ул бар!

Әнә бит: чәчкә күзеннән
Мөлдерәп карап тора.
Чайкалыр... Калма үзеннән,
Ярат та ярат кына.

Юлларның болай буталып
Калырын каян белим?
Мин үзем, үзем бит аны
Чәчкәгә әйләндердем.

Ялгыз чәчкә иртә сулар,
Түзгәндер дә моңарчы.
Ул шушында... Көтәсе бар
Үзем чәчкә булганчы...

## КАЛ МИНЕМ ЙӨРӘГЕМДӘ

Бәхетемә тишелгәнсең:
Йөрәгемдә гөл үсә.
Күтәрелеп елмай әле, –
Гөлгә чәчәк килешә.

Гөлләргә чәчәк килешә,
Арасыннан җил исә.
Бер дә сине мин җилләргә
Бирмәс идем югыйсә.

Чәчәкләр булып атканы
Юк иде берәүнең дә,
Гөлләрдән башка нишләрмен, –
Кал минем йөрәгемдә!..

* * *

Гасырларга кушып җырламаслар
Синең белән минем исемне:
Гөле шулдыр... Әмма яланнары,
Заманнары бүтән ич инде!

Җандагыны чыгып кычкырмадык.
Ә каеннар барыбер сизенгән:
Боларны да күреп калыйк диеп,
Юл буена чыгып тезелгән.

Ил күзеннән нәрсә яшерәсең! –
Таң җилләре искән чакларда,
Мәңгелекнең ап-ак каеннары
Пышылдарлар безнең хакта да...

* * *

Күкләргә йолдызлар чәчелгән,
Бер калка җемелдәп, бер сүнә...
Карыймын күзләрем талганчы –
Нигә соң син түгел берсе дә?!

Тирән шул дөньялар, әй тирән –
Җитәлми карашым, җитәлми...
Җирдәге сөюнең яктысы
Йолдыздан арырак микәнни?

Сине соң тәкъдирләр нигә дип
Бу чаклы еракка яшергән? –
Күкләргә ашкына гомерләр.
Алдыма йолдызлар чәчелгән...

* * *

Дөньяга мин сине эзләп килдем.
Эзләгәнем, шөкер, табып китәм.
Шуның өчен, акылымда килеш,
«Исәр» дигән исем тагып китәм.

Дөньяга мин сине эзләп килдем.
Эзләгәнем, шөкер, табып китәм –
Үтеп чыга алмас ут икәнсең...
Үземне мин утка ягып китәм.

Дөньяга мин сине эзләп килдем.
Эзләгәнем, шөкер, табып китәм.
Соң булса да, өрфиядәй җанны
Иңнәреңә синең ябып китәм...

Харрас Әюп (Харрас Гыйльмегали улы Әюпов) 1946 елның 21 августында Татарстанның Мөслим районы Түреш авылында колхозчы гаиләсендә туган. Түрештә башлангыч белем алып, 1964 елда Күбәк урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

Х.Әюп үзенең хезмәт юлын 1969 елда Мөслимдә район газетасында әдәби хезмәткәр буларак башлап җибәрә, соңрак редакциянең авыл хуҗалыгы бүлеген җитәкли. Казанга күчеп килгәч, 1972 елның апреленнән алып 1983 елның декабренә кадәр ул «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясендә эшли. 1983 елдан башлап хезмәтен Татарстан китап нәшриятында дәвам иттерә: башта матур әдәбият редакциясендә редактор була, 1992 елның сентябреннән – шул редакциянең мөдире, ә 1994 елдан – нәшриятның баш мөхәррире.

Х.Әюпнең беренче язган шигырьләре урта мәктәптә укыган чорга – 60 нчы еллар башына туры килә. Аларның берсе 1962 елда район газетасында басылып та чыга. Шуннан соң ул үзенең шигырьләре белән вакытлы матбугатта даими катнаша башлый, язганнары «Яшь ленинчы» газетасы битләрендә дә урын ала. Университетта укыган елларда ул әдәби иҗат белән ныклап шөгыльләнергә карар итә. «Әллүки» әдәби берләшмәсенә йөреп тәҗрибә туплый, танылган язучылар белән аралаша. Шигырьләре республика газета-журналларында, «Идел» альманахында, яшь авторларның күмәк җыентыкларында дөнья күрә. Х.Әюп иҗаты 60 нчы елларда татар шигъриятенә килеп кергән яңарышның бер чагылышы буларак бәяләнә.

Кулга каләмне иртә алса да, авторның үз-үзен эзләү чоры шактый дәвам итә: «Ышаныч» дип исемләнгән беренче китабы 1980 елда гына басылып чыга. Аннан соң бер-бер артлы дөнья күргән «Кояшлы яңгыр», «Каен балкышы», «Таң суы», «Төнге кояшлар», «Сабыр савытлары», «Җәяүле буран», «Көй эзләү» кебек китаплары Х.Әюпне шигърият сөючеләргә сүз төмен белгән, халык рухын яхшы тойган җитди каләм иясе итеп танытты. Соңгы елларда аның иҗатына карата игътибар тагын да көчәя төште. Х.Әюп поэмалары буенча эшләнгән тапшыруларны радиотыңлаучылар яратып кабул иттеләр, шагыйрьнең телевидение аша ясаган чыгышлары да тамашачылар күңелендә теләктәшлек тапты, аның сүзләренә язылган җырлар торган саен ешрак яңгырый.

Уңышлы әдәби эшчәнлеге өчен Х.Әюпкә 1994 елда «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Х.Әюп – 1982 елдан бирле Язучылар берлеге әгъзасы.

**Ышаныч:** Шигырьләр. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1980. – 144 б. – Рец.: Гайнетдинова Д. Ак кәгазьдә күңел нуры // Татарстан яшьләре. – 1981. – 13 гыйнвар.

**Кояшлы яңгыр:** Шигырьләр, поэма. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1983. – 80 б.

**Каен балкышы:** Шигырьләр. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1985.– 96 б.

**Таң суы:** Шигырьләр. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1987. – 119 б.

**Төнге кояшлар:** Шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1989. – 159 б. – Рец.: Гыймадиев И. Шагыйрь күңеле // Социалистик Татарстан. – 1990. – 2 ноябрь.

**Сабыр савытлары:** Шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1992. – 207 б. – Рец.: Сибат Р. Гомерлек аргамак // Ватаным Татарстан. – 1994. – 29 июль.

**Ташка язгандар һөйөүзе:** Шигырзар һәм поэмалар. – Өфе: Башкортстан «Китап» нәшрияты, 1994. – 179 б. – Рец.: Поварисов С. Ташка язылган мәхәббәт // Кызыл Таң. – 1997. – 6 август.

**Биш вакыт намаз:** Поэма. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1995. – 15 б. – Рец.: Рәхмәтуллина Г. Биш вакыт намаз // Шәһри Казан. – 2002. – 19 октябрь.

**Җәяүле буран:** Шигырьләр һәм поэмалар / Зөлфәт кереш сүзе. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1996. – 383 б.

**Көй эзләү:** Поэмалар, баллада. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2001. – 110 б. – Рец.: Ибраһим Х. Көй эзли шагыйрь // Ватаным Татарстан. – 2002. – 17 май.

**Ут аркылы сикерү:** Шигырьләр, поэмалар. – Казан: Мәгариф, 2004. – 175 б.

**Гыйльман Г.** «Кояшлы яңгыр» хакында уйланулар яки елак тәнкыйть // Гыйльман Г. Заман сүз сорый. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1991. – 31-40 б.

**Галимуллин Ф.** Яшен дисеннәр... // Шәһри Казан. – 1995. – 24 март.

**Вәли Р.** Гомерләрнең өйлә туры җиткән... // Шәһри Казан. – 1996. – 23 август.

**Әхмәтҗанов М.** Нәселемнең мин бер тәрәзәсе... // Мәдәни җомга. – 1996. – 5 июль.

**Зөлфәт.** Тыелгысыз кош сере // Казан утлары. – 1996. – № 8 – 78-81 б.

**Гаташ Р.** Тын, илаһи гыйбадәт // Ватаным Татарстан. – 1996. – 20 август.

**Әхмәтҗанов М.** Без – Кояштан // Татар иле. – 1996. – 31 август.

**Юнысова А.** Гомерләр узып бара // Ватаным Татарстан. – 2001. – 7 сентябрь.

**Садриев Ф.** Зәңгәр күзләр дөньясы // Мәйдан. – 2004. – № 2. – 140-143 б.

**Камалова А.** Без – Кояш балалары // Идел. – 2004. – № 7.- 65-67 б.

# ЭЧТӘЛЕК

Күңелендә шигырь уты. *М.Бакиров.* . . . . 5

## I. Су хәтере

Хәтер . . . . 16
«Яулардан һәм сугышлардан тора...» . . . . 17
«Утлар яна...» . . . . 18
Казан . . . . 19
Мөслим музеенда . . . . 20
Ык буенда җил исә... . . . . 21
«Туган ягың, табигатең булып...» . . . . 22
Казанда яңгырлар... . . . . 23
Болгарга кайту . . . . 24
Сөембикә манарасындагы айны сәламләү . . . . 25
Яра . . . . 26
Тел күрсәтә... . . . . 27
Үзгәрешләр турында . . . . 28
Үз-үземә генә түгел . . . . 29
Авырткан җир . . . . 30
Су хәтере *(Поэма)* . . . . 31
Базарлар *(Публицистик поэма)* . . . . 39

## II. Гомер сандыгы

Гомер . . . . 50
«Япа-ялгыз яланнарда йөрим...» . . . . 50
Болын . . . . 51
Ак метеор . . . . 52
«Җир-суларым иркен сулап ята...» . . . . 53
«Үрләде таң офык читләреннән...» . . . . 54
«Белеп торам: елау – бәхет түгел...» . . . . 55
Ялгызлык . . . . 55
«Күпме генә озак яшәмәсен...» . . . . 56
Мәрхәмәт . . . . 57
«Нәселемнең мин бер тәрәзәсе...» . . . . 58
Җылы килә . . . . 59
Гомер сандыгы . . . . 60
Җәйге агым . . . . 61
Тел ачкычы . . . . 62
Очу . . . . 63
«Ышанасы иде шуңа...» . . . . 64
Халәт . . . . 65
Сабантуй булып узган мәйданда . . . . 66
Бермуд өчпочмагы . . . . 67
«Әле генә зәңгәр язлар иде...» . . . . 68
Әбиләр чуагы . . . . 69
Васыять . . . . 70

Ничә гасыр елый Йагкуб... 71
«Сандугачлы һәм тургайлы дөнья...» 72
Таң суы 73
«Җилләр – җилфер-җилфер...» 74
«Бигрәк озак тоела иде безгә...» 74
Йөгермәктә кеше 75
Кояш 76
Иңнәремә сал башың... 77
Гөлләр исән... 78
Нәсел агачы 79
Тирәндәрәк әле... 80
«Гел кояшлы түгел дөнья...» 81
«Бер яман сүз җиткерделәр миңа...» 81
Биеклек 82
Әткәй белән сөйләшү 83
«Баш очында күкләр нинди тирән...» 85
«Гомер юлым кая юнәлсә дә...» 86
«Үз-үземне белә башлаганда...» 87
Кечке уен 88
Аклык 89
Кояш чыгышларын карап торам... 90
Баш очында бер кош 91
Шәһәргә килгән авыл баласына 92
«Барыбыз да – ата балалары...» 93
Мәүлет кичендә 94
«Сандугачлар сусап су тапмыйлар...» 95
Ут аркылы сикерү 96
Кош елавы 97
«Җидегән йолдыз!..» 98
Песнәк 99
Авылдашым Өммеһани апага ачык хат 100
«Бу дөньяда мине яраттылар...» 101
Абый!.. 102
Терелтмичә китмә!.. 103
«Булыр-булмас арба юл бозар, ди...» 104
«Кемнәр генә җирдә яшәмәгән...» 104
Күкләр шул ук... 105
Күтәр! 106
Татар җыры 107
Гармун бәйрәме 108
Кыр казлары Казан өстендә... 109
Буран тынган ара... 110
Гомер буе... 112
Көйләр түгел иде... 113
Җанында Калмия бар... 114
«Каерылам да карыйм...» 115
Түтәл-түтәл ак болытлар 115
Бүген белдем... 116

«Ышанычлар челтәрләнеп бетте...» . . . 116
Йа Илаһым!.. . . . 117
Дөньяга үпкә сүзе . . . 118
Сулар тирән... . . . 119
Ат җикте малайлар... . . . 119
Хәтер тауда . . . 120
«Кояш чыгар...» . . . 121
«Йөрәгемдә йөрткәнгәме...» . . . 121
«Тартылган кыл сыман зыңлап тора...» . . . 122
«Замананың шакшысына...» . . . 123
«Дөньялыкны кичеп чыгып барам...» . . . 123
И эзләрсез әле... . . . 124

## III. Гамәл дәфтәре

«Бу туфракка күпме җылы сеңгән...» . . . 126
Төнбоеклар . . . 127
«Акты Вакыт...» . . . 128
«Төнге күктә кемдер шырпы сыза...» . . . 128
«Нигә болайдыр язмышлар...» . . . 129
«Күпме шәфәкъ ябып киткән нурын...» . . . 130
«Тагын берәү – кемдер яши миндә...» . . . 131
Сабырлык . . . 132
Сандугач үлеме . . . 132
«Тирәләре яшел үлән...» . . . 133
Хиросима ташы монологы . . . 134
«Бөтенесе туфракка сеңгән...» . . . 135
Без – бербөтен . . . 136
Сулар ага . . . 137
«Тагын бер көн китеп барды бездән...» . . . 138
Бер уйласаң... . . . 138
Бәйрәмнәр . . . 139
Исәнлек . . . 140
Оча кошлар... . . . 141
Дөнья бүген . . . 142
Нигә болай? . . . 143
Йөзьяшәр карт белән очрашу . . . 144
Җирдән киткәннәр сүзе . . . 145
Кояш тотылганда бер уй . . . 145
Караш . . . 146
Акбүз ат . . . 147
Күчтәнәчләр тәме телемдә... . . . 149
Урманнарга җәйләр кереп килә . . . 150
Гамәл дәфтәре . . . 151
«Гаҗәеп бер әкият эчендә без...» . . . 151
«Башкаеңны кая куяр идең?..» . . . 152
Кышкы Идел өстендә . . . 153
Өй салу . . . 154
«Күкләрдә – мәңгелек болытлар...» . . . 155

Кояш тотылу . . . 156
Гаҗизлек . . . 157
«Үз хәлеңне үзең генә белдең...» . . . 158
«Елыйм, дисәң – күптән яшең чыкмый...» . . . 158
«Үзеннән дә зурны күтәрә дип...» . . . 159
«Нигә уфтанырга, арткан өчен...» . . . 159
«Күзгә күренмәс булырга...» . . . 160
Аерылу . . . 161
«Яраткан да җан иясе итеп...» . . . 162
Кара Тау . . . 163
«Туган ил киң: җәелгән ул...» . . . 164
«Иң беренче – телгә төшә каргыш...» . . . 164
«Күләгәле дөнья, күләгәле...» . . . 165
«Яманладым бүген мин берәүне...» . . . 165
«Утларга салмагыз җанны...» . . . 166
«Кышның инде соңгы бураннары...» . . . 166
«Күпме җаннар канда килеш кала!..» . . . 167
«Күңел яхшы иде...» . . . 167
Бер генә мизгелгә... . . . 168
Йөз яктысы . . . 169
Каен . . . 170
«Җирдән киту – үлем түгел әле...» . . . 170
«Сокланмаган кеше юктыр...» . . . 171
Безнең гомер . . . 172
Сабантуй . . . 173
Әманәт . . . 174
Төнге очыш . . . 175
«Агач башлары шаулыйдыр...» . . . 176
Без – Кояштан . . . 177
Тик без генә . . . 178
Учак . . . 179
Соңгы ат . . . 180

## IV. Тәкъдир каләме

Кәгазь белән сөйләшү . . . 182
«Тузга язмаганны сөйләмәскә...» . . . 183
«Җанда шигырь бөреләнгән саен...» . . . 184
Хатлар юлы . . . 185
Тәкъдир каләме . . . 186
«Кыйгак-кыйгак, кыйгак-кыйгак!..» . . . 187
«Уйларымны сыйдыралмыйм сүзгә...» . . . 187
Терек суы . . . 188
Шигырьнең өч халәте . . . 189
Җиләк җыю . . . 191
Яшен вакытында язылган шигырь . . . 192
Язмыйм инде... . . . 193
«Болыннарда күбәләкләр...» . . . 194
Шәм яктысы . . . 195

Гыйбадәт . . . 196
Бишексезләр өчен бишек җыры . . . 197
«Су буенда казлар төзәтенә...» . . . 198
Биш вакыт намаз . . . 199
Заманнарның иң кирәкле сүзе . . . 204
Шигырь бәйрәмендә . . . 205
«Дөньялыкны узып барган чакта...» . . . 206
Өч кенә сүз... . . . 207
Язмыш . . . 208
Гөлчәчәк . . . 209
Язалмаган чакта туган шигырь . . . 210
«Кеше китә...» . . . 211
«Ишетми калма берсен дә...» . . . 211
Аккош күлендә . . . 212
Моңлы бер кыл . . . 213
Илһам Шакиров җырлаганда . . . 214
Шамил Усманов . . . 215
Сибгат Хәким төше . . . 216
Калка Туфан... . . . 217
Бөекләрнең гомерләре... . . . 218
Барып җитәр көне... . . . 219
Такташка хат . . . 220
Үз күгеңдә . . . 226
Китап тотып кулга... . . . 227
Гармун . . . 228
Юксыну . . . 229
Туры сүзгә . . . 230
«Бер иңдәге ике фәрештә күк...» . . . 231
Шагыйрь дуска . . . 232
Җыр тамыры . . . 233
Озын төннәр уртасында... . . . 234
Мокамай . . . 235
Кайту . . . 236
Иман яңарту . . . 237
Шигърият китабы . . . 238
Кол Галигә . . . 239
Таң җиле . . . 240
Көй эзләү *(Поэма)* . . . 241

## V. Авыл җаны

«Сулар булып актым туган яктан...» . . . 250
Җил . . . 251
Алма исе . . . 252
Ә бәбкәләр һаман яшел... . . . 253
Икмәк . . . 254
«Иңнәрендә – сары толымнары...» . . . 255
Көзге торналар . . . 256
Талларга . . . 257

Кибәнче картлар . . . 258
Өянкеләр . . . 259
Авыл. Кичке зират . . . 260
Көз . . . 261
«Назларыңда – әнкәй мәхәббәте...» . . . 261
Чишмәне сагыну . . . 262
«Безнең якка таба яңгыр узды...» . . . 263
Балачак иле . . . 263
Нур булып калыккансың... . . . 264
«Тәлгәш-тәлгәш аклык иңә күктән...» . . . 265
Кесәдәге җил . . . 266
«Яктыдан да якты – нәрсә якты?..» . . . 267
Авылымда шундый шагыйрьләр бар... . . . 268
«Күргән-кичергәннең бик күбесе...» . . . 269
«Җәйге бакча...» . . . 270
Салават күпере . . . 271
Арыш кыры . . . 272
Авыл картлары . . . 273
Әлли-бәлли... . . . 274
«Төркем-төркем кошлар күтәрелде...» . . . 275
«Бала чакта бары да ерак була...» . . . 276
«Авырлыктан түгел, сабырлыктан...» . . . 277
Бусага . . . 278
Иске нигез өстендә уйлану . . . 279
Чакыру . . . 280
Алма әби . . . 281
Өй өмәсе . . . 282
Капка ачу . . . 283
Авылым юкәләренә . . . 284
Минем туган якларымда . . . 285
Ә-ә-әү!.. . . . 286
«Басар өчен сагыну-җирсүләрне...» . . . 287
Дөнья яратылу . . . 288
Көзге чакыру . . . 289
Авыл . . . 290
Авыл карчыклары . . . 291
Авылым көзе . . . 292
Авыл җаны *(Поэма)* . . . 293
Куш Чишмә . . . 302
Язгы хатирә . . . 303
Өстән бикләнгән... . . . 304
Арыш басуында . . . 305
Печән чабу . . . 306
Шунда, агай!.. . . . 307
«Мич» янында . . . 308
Мөслим көзе . . . 309
Сабый чактан бер күренеш . . . 310
Кайсыгыз? . . . 311

Килә дә карый бер малай... . . . . . . . . . . . . . . 312
Җил дә бар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 313
Кырынтау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 314
Йөрәк атым *(Поэма)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 315

## VI. Әнкәйгә кайту

«Озак үстек микән бу яшькәчә...» . . . . . . . . . . . . 324
«Күзеңнән моңсулык сирпелә...» . . . . . . . . . . . . . 325
«Тын белән җылыталармы...» . . . . . . . . . . . . . . . 326
Казлар эзләү *(Бәет)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 327
«Син бит, әнкәй, мәңгелектә...» . . . . . . . . . . . . . 328
Мирас . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 329
Көй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 330
Шелтә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 331
Каз кычкыра . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 332
Әнкәй җырлый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 333
«Кайгырдың син, әнкәй, авыр чакта...» . . . . . . . . . . 334
Чәчәк анасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 335
«Менә син дә дөнья куйдың, әнкәй...» . . . . . . . . . . 336
Әнкәйнең ак самавыры . . . . . . . . . . . . . . . . . . 337
Капка баганасы турында баллада . . . . . . . . . . . . . 338
Анда ни бар? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 346
Кайтып барган чакта Мөслимгә... . . . . . . . . . . . . . 347
Каравылда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 348
Әрәмә бар... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 349
Әнкәйгә кайту . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 350
«Ишетәм көзге җилләрдә...» . . . . . . . . . . . . . . . 351
Әнкәемнең биш бөртеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . 352
Дисбе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 353
«Әнкәй!» – диеп башлап кителгәннәр...» . . . . . . . . . 354
Көзге *(Поэма)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 355

## VII. Кечке тәрәзәләр

«Ышанып та бетмим кешеләргә...» . . . . . . . . . . . . 364
Без язган хатлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 365
«Үзең белмисеңдер әле...» . . . . . . . . . . . . . . . 366
Ай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 367
«Бер үк җырның ике яртысы без...» . . . . . . . . . . . . 368
Синдер ул бары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 368
Әйтегезче! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 369
«Шомыртларга инде ак шәл кирәк...» . . . . . . . . . . . 370
Бер сылуга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 370
«Нәрсә югалттың, сылукай...» . . . . . . . . . . . . . . 371
Көзге яңгыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 372
«Акрын гына китеп барам синнән...» . . . . . . . . . . . 373
«Матурлык алдында телсез...» . . . . . . . . . . . . . . 373
«Һаваларга җырлар язам...» . . . . . . . . . . . . . . . 374
Кыйбла . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 374

Кичке тәрәзәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 375
Оныттыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 376
Бер карасам... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 376
Ялгышына кадәр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 377
Кичләрем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 378
«Икесе дә – ашың да бар, яшең дә бар...» . . . . . . . . . . . 378
Кайда син, гармун? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 379
«Берәүдән дә җылы сүзем кызганмадым...» . . . . . . . . . . . 379
Сиңа гына язган хатлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 380
«Чәчәк җыеп йөри кызлар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 380
«Минекеме әллә түгелме син?..» . . . . . . . . . . . . . . . . 381
«Таш бәгырьле, дисең мине...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 381
«Сиңа гына дигән бер җырым бар...» . . . . . . . . . . . . . . 382
Сөю . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 382
Якты көннәр җирдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 383
Матурларга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 384
Миләш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 385
«Сөюне сөюдән аерсак...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 386
«Ташка язганнар сөюне...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 386
Сөю фасылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 387
«Хатлар килә, хатлар китә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 388
Язган идем исемеңне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 389
«Малай чакта матур апаларны...» . . . . . . . . . . . . . . . . 390
«Җилләргә кушылып җырлама...» . . . . . . . . . . . . . . . . 390
«Сине әле беркем яратмаган...» . . . . . . . . . . . . . . . . 391
«Юлга чыгып, җитми калганым юк...» . . . . . . . . . . . . . 392
Йөгерәмен дә чыгамын... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 393
Ай нурында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 394
«Бер – яшьлектә, бер – картлыкта, диләр...» . . . . . . . . . 395
«Алым түгел, гөлем түгел...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 395
«Исемә генә төшмәдең...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 396
«Күпме эшең эшләнмичә кала...» . . . . . . . . . . . . . . . . 396
«Бу буран – минеке...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 397
Алмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 398
Фәрман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 399
Гөнаһ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 400
«Еламыйм сине...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 401
«Күпме гомерләр үтмәде...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 402
Кал минем йөрәгемдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 403
«Гасырларга кушып җырламаслар...» . . . . . . . . . . . . . . 403
«Күкләргә йолдызлар чәчелгән...» . . . . . . . . . . . . . . . 404
«Дөньяга мин сине эзләп килдем...» . . . . . . . . . . . . . . 404

Биобиблиографик белешмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 405

Литературно-художественное издание

*Харрас Аюп*
*(Аюпов Харрас Гильмегалиевич)*

# ЗЕРКАЛО ДУШИ

Стихи, поэмы

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Рәссамы *В.В.Фомин*
Техник мөхәррире һәм комьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Г.М.Хәбибуллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 22.06.2005. Форматы 70×108 $^1/_{32}$. Офсет кәгазе.
«Futuris» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 18,20 + форз. 0,18.
Шартлы буяу-оттиск 73,85. Нәшер-хисап табагы 14,78 + форз. 0,29.
Тиражы 2000 д. Заказ А-453.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

ААҖ «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.